Безнен МИРАС
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
8
август 2021
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Омскидагы татар матбугаты
28 бит

Троицк байларыннан Габделвәли Яушев
33 бит

ТАРА ӨЯЗЕНДӘГЕ (ХӘЗЕРГЕ ОМСК ӨЛКӘСЕ) ТАТАР СӘҮДӘГӘРЛӘРЕ. XX ГАСЫР БАШЫ

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС
12 +
8
(332)
август 2021

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

10

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Василь Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энже Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Әдип Маликов

ТАРИХИ МИРАС

4 Әйтикиннәр. *Р.Нәфыйков, Ф.Вәлиев*
10 «Себергә бөек гыйльми камиллекне бүләк итеп алып кайтты». *Р.Фәхреддин*
13 Себернең югалган Казаны. *Н.Галиева*
16 Киң вә гали табигатьле Омски имамы. *А.Сәйфетдинов, Л.Гобәйдуллин*
21 Минем соңгы археологик табышым... *М.Госманов*
26 Бибимаһруй Үтәмешеваның кабер ташы. *А.Гайнетдинов*
28 Омскидагы татар матбугаты. *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
33 Троицк байларыннан Габделвәли Яушев. *Г.Баттал*
44 Шәҗәрәбез тарихы. *Ә.Маликов*

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ӘДӘБИ МИРАС

49 Тукайның Суомида басылган бер җыентыгы. *Х.Миңнегулов*
53 «Алар бик нык ышаналар...» *Р.Фәттахова*
56 Әдип абый – әдәп үрнәге. *Э.Шәрифуллина*

ТАТАР ГАМЕ

60 Ышанычыбыз аклана. *М.Шәймиев*
61 Күмәчче Хәким оныгы яки Бисмиллалы гомер. *Л.Лерон*
69 «Безнең мирас» котлый!
70 Себер сүзе. *Ф.Бәйрәмова*
76 Валлаһи. *Г.Тукай*
77 Тукай Троицкига кайтты
78 Нурихан ага ватанында

ДИНИ МИРАС

80 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
86 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

88 Себерне өйрәнгән галим. *А.Вәлиева*
96 Себер киңлегеннән – халык күңеленә. *Л.Мөхәммәтҗанова*
100 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
102 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

104 Әнвәр абый Гобәйдуллин рухына догам... *Ә.Зарипов*
108 Татар җырчылары. Кадерле мизгелләр. *З.Гыйльметдинова*
110 «Су буйлап» җыры

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Август*

Заказ №Е-2609. Тираж – 3020 данә. Формат 70x100 $^{1}/_{16}$
Басарга кул куелды: 27.07.2021. Чыгу көне: 02.08.2021.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Тара өязендәге (хәзерге Омск өлкәсе) татар сәүдәгәрләре. Сулдан уңга: Хәмзә Габбас улы Гыйноятов, Мөхәммәд Госман улы Гыйноятов, приказчик Габделкадыйр Гадельша улы Динмөхәммәдов, Хәмзәнең энесе Сәфәр. XX гасыр башы
Фото төбәкне өйрәнүче Азат Сәйфетдинов коллекциясеннән алынды.

Безнең мирас №8 август 2021

Онытсак үткәнне, оныклар
Санламас бүгеннең кадерен.
Әдип Маликов

Мәскәүдә очрашу. Сәҗидә Сөләйманова һәм Әдип Маликов. Кызыл мәйдан. 1951 ел

ӘДИП МАЛИКОВ
(16.08.1921-23.04.2009)

***

Тормыш кичкән иргә таян! –
Өстен торыр ваклыклардан,
Мәхрүм итмәс шатлыклардан.
Таян иле белән бергә
Үлем аша узган иргә!

***

Аерылганда синнән, туган ягым,
Юксынуым җырда чагылыр.
Урый торгач зәңгәр планетаны,
Юлым синдә туктар барыбер.

***

Авырлыгы юлның – иңнәрдә,
Чишмәләрнең тәме – телләрдә...

***

Минем якыннарым шундый:
Таңнан эшкә узалар –
Таштан поэма салалар,
Асфальттан җыр сузалар.

***

Буып булмый җырны ялган белән,
Хаклык өстен чыга ничек тә.

***

Нинди үлчәүләргә сыяр икән,
Үлчәп кара бала шатлыгын!

***

Җырчыларын халык үзе сайлый,
Тик җанына булсын аваздаш!

Текстны журналга
Ләбиб Лерон *әзерләде.* ■

Әйтикиннәр

Рәфыйк Нәфыйков, Фоат Вәлиев

Сулдан: Тобольск сәүдәгәре Мөхәммәдсәфәр Ченбаев, Шәһәр Думасы гласные Тохтасын Аймөхәммәтов һәм сәүдәгәр Габделфәттах Әйтикин

Әйтикин фамилиясе беренче тапкыр, безгә мәгълүм булганча, 1883 елда Казан университеты профессоры Н.Загоскинның «Волжский вестник» газетасында урнаштырылган кыска бер хәбәрендә телгә алына. Аның эчтәлеге болай: сәүдәгәр Әйтикиннең пароходы Обь елгасында сәүдәгәр Громов пароходы белән бәрелешә. Бай эшкуарларга Себер киңлекләре дә кысаная бара. Пароходлар бәрелеше һәр ике як өчен дә әллә ни фаҗига белән бетми бетүен.

Громовлар «эше» күпләргә «Хәсрәт дәрьясы» («Угрюм-река») әсәре буенча яхшы таныш, ә Әйтикиннәр исеме исә бөтенләй билгесез.

Әйтикиннәр нәселе бик ишле һәм бай була. Тара һәм Тубыл татарларының риваятьләренә караганда, Әйтикиннәр нәселенең ыру башы Миргали хуҗа бирегә Себер рус дәүләтенә кушылганга кадәр үк килә, ә «Әйтука» (Әйтикин) этнонимы Миргали хуҗа оныгының улы исеме белән бәйләнгән диелә.

Әйтикиннәр нәселе башында торучылар казакъ далаларында Россия товарларын алмаштырып сату белән шөгыльләнгәннәр. Шактый күләмдә байлык туплагач, алар кәрван белән сәүдә итәргә керешәләр. Әйтикиннәрнең кәрваннары Урта Азиянең Бохара, Кукан, Ташкент һәм башка шәһәрләрендә күп тапкырлар була. **Алар XVIII гасырда ук Кытай белән сәүдә элемтәләре урнаштыралар. Әйтикиннәр Балтыйк диңгезе портлары аша Көнбатыш Европага да зур партия товар чыгаралар.**

Мәгърифә Әйтикина

XIX гасырның икенче яртысында Әйтикиннәрнең Себердә сәүдә предприятиеләре дә барлыкка килә. Тара шәһәрендә — Әйтикиннәрнең туган җирендә аларның ике биналы күн заводы була. 1852 елда бу заводта гомум бәясе 7200 сумлык 3000 данә күн эшкәртелә. Әйтикиннәр заводның әзер продукциясен эчке базарга, Көнбатыш Европа илләренә, Кытайга, Ташкентка һәм Бохарага чыгаралар. Әлеге заводның хуҗасы **Габделфәттах Әйтикин** була. 1865 елда исә Рәхмәтулла Әйтикин Павлодар шәһәрендә күн заводы төзетә.

XIX гасырның беренче яртысында Себер сәүдәгәрләренең иң бае **Нияз хаҗи Әйтикин** санала. 1828 елда Көнбатыш Себер генерал-губернаторы кушуы буенча ул Омскидан Куканга кадәр элеккегесенә караганда кыскарак яңа кәрван юлы салдыра.

Нияз хаҗи Әйтикиннең уллары Габделфәттах («Патша»), Рәхмәтулла («Рахмуш»), Насреддин эчке һәм тышкы сәүдә белән шөгыльләнәләр.

Габделфәттах Әйтикин Павлодар, Алма-Ата, Симәй һәм Тара шәһәрләрендә кибетләр тота. Ул мануфактура, галантерея һәм азык-төлек әйберләре белән сәүдә итә. Ә чит илгә исә ул башлыча үзенең вәкилләре – вак һәм урта хәлле сәүдәгәрләр тарафыннан җыелган бодай сата.

Габделфәттах Әйтикин шулай ук такта чәй, аш тәмләткечләре, фарфор, фаянс савыт-саба, ефәк һәм йон тукымалар кебек традицион кытай товарлары белән дә сәүдә итә. Ул аларны Кытайдан үзе алып чыга торган була.

19 нчы йөзнең илленче елларында Әйтикиннәр, Симәйнең 1 нче гильдия сәүдәгәре Сидор Самсонов, Кяхтаның 1 нче гильдия сәүдәгәре Иван Носков һәм

Әйтикиннәр пароходы

Тара шәһәрендә Әйтикиннәр төзеткән мәчет

башкалар белән берлектә, Чүгүчәк, Голҗа, Кяхта кебек кытай һәм монгол шәһәрләрендә сәүдә итәләр. 1854 елда рус сәүдәгәрләре Чүгүчәктә үз факторияләрен оештыралар. Бу эшләрдә Габделфәттах Әйтикин дә зур активлык күрсәтә.

1880 елда Әйтикиннәр Тарада тәрәзә пыяласы һәм савыт-саба җитештерүче завод ачалар. Дөрес, бу завод озак эшләми. Ялланган эшчеләр, хезмәт шартларының начар һәм хезмәт хакының түбән булуына ачу итеп, аңа ут төртәләр.

XIX гасырның икенче яртысында яшәгән Нияз хаҗиның кече улы **Насреддин Әйтикин** бик үзенчәлекле шәхес була. Мөгаен, ул Россиядә бик тиз үскән капитализм чоры таләпләрен башка сәүдәгәр туганнарына караганда яхшырак тойгандыр. Әтисе һәм өлкән туганнары Урта Азия товарлары белән сәүдә итүне кулай күрсәләр, Насреддин исә рус һәм Европа капитализмы вәкилләренә хас рәвештә эш йөртә башлый.

Өлкән Нияз Әйтикингә сәүдә кәрваннарын Омскидан Куканга һәм Урта Азиянең башка шәһәрләренә илтеп җиткерү өчен татар, үзбәк, казакъ һәм башка кайбер төрки телләрдә яхшы ук сөйләшеп, рус телен уртача белү дә җиткән. Аны, мәсәлән, гади исәп-хисап мәгълүматлары да канәгатьләндергән. Әмма Насреддин Әйтикин боларга гына риза булмый. Ул күп укый, рус телен һәм әдәбиятын тырышып өйрәнә. Гарәп һәм хәзерге төрки телләрне үзләштерә. Кайбер чыганаклардан күренгәнчә, Насреддин һәм Рәхмәтулла, шулай ук, немец һәм инглиз телләрен дә өйрәнә. Тарада Әйтикиннәрнең өй китапханәсендә гарәп, фарсы, рус һәм Көнбатыш Европа телләрендә шактый күп санлы китап тупланган була. Насреддин Россия һәм чит илләрдәге сәүдә һәм сәнәгать предприятиеләрендәге исәп-хисап


Гор. ТАРА
2-й гильдіи.
Айтыкинъ Наръ-Этдинъ Ніясовичъ, чай, сахаръ, желѣзо и кожевен. заводъ.
Айтыкинъ Абейдулъ-Абдулъ Фатаховичъ, мануфактурн. товар.
Айтыкинъ Абдулъ Маметѣевичъ, тоже.
Айтыкинъ Рахматулла Ніясовичъ, тоже.
Айтыкинъ Абдулъ-Маликъ Авасовичъ, разн. мелочнымъ товар.

2-й гильдіи.
Айтыкинъ, Насръ-Этдинъ Ніясовичъ, чай, сахаръ, желѣзо и кожевен. заводъ.
Айтыкинъ, Сеитъ Паталлъ Хоролинаковичъ, мануфактурн. товар.
Айтыкинъ, Абдулъ Маметѣевичъ, тоже.
Айтыкинъ, Рахматулла Ніясовичъ, тоже.
Айтыкинъ, Абдулъ-Маликъ Авасовичъ, разн. мелочнымъ товар.


Купцы 2-й гильдіи:
Айтыкинъ, Абдулъ Маликъ Авасовичъ, чаемъ, сахаромъ и жиров тов.
Айтыкинъ, Насръ-Этдина Ніясовича н-ки, чай, сахаръ и жиров. тов.
Айтыкинъ, Рахматулла Ніясовичъ, хлѣбн торговля.


Купцы 2-й гильдіи.
Айтыкинъ, Абдулъ Маликъ Авасовичъ, чаемъ, сахаромъ и разными товарами.
Айтыкина, Насръ-Этдина Ніясовича наслѣдники, чаемъ, сахаромъ и жировыми товар.


Купцы 2-й гильдіи:
Айтыкина, Абдулъ-Маликъ Авасовича Н-ки, чаемъ, сахаромъ, хлѣбомъ и разн. тов.
Айтыкина, Назира Ніясовича Н-ки, чаемъ, сахаромъ и желѣзными товарами.


Гор. СЕМИПАЛАТИНСКЪ.
Временно торгующіе по 2-й гильдіи.
Абдуловъ, Абдрахимъ Мухаметовъ, мануфакт. тов.
Айтыкинъ, Абдулъ-Маликъ Авасовичъ, мануфактур., скобян., пушнымъ и стеклян. тов.
Афонинъ, Федотъ Сысоевичъ, бакалейн. и галант. тов.
Анаятовъ, Миръ-Пулатъ-Миръ, азіатскими мануфакт. тов.
Аюбаевъ, Мухаметъ-Миръ, азіатскими мануфактур. тов.
Айтыкинъ, Абдулъ Абдулатаховъ, чай и сахаръ.

Әйтикиннәрнең Тара шәһәрендәге йорты

системасының заманча булганнарын аеруча игътибар белән өйрәнә. Ул озаклап Мәскәүдә, Петербургта яши, Берлинда һәм Парижда була. Кайда гына булмасын, сәүдә һәм сәнәгать предприятиеләрен идарә итү ысулларын, аларда эшне оештыру тәртипләрен тырышып үзләштерә. Яшь Әйтикин Истанбул, Каһирә, Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләрендә да булып кайта.

Насреддин, Тара һәм Павлодарда кибетләр һәм күн заводы белән беррәттән, Төмән суднолар төзү верфендә үз акчасына ике буксир пароходы төзетә. «Эшче» һәм «Тара» дип исемләнгән пароходларны 1877 елда, Тубыл елгасының урта агымы суднолар йөрү өчен ачылгач, суга төшерәләр. Алар Тубыл һәм Иртеш буйлап Төмән-Тубыл-Павлодар линиясе буенча йөк йөртәләр, пассажирлар ташыйлар. Насреддин Әйтикин, абыйсы Рәхмәтулла белән берлектә, Иртештәге башка пароход компанияләренә караганда алданрак, Төмән-Симәй линиясе буенча пароход җибәрә. Бу пароходларның капитаннары итеп Әйтикиннәр Тарадан — Мөхәммәди Агафуровны, Павлодардан – Габделкадыйр Кәримовны билгелиләр. Аларның икесе дә элек бурлак булганнар, рус бурлаклары белән Ямыш күленнән Төмәнгә кадәр тоз төялгән авыр баржа һәм баркасларны йөрткәннәр. Шуңа күрә Иртешне бик яхшы белгәннәр.

Билгеле, Әйтикиннәр хөкүмәт заказларын да үтәгән. Шуның өчен патша хөкүмәте аларны почетлы гражданин исеме һәм башка бүләкләр белән зурлый. Омск өлкә дәүләт архивында 1868 елгы документларның берсендә мондый юллар бар: *«Тара шәһәренең 1 нче гильдия сәүдәгәре бохаралы* ***Рәхмәтулла Нияз улы Әйтикин*** *һәм аның энесе Насреддин, Көнбатыш Себер генерал-губернаторы һәм хәрби министр тәкъдиме белән, 1868 елның 7 июнендә, хәрби министрлыкка күрсәткән хезмәтләре өчен, патша тарафыннан Рәхмәтулла — Александр тасмасына, ә Насреддин – Станислав тасмасына беркетелгән көмеш медальләр белән бүләкләнәләр».*



Г. ПАВЛОДАРЪ.

2-й гильдіи.

Агафонова, Марія Мироновна, крупчатка хлѣбное дѣло.
Айтыкинъ, Абдулъ Фаттаховичъ, мануф. и жиров. тов.
Айнуллинъ, Али Мухаметкалѣевичъ, жир товаръ.
Айтыкинъ, Абдулъ Маликъ, жир. тов.
Акчуринъ, Абдулъ-Хакимъ, мануф. тов.

Почетлы гражданнар буларак, Әйтикиннәр җирле идарә органнарына да билгеләнәләр. Мәсәлән, 1889-1892 нче елларда Рәхмәтулла Әйтикин төрмәләр буенча Тара өяз попечительләр комитеты члены, ә Насреддин Әйтикин шул ук елларда Тара өязе салым җыю оешмасы әгъзасы була.

Сәүдәгәр Әйтикиннәр тарихын шушының белән тәмамларга да мөмкин булыр иде. Шулай да алар тарихта Россия сәүдә капиталына нигез салучы, яңа җирләр үзләштерүче, кыенлыкларга карамастан, илнең байлыгын арттыручы, башка илләр һәм халыклар белән элемтәләрне үстерүче башка байтак сәүдәгәрләрдән күпкә кызыклырак шәхес булып калганнар.

Габделфәттах Әйтикиннең оныгы **Мөнирә Гобәйдулла кызы Исхакова** (1893 елда туган) сүзләренчә, бабасы тарафыннан оештырылган китапханә Тара шәһәренең түбән өлешенә урнашкан ике катлы Әйтикиннәр йортының берсендә урнашкан була. Китапханәгә Петербургтан, Мәскәүдән, Истанбулдан, Каһирәдән, Казаннан һәм башка шәһәрләрдән газета-журналлар даими килеп тора. Китапханәне яңа китаплар белән баетуны Рәхмәтулла Әйтикин кайгыртып торган. Ул заманының укымышлы кешесе була.

1965 елның май аенда Ташкентта бу мәкалә авторларының берсе (Ф.Вәлиев) М.Г.Исхакова белән очрашып сөйләште. 1912 елга кадәр китапханәдә тарих һәм әдәбият буенча кульязма чыганаклар да сакланган. Аларны узган гасырның урталарында Габделфәттах Әйтикин җентекләп җыйган була. Бүгенге көндә әлеге кульязмаларның язмышы билгесез.

«
Габделфәттах Әйтикин 19 нчы йөзнең алтмышынчы елларында тоткынлыктагы Н.Г.Чернышевскийны беренче тапкыр коткарырга тырышучыларның берсе була.

Габделфәттах Әйтикин 19 нчы йөзнең алтмышынчы елларында тоткынлыктагы Н.Г.Чернышевскийны беренче тапкыр коткарырга тырышучыларның берсе була. Ул сөргендәге рус һәм поляк революционерлары белән бергә көрәшкә әзерләнә, шул максат белән корал сатып ала. Сорау алулар вакытында патша ялчыларына бернинди дә мәгълүмат бирми. Аның янына провокаторлар да җибәреп карыйлар, әмма файдасы булмый. Жандарм офицеры да аннан бер мәгълүмат та ала алмый. Зур түрәләр, канәгатьсезлек белдереп, үзләре әзерләгән хәйлә кармагына капмаган сәүдәгәрнең тәҗрибәле һәм хәйләкәр булуын документка теркәп куялар. Алар аеруча «татар милләтенең бер җирдә сәяси үзәге» булу-булмавын ачыкларга тырышалар.

XX гасыр башында Әйтикиннәрнең социал-демократ Ибраһим Әхтәмов гаиләсе белән туганлашуы да кызыклы. Ибраһим Әхтәмовның сеңлесе Зөһрә, Әйтикингә кияүгә чыккач та, 1902 елның язында, Тарадан абыйсына кызыклы хатлар юллый.

Әйтикиннәрнең варислары революциядән соң Советлар хакимияте ягында булалар: аларның яшь буыны илебез данын арттыруга хезмәт итә. Күбесе Бөек Ватан сугышында катнаша, хөкүмәт орден һәм медальләре белән бүләкләнә. ■

«Себергә бөек гыйльми камиллекне бүләк итеп алып кайтты»

Ризаэддин Фәхреддин

Тара мәдрәсәсенең эчке күренеше

Нияз бине Хәйдәр бине Ярымсәед бине Хәйдәр бине Гали Себердә Тара шәһәрендә яшәп, 75 яшендә 1263 (1847) елның җөмадиел-әүвәл аенда (22 апрельдә) вафат булып, Сәбаләк исемле авыл каберлегендә күмелгән.

Балалары: Габделфәттах, Рәхмәтулла, Насреддин, Нәҗмеддин һәм башкалар. Бу кемсә имамлык хезмәтендә булмаса да, чыннан да, галим вә фазыйль бер зат булып, милләтен сөяр, мәчет-мәдрәсәләргә тиешле иганә ярдәмен күрсәтер, укырга теләгән, сәләтле булган шәкертләргә үз кесәсеннән ярдәм итәр, уң кулы биргәнен хәтта сул кулы белмәс; мәҗлесләрдә һәркемнең сүзен тыңлар, бөтен мәҗлес әһелләренең барысыннан ничә мәртәбә гыйлемле булган хәлдә, һичнәрсә белмәүче кемсә кебек белмәмешкә салышып утырыр; форсат табылган вакытларда Коръән шәрифне матур итеп күчерер, хакыкый галимнәргә чын мәхәббәт итәр, зиһене тугры, акыллы, үзе вәкарьле, эшне уйлап эшләүче, аралашуда хуш бер зат иде, диләр. Үзе бөек сәүдәгәр булып, фабрика тоткан, Себернең мәшһүр

мәркәзләрендә сәүдәханәсе тәртипкә салынган рәвештә эшли иде. 1236 елда Сабанчы бине Ярмөхәммәд, Мөхәммәд бине Салих бине Шәех исемле юлдашлары белән бергә Хиҗазга барып хаҗ кылдылар; Мәккәдә хәнәфиләр мөфтие булган Габдулла бине Габдерахман әс-Сираҗ әфәнде (бу мөфти 1264 елда Мәккәдә вафат булды) белән очраштылар. Әлеге сәфәрендә Каһирәдә туктап, фазыйль голяма белән аралашып, мәшһүр галимнәр хозурында кыйраәтен төзәтеп, яхшыртып, иҗазәт алды. Себергә бөек гыйльми камиллекне бүләк итеп алып кайтты. Шуның өчен Себер мөселманнары бу затны үзләренең бабалары санап горурланалар, олысы-кечесе, ирләре-хатыннары исемен кадерләп, хәер-дога белән искә алалар.

Искәрмә: әгәр дә Нияз хаҗи хакыйкатьтә шушында язылган сыйфатта бер кеше булса, фәкать Себердә булган мөселман кардәшләребезнең генә бабалары булмыйча, бәлки, барыбызның, бөтен милләтебезнең бабасы булачак. Мондый затларны Аллаһ хисап вә җәза көннәрендә мәрхәмәте күләгәсендә рәхәт-рәхәт тотсын!.. Моның кебек мөхтәрәм бәндәләр бөтен халкыбыз өчен бетмәс-төкәнмәс горурлык, боларга бөтен дөньябыз фида вә газиз җаннарыбыз корбан булсын!.. Дөньяда хаҗилар, байлар, муллалар, мөдәррисләр, язучылар, укучы-укытучылар хисапсыздыр, әмма чынлыкта милләт бабалары булган затлар – шушының рәвешендә булганнары.

«Моның кебек мөхтәрәм бәндәләр бөтен халкыбыз өчен бетмәс-төкәнмәс горурлык, боларга бөтен дөньябыз фида вә газиз җаннарыбыз корбан булсын!.. Дөньяда хаҗилар, байлар, муллалар, мөдәррисләр, язучылар, укучы-укытучылар хисапсыздыр, әмма чынлыкта милләт бабалары булган затлар – шушының рәвешендә булганнары.

Хәтеремдә ки, муллалар җыелышы булган бер мәҗлестә өстәл башында ак сакаллы, бәһале киемле бер зат утыра иде. Хиҗаз тарафыннан яңа гына кайткан булган. Дөячеләрнең намаз укымауларын, бар нәрсә өчен түләү, өлеш сорауларын, сәдака сораучы фәкыйрьләрне, үзләренең ниләр ашап-эчеп йөрүләрен, төрекләрнең тәмәке тартуларын, Истанбул урамында булган этләрне сөйләп, ни мөнәсәбәт белән – белмим, укыту мәсьәләсенә күчеп: «Бүген яңа форма

Мәдрәсәнең тышкы күренеше

белән укыту тиешле дип сөйләгән затлар күренә, сүзләренең атасы вә анасы юк!.. Пәйгамбәребездән (с.г.в.) мирас булып бүгенгә кадәр килеп җиткән форманы үзгәртмәк булалар. Ай ахмаклар, ай ахмаклар, – димәсенме. Бер яктан, бу кемсәнең гарәп сүзләрен гаять бозып вә җимереп сөйләвеннән, икенче яктан, һичбер кемнән тартылмыйча, мактану һәм кыюлык белән сөйләгәннәреннән гаҗәпләнеп, хәйран булып тордым. Ни булса да, бер сулыш алганын форсат санап, үзенә туры карап: «Гали зат кайда белем алырга өнди соң? Мәрхәмәт итеп бәян кылса, шат вә рәхмәтле булырбыз», – дидем. Мәгәр дә хаҗи әфәнденең колаклары бик тә ишетмәс, дөресрәге дә, саңгырау, имеш. Янымда булган кеше: «Бу бит фәлән кемсә, миллионер, гаять акыллы бер адәм!» – диде. Мин дә: «Үзе мондый җаһил булган хәлдә, бердән, тәрбия мәсьәләсенә керешүе вә, икенчедән, дин вә тарих исеменнән сүз сөйләве акыллы кемсә һөнәреме булыр?!.» – дип уйладым да дәшми калдым. Мәгәр дә ысуле җәдидә тарафдары булып китсә, мәхәлләдә булган мәктәпләрне идарә иттерү вә кирәк урыннарга мал сарыф итү, фәкыйрь шәкертләргә китап вә кәгазь бирү ошбу миллионер хаҗи әфәндегә йөкләнәчәк бит. Һәм дә гаять дәрәҗәдә мал җыярга комсыз булганыннан, өлеш чыгаруны җан чыгару бәрабәренә күргәне сәбәпле, ысуле җәдидә шәригатькә каршы дигән яңа уйлап табылган мәсләккә кергән һәм бу җәһәттән барлык куркулардан котылган кебек булып утыра иде. Хәтта мәхәлләсенә бер мәдрәсә бина кылу кирәк булганнан миллионер хаҗиның парәсе кузгалмады, һәрвакыт «ахмаклар»га ярдәм итә торган, Урал тауларында алтын казучы мөселман байлары кирпечтән мәдрәсә бина салганнар, имеш. Менә шундый миллионер карт хаҗилар хәлләрен күргән-белгән вакытыбызда Нияз хаҗиларны исебезгә төшерәбез вә рухларының тынычлыгы өчен догалар кылабыз. Никадәр аз булсалар да, һәр җирдә вә һәр заманда Нияз хаҗиларыбыз, күп шөкерләр булсын, бардыр. Боларның тәрҗемәи хәлләре бу китабыбыз өчен гүзәл зиннәт булачак. «Асар»ебезгә «Өстәмә» яки «Кушымта» язачак яңа буын галимнәренә Нияз хаҗи кебек милләт бабалары турында бер дә калдырмыйча язуларын һәм дә исемнәрен хөрмәт белән телгә алуларын күңелем белән өмет итәм. ИншәАллаһ, бу өметебез тулысынча тормышка ашар. Искәрмәбез шушы урында тәмам булды.

Нияз хаҗи астролябиясе

Текстны басмага ***Рамил Миңнуллин*** *әзерләде.* ■

Себернең югалган Казаны

Наилә Галиева*

Себер табигате. ***Розалия Аптрахимова һәм Даниил Товсултанов фотолары***

Тормышыбызның билгеле бер чорында күпләребез үз гаиләсе, нәсел-нәсәбе тарихы белән кызыксына башлый. Соңрак бу туган авылның тарихын өйрәнүгә дә күчәргә мөмкин. Миңа буыннан-буынга үз нәселе тарихына хөрмәт һәм мәхәббәт тапшырыла торган гаиләдә туу һәм үсү бәхете елмайды. Әти һәм әни ягыннан ата-бабаларым Омск өлкәсенең төп халкы булмавы сәбәпле, аларның бирегә күчеп килү вакыйгалары гаилә риваятьләренә әверелгән иде. Мәктәп елларыннан ук мин үз гаиләмнең тарихын өйрәнә һәм истәлекләр җыя башладым. Иң җиңеле әнием ягыннан бабаларым – мөгаллим Хәмидовларның нәсел-шәҗәрәсен өйрәнү булды, чөнки инде ул карт бабам Ризаэддин тарафыннан күпмедер дәрәҗәдә язылган. Моннан тыш, аның көндәлекләре дә сакланып калган. Нәкъ менә шушы язмалар миңа XX гасыр башындагы вакыйгаларны яхшырак аңларга ярдәм итте.

Татарстан Республикасының элеккеге Тәтеш өязендәге Аллабирде авылында 1875 елда туып, Казан шәһәрендәге «Мәрҗани» мәдрәсәсендә белем алган Ризаэддин Сафиулла улы Хәмидовның язмалары арасында, әлбәттә, Себер турындагылары да бар. Дөрес, озак вакыт мин аларга тиешле игътибар бирмәдем, фәкать гаиләмә караган текстларны гына аерып алдым. Әмма, вакыт узу белән, язмаларда Казан авылы турында кыйммәтле чыганаклар барлыгын аңладым. Инде дөнья картасыннан юкка чыккан әлеге авыл янындагы торак пунктларда бүген дә минем бабам искә алган кешеләрнең онык-оныкчыклары яши һәм бу язма аларга да нәсел шәҗәрәсен

* **Наилә Галиева** – этнограф, төбәкне өйрәнүче, Салехард шәһәрендәге Арктиканы фәнни өйрәнү үзәге хезмәткәре.

төзүдә, борынгы бабаларының кайдан килеп төпләнгәнлеген ачыкларга, Татарстан белән туганлык мөнәсәбәтләрен яңартырга ярдәм итәр дип уйлыйм.

Кызганыч, көндәлекнең оригиналы безнең буынга кадәр килеп җитмәгән. Элегрәк карт бабам аны гарәп графикасында үз кулы белән язган булган. Соңрак бер улы кириллицага күчергән. Әлеге язмалардан сезгә дә бер өзек тәкъдим итәм: *«Без Себергә 1912 елның көзендә килеп тора башладык. Шул көздә 6 аршынлы ызба салып, башын үлән белән ябып та куйдык. Без килгәндә бу авылга һичбер исем бирелмәгән иде. Авыл халкы бу авылга Казан авылы исеме куйды. Чөнки бу авылда гел Казан халкы җыелган иде. Тәтеш өязеннән Күккүз дигән авыл кешеләре – болар Себергә башлап килеп, бу авыл утырган участокны билгеләгәннәр һәм шунда утырганнар. Янә Тургай дигән авыл, янә Аллабирде дигән авыл кешеләре, янә Әҗем авылы, янә ике йорт Чистай өязеннән, янә бер йорт Мамадыштан бар иде.*

Ризаэддин Сафиулла улы Хәмидов

Бу Казан авылы Иртышның сул ягында, Иртыштан 15 чакрым эчтә, элекке Такмык волостеның Тара өязендә иде. Казан авылы халкы биредә 1930 елга кадәр торды. 1930 ел бу авылның җирен совхоз алып, авылны таратырга мәҗбүр итә. Авылның күбесе 20 чакрым җиргә – Тозказан дигән авылга барып, колхозга керде. Без бер генә йорт, Үләнкүл дигән авылга барып, колхозга кердек. Үләнкүлдә бер ел торгач, иген булмау сәбәпле, түбән таба Иртыш белән 1932 ел 1 майда Усть-Ишим дигән авылга килдек. Усть-Ишимда бер җәй торып, аннан Ире дигән авылга – Кип-Кулларга килдек.

Казан авылында беренче землянка казып тора башлаган кеше – Миңлевәли Насыйбулла угылы, Күккүз авылыннан; 2 нче – Кәлимулла Хәмзә угылы; 3 нче – Һидиятулла Ибраһим угылы; 4 нче – Ибнеҗан Ибраһим угылы; 5 нче – Миңдулла Гыйбадулла угылы; 6 нчы – Гарифулла Ибраһим угылы; 7 нче – Гарифулла Гыйбадулла угылы; 8 нче – Дәүләтша Тимергали угылы; янә Әҗем авылыннан Мөсәллим карт; Дәүләтша Хәмит угылы; (?) Мәхмүт угылы; янә Барыш авылының Ярулла Мостафа угылы; янә Күккүз Хәйрулла Мәхмүт угылы; янә Тургай авылыннан Ганибулла Фәхреддин угылы; Баһаветдин Фәхреддин угылы; Мәхмүт Фәхреддин угылы; Җамалетдин Котмәт угылы; Мәхмүтсадыйк Җамалетдин угылы; Сәгыйдулла Динмөхәммәд угылы; Аллабирде авылының Ганикулла Гарифулла угылы; Ризаэддин Сафиулла угылы; янә Әҗем авылының Вахит Бәхтияр угылы; Дүртөйленең Гыйләҗетдин Сираҗетдин угылы; Габделҗаббар Габделгариф (?) угылы; Чистай өязе Мәхмүт Кәрим угылы; янә Тәрҗемән карт; янә Мамадыш өязенең Хәмидулла Сәгыйдулла угылы. Болар – төп Казаннан күчеп килгән кешеләр. Казан авылында 1909 елдан башлап 1931 елга кадәр торганнар».

Бабам искә алган бу кешеләрнең барысы да – һиҗрәт ачысын татыган, туган туфракларыннан аерылып, ерак Себергә, караңгы тайгага бәхет эзләп килгән игенчеләр.

Алар арасында Ризаэддин белән бергә хатыны Нәфисә, уллары Зәкәрия белән Яхъя да була. Озак та үтми, 1914 елда гаилә башлыгын Беренче бөтендөнья сугышына алалар. Ул аннан 1917 елда Февраль революциясеннән соң гына әйләнеп кайта. 1921 елгы Идел буендагы коточкыч ачлыктан качып, бертуганнары Габделхак, Самат һәм Факия дә сыену урынын биредә таба.



Картадан Казан авылы урнашкан урынны күрергә мөмкин

Бабам Себергә күченеп килү сәбәпләре хакында язмый. XX гасыр башында Столыпинның аграр реформалары һәм 1911 елгы ачлык нәтиҗәсендә Казан губернасындагы җире аз крестьяннар Себергә килеп төпләнә. Казан авылы кешеләренең дә әлеге вакыйга уңаеннан ерак тайгада нигез корганлыгы аңлашыла. Кызганыч, Казан халкының көчләп күмәкләштерелүе, мең бәлаләр белән килеп төпләнгән нигезләренең туздырылуы хакында бабам тәфсилләп сөйләми. Мөгаен, моның сәбәбе үз гаиләсе өчен курку булгандыр. Дөрестән дә, совет чорында бу турыда дәшмәү хәерлерәк була. Хәзер инде әлеге авыр һәм куркыныч көннәр турында аның балалары искә төшерә, оныкларына сөйли.

Ризаэддин Хәмидов искә алган кайбер кешеләрнең язмышларын төрле чыганаклардан ачыкларга насыйп булды: *«Гибаруллин Гарифулла. Родился в 1879 г. в д. Б-Куккуз Казанской губ. Житель д.Казанка Большереченского р-на Омской обл. Татарин, плотник. Арестован 21 июля 1937 г. Приговорен 17 сентября 1937 г. тройкой при УНКВД по Омской обл. по ст. 19-58-2-6-9 УК РСФСР к высшей мере наказания. Расстрелян 19 сентября 1937 г. Реабилитирован 29 июня 1960 г. президиумом Омского облсуда за отсутствием состава преступления. (П-8259)»*.

Бабам да репрессия корбаны. Ул гаиләсе белән Васюган сазлыкларына сөрелә: *«Хамидов Ризаутдин Сафиулович, 1875 г.р. Житель д. Казанка Большереченского р-на Омского окр. Западно-Сибирского края. Состав семьи: жена Нафиса, сын Абдрахман, 1923 г. р. Выслан вместе с сыном в 1930 г. Реабилитированы УВД по Омской обл. 25.11.2002 г. за исключением Нафисы». (ИЦ УВД по Омской обл. Ф.8, оп.5, д.807)*.

Бөек Ватан сугышында катнашучылар: *«Насыбулин Миливали, д. Казанка. Рядовой, проп. б/в.»; «Фахрутдинов Шайхитдин Багаутдинович (1901-1984), д.Тусказань. Рядовой, стрелок; ЛФ, ВФ. Дважды ранен»*.

***

Хәзерге көндә Казан авылын Омск өлкәсенең карталарында күрмәссез. Аның турында хәтта югалган торак пунктлар исемлегендә дә мәгълүмат юк. Фәкать 1912-1925 нче еллардагы карталарда гына «Казанск» һәм «Казанкий» топонимы күрсәтелгән. Бу нәкъ менә минем бабам һәм аның замандашлары нигез салган Казан авылы булырга тиеш, һәрхәлдә, географик урыны шуңа туры килә. Киләчәктә көндәлек һәм архив материаллары язмаларын чагыштырып, Казан авылы һәм анда яшәгәннәрнең язмышын тирәнрәк өйрәнергә телим. Бу кечкенә мәкаләм Казан авылының тарихын саклап калуда ярдәм итәр дип өметләнәм. ■

Безнең мирас №8 август 2021

Киң вә гали табигатьле Омски имамы

Мәрхүм Ниязмөхәммәд әфәнде Сөләйманов җәнаблары

Ниязмөхәммәд Сөләйманов тарихта исеме бик азларга гына билге имам, китап сәүдәгәре. Ул Тобол губернасына кергән Тара өязендәге Кышлау авылында (хәзер Омски өлкәсендә) туган. 1880-1882 нче елларда – Тара шәһәрендә, 1884-1887 нче елларда Петропавловски мәдрәсәләрендә укый. Шуннан соң Петропавловскида имам була. 1907 елның ахырында Омскида Хөкем палатасында тәрҗемәче булып хезмәт иткән Закир Ишмөхәммәдов тәкъдиме белән Омскига күченеп, шәһәр мәчетендә имам хезмәтен башкара. Аңа, Омски мөселман җәмгыяте икегә бүленгәч, аларны берләштерә алмау сәбәпле, бер үк вакытта ике мәчеттә дә имамлык итәргә туры килә: «бер җомганы – бер мәхәлләдә, икенчесен икенче мәхәлләдә укытып йөри». Нурмөхәммәд Сөләйманов татар матбугатында мәкаләләр яза. Ул – «Шәркый рус мәктүбләре», «Төрки хөтбәләр», «Төрки нотыклар» һәм «Садыйк әфәнде» исемле китаплар авторы.

Ниязмөхәммәд хәзрәтнең Петропавловскида китап сәүдәгәре булуы да билгеле. «Шәркый-рус мәктүбләре» исемле китабының азагына: *«Ниязмөхәммәд Сөләйманов китапханәсендә сатылмактадыр: һәртөрле мәктәп вә мәдрәсәләр өчен дәрес китаплары, Кәлям-шәрифнең Казан, Бакчасарай вә кайбер басмалары, «Һәфтияк», тәфсир, тарих, җәгърафия (география), хисап, әхлак, әдәбият, төрекчә, русча, гарәпчә әдәбия вә фәнни рисаләләр, ысуле сутия әлифбалары вә кыйраәт китаплары»*, – дигән игълан куела.

Дин галименең кызы Хәдичә Сөләйман Буби кызлар мәктәбендә укыган, соңыннан үзе дә Омскида татар һәм казакъ кызларын укыткан. Хәдичә Сөләйман Гражданнар сугышы вакытында мөһаҗирлеккә китә, башта Харбинда, аннары Япониянең Кобе шәһәрендә яши. «Яңа милли юл» журналында Хәдичәнең 1934 елда Кобега Гаяз Исхакый килүе турында хәбәре басылган: *«13 октябрь җомга көн әдипләребездән Гаяз Исхакый җәнаблары Шанхайдан «Нагасаки мару» исемле вапурда Кобе шәһәренә килеп чыкты. Ерак Шәрыкта зыялыларны күреп сөйләшергә зар булганларга кояш нуры балкып чыкты, тантаналы рәвештә алкышланды. Кобе яшьләр түгәрәге оешмасы һәм дә һәрвакыт җәмгыять эшләрендә катнашып йөрүче ханымнарның булышуы аркасында чәй мәҗлесе корылып, бөтен Кобе төрек-татарлары Гаяз Исхакый җәнабларын күрергә мәшруф булдылар. Мәҗлестә Гаяз әфәнде милләт һәм милләтчелекне ныгыту турында һәм яшь буыннарга ана телне укытырга, һәрвакыт үзебезнең Чыңгыз балалары булганлыкны онытмый иттифакта булып, көч-куәт җыеп, коллыктан котылып мөстәкыйль булуыбыз өчен тырышырга кирәклекне сөйләде. Бу мәҗлес 15 октябрь – Казан ханлыгының бетерелгән көненә туры килде. Төн урталарына кадәр таратылган мәҗлеснең ахырында Казан ханлыгын сакларга дип сугышып шәһид булганнарның рухына Коръән укып багышланды»*, – дип яза ул.

Мәрхүм Ниязмөхәммәд әфәнденең угыллары: биеге – Мәхмүд исемендә, бу мәрхүмнең үзеннән алты айдан соңра вафат итмештер. Кечеге – Мәсгуд намендә, бусы бу көндә сәламәт. Җәнабе Хак! Мәрхүмнең үзе кеби сахибел-фазыл *(гыйлем иясе)* итеп, кәнди *(аның)* өчен догачы әйлә.

***

Ниязмөхәммәд Сөләйманов заманның күп татар зыялылары белән аралаша. Габдерәшит Ибраһимов – аның якташы, замандашы. Галим Омскига килгәч, Ниязмөхәммәд хәзрәт аны каршы ала һәм шәһәр буенча озатып йөри. Имамның барлык китаплары да Петербургта, мәшһүр якташы матбагасында басылып чыга.

Н.Сөләйманов 1916 елда вафат булганнан соң, замандашлары аның турында матур истәлекләр яза. Шундый авторларның берсе – Хөҗҗәтелхәким Мәхмүтев – дин эшлеклесе, «Галия» мәдрәсәсе мөгаллиме, журналист, «Ислах көтепханәсе» журналының баш мөхәррире, «Мисбах әл-залим...», «Интикъад әл акъваль» исемле китаплар авторы. **Аның Ниязмөхәммәд Сөләйманов турындагы истәлеге 1917 елда Казанда чыга торган «Мөшәвәрәт» мөселман календарендә дөнья күрә.** Әлеге чыганактан без Омски имамының заманы өчен алдынгы, мәгърифәтле һәм күпләр өчен үрнәк шәхес булганын беләбез.

Безнең мирас №8 август 2021

Утырганнар (сулдан уңга): Габдерахман Әхмәров, Гомәр Дәүләтъяров, Һади Максуди, Ниязмөхәммәд Сөләйманов. Басканнар: Йосыф Акчура, Габдулла Буби, Лотфый Исхакый, Харис Фәйзи.

Мәрхүм Ниязмөхәммәд әфәнде Сөләйманов

Хөҗҗәтелхәким Мәхмүдов

Мәрхүм Ниязмөхәммәд бине Сөләйман бине Гәбделбакый бине Сөләйман Табул губернасы Тара өязендәге Аутуз авылыннан булып, төп Сибирия инородецларыннан булган хәлдә берничә еллар элек Петропавел мещанлыгына язылган иде.

Укуы. Иң әүвәл мәрхүм әтисеннән вә аннан соңра Табул якынындагы (Карагай авылында булса кирәк) бер авылда булынган. Аннан соң да 1880-1882 нче елларда Тара шәһәрендә мәрхүм Нәҗметдин хәзрәтләреннән вә аннан соңра 1884-1887 нче елларда Петропавелда Рәхмәтулла хәзрәт Ягмуразый хозурында, вә аның вафатыннан соңра шул мәхәлләгә имам вә мөдәррис була. Остазы мөхтәрәм дамелла Габделгазиз бине Мостафа Бигишев дәресләрен укып, 1893 нче елларда мәдрәсәдән чыкмышлардыр.

1890 нчы елларда булса кирәк, сабакташы булган Мөхәммәдҗан әфәнде Бигишев җәнаблары илә русча хәзерләнеп, городской училищеда имтихан биреп, шәһадәтнамә алганнар. Мәдрәсәдән чыккан соңында да бер тарафтан мөгаллимлек итеп, икенче тарафтан русча мәгълүматын арттырырга тырышкан вә 1895 нче елларга кадәр тәмам русчага бирелеп бөтен әдәбиятны өйрәнерлек дәрәҗәдә русча өйрәнгән иде. Мөгаллимлек итүе дә гади хәлфәләр шикелле булмаенча, бәлки, укыту ысулын тәмам тәртипкә салган булганлыктан, үзе дә һәрвакыт: *«Петропа-*

велга иң әүвәл ысул җәдидә кертүче мин булдым», – дип сөйли иде. Бу вакытларда Петропавелда кадер вә игътибары да күтәрелеп, бер тарафтан китап сәүдәсенә дә керешкәнлектән, дөньясы да яхшы ук юлга салынды. Әүвәлләре үзенең имам булырга теләге күп булмаса да, соң елларда берничә урыннан, мәсәлән, Петроградка җәмгыяте хәйрия мәхәлләсенә, Касыймда мөдәррислеккә һәм дә мәрхүм Мөнир әфәндедән Чиләбегә имамлыкка дәгъвәт ителгән, бер тарафтан Омскига да чакыралар иде. Омскига имам булырга кызыгырлык бернәрсә булмаса да, ләкин иң әүвәл үзебезнең Сибириябездә хезмәт итү теләге илә Омскига имам булып күчеп барды.



Сөләйманов Н.Шәркы рус мәктүбләре. – СПб: Габдерәшит бине Гомәр Ибраһимов матбагасы, 1905. – 27 б.

Аның матбугатта күрелгән мәкаләләре иң әүвәле «Шәркый рус»та булса кирәк. Басылган әсәрләреннән иң беренчесе 1906 елның «Өлфәт» матбугасында язылган «Мөназәрә» исемле әсәре булса кирәк. Моннан соң «Петроград сәяхәтнамәсе», «Мәктүбләрем» вә ике кисәк «Төрки хөтбәләр» һәм дә «Нотыкларым» исемле әсәрләре бардыр. Болардан башка үз тарафыннан нәшер ителгән кайбер вак рисаләре дә булса кирәк. Хөтбәләреннән соңгы кисәкләре язылган булса да, хәзергәчә басылып чыкканы беленмәде.



Н.Сөйләмановның шәхси мөһере. Аңа: «Омскида Ниязмөхәммәд Сөләйманов китап сәүдәсе», – дип язылган. «1326/1908 сәнә (ел)»

Мәрхүм үзе саф калебле, киң вә гали табигатьле, сабырлы, вәкарле бер зат иде. Ислам гыйлемендә һәм җәдитчелек мәгарифендә хөр фикерле булган хәлдә гомуми вә хосусый мәҗлесләрнең һичберсендә урынлы-урынсыз кычкырышып муллалар берлән бозылышканлыгын белмимен. Һәм шәкерт заманыннан вә мәдрәсәдән чыккан вакытларыннан башлап, хәтта дөньясы иң кысынкы булган вакытларда да һичбер кешегә баш игәне юк. Мәрхүм, хөр фикерле вә һәрбер мәсьәләгә киң караучы булуы өстенә, ислам гыйлеме вә гарәп телен яхшы белгәнлектән, иманы нык иде. Омскида торуы үзенчә бигүк күңелле түгел, мәхәллә доходы да башка шәһәрләрдәге шикелле булмаганлыктан, мәгыйшәтне үзенең оста тәдбире илә һәм дә күбрәк китап сәүдәсе илә идарә итеп барганлыгыннан, әллә нинди артык акча калдырган булыр дип булмый.

Үзеннән соң калган гаиләсе хатыны һәм дә 4-5 баладан гыйбарәт булса кирәк. Олы кызы әүвәл үзеннән, соңрак Буби кызлар мәктәбендә укыган һәм дә русча да укыган булып, хәзерендә Омски кызлар мәктәбендә мөгаллимәлек итмәктәдер.

Омскиның борынгы мәчете

Башка балалары һәммәсе дә уннан түбән яшь балалардыр. Асыл ватанында якын кардәшләре һәм бар.

Ниязмөхәммәд әфәнденең Омскида уздырган соңгы дәверендә күңел теләгәнчә рәхәтлек вә иркенлек булмады. Безнең халыкта һәр җирдә булган вак табигатьлелек, янчыкларындагы 5-10 сумнары белән мактану вә шул нисбәттә ислам галимнәренә түбән карау вә аларны үз фикерләренә генә хезмәт иттерергә теләү шикелле бозык гадәтләр боларда да булганлыктан, Омски халкы Ниязмөхәммәд әфәнде кеби мәмләкәтемездә сирәк булган галимне дәрәҗәсенә тиешле сурәтдә тәкъдир вә ихтирам итә белмәде вә шуның өчен дә ул барган көненнән бу көнгә кадәр тынычлык вә күңел рәхәтлеге илә яши алмады.

Иң әүвәлендә степь вилаятләрендәге һәр шәһәрдә булган шикелле монда да нугай-казакъ мәсьәләләре барлыкка килеп, еллар буенча дәвам итте. Казакълар, волость партиялеге ысулы илә илдән сөрү-сөрү казакъ китереп, мәхәллә дәгъвәләштеләр.

Нигездә, Духовный собрание карамагында булынган, халык өчен хөкүмәт тарафыннан салынган мәчетне, казакъ мәхәлләсе исеменә күчертеп, Степное положение астына кертергә тырыштылар, соңра татарлар үзләре дә ике фирка булып, дәгъвалашырга тотындылар. Әлегә кадәр шул мәсьәләнең тәмамилә хәл ителгәне юк. Шуның өчен Ниязмөхәммәд әфәнде, мәктәп эшләренә дә һич катнашмаенча, һәммәсен попечительләр кулына тапшырып, үзе бер читдә торды вә гомеренең иң соң көненә кадәр ялгызы уку-язу илә мәшгуль булды.

Кереш мәкалә һәм текстны журналга
***Азат Сәйфетдинов** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Минем соңгы археологик табышым…[1]

Миркасыйм Госманов

Миркасыйм Госманов (уңнан өченче) КДУ галимнәре һәм студентлары арасында. 1961 ел

Август-сентябрь, 1962 ел.

28 июньдә 6 кеше Казаннан киттек. «Клара Цеткин» теплоходы белән. Юлда эшләп булмады, шулай да «Киек эзләреннән» дигән сериядән 3 хикәянең карамасын яздым…

31.07.1962.

Сарай-Бәркә хәрабәләренә килдек. Мәскәүлеләр килгәнче 3-4 көн киләп сарып йөрдек.

4.08.1962.

Мәскәүлеләр килделәр, 30лап кеше. 5 августтан башлап эшкә тотындык.

10.08.1962.

Казылма бик хәерче… Мин тапкан бер «сөңге башы»н исәпләмәгәндә, бернәрсә дә юк диярлек. Тиле яһүд Вайнерның уйлап чыгарган «манара»сында (бер дә манара түгел!) тагын берәр атна ахмак булырга туры килер. Дурак!

[1] Идел буе археологик экспедициясе көндәлегеннән кыскартып тәкъдим ителә.

14.08.1962.

Менә ярты ай узып та китте. Көндезен, дөресрәге, Мәскәү вакыты белән көндезге бергә хәтле сукыр тычкан күк җир чукыйбыз, ә төштән соң су керәбез, балык тотабыз. Балык!..

Һәр көнне диярлек 6-7 балык. Кайбер көнне 5-6 калкан була! Хозур яшәсен Актүбә!

16.08.1962.

Бүген әллә ничек чирләп торам. Кәеф юк. Ятам.

Хәсрәт «манара»ны бүген бетерәләр бугай... Чәнчелеп китсен. Мин археолог булсам, анда вакыт та, акча да әрәм итеп тормас идем.

Ярар, Вайнерга ялган сатарга азрак булыр әле...

Бүген кичен дежур торам. Ә кәеф юк...

18.08.1962.

Лагерьдан 3 км җирдә сыер сарае салалар иде. Шунда әллә нинди сөякләр табылган. Безнең И.В[айнер] (тиле) шуны казырга уйлап (нәрсәсенә кызыкты икән ул сөякнең), шул сыер абзарының эчен казый башладык. Туфрак – масса, сөяк – аз. Ә И.В[айнер] әтәчләнә генә.

22.08.1962.

Кичә бер каберлек ачылган иде, аның яртысы стена астында булып чыкты, мин җир стенаны уеп казый башладым. Мәетнең баш очында әллә нинди чүлмәк күренә башлады, мин уекның астына карап казырга тотындым...

Кинәт әллә нәрсә өстемә капланды, бөтен дөньяны караңгылык каплаган кебек булды – бер ярым метрлы җир ишелеп, мин балчык астында калдым. Һушымны югалтмадым, чөнки йөзтүбән ятып, терсәгемә таянган килеш калганмын, ягъни күкрәк астында суларлык һава калган. Бөтен дөнья караңгы иде. Мин үземнең якты дөньяны күрәчәгемә ышандым, чөнки безнең егетләр анда бик күп иде. Берничә мәртәбә кычкырып та җибәрдем бугай. Сулыш кысылып, тыным буыла башлады. Өстән бик нык баса, хәл бетә. Аңымны җуям дигән арада, иптәшләремнең тавышлары ишетелде һәм борынга саф һава бәрелде. Бу беренче сулыш иң саф, иң шифалы, иң хозур сулыш иде... [Г. А. Ф[едоров]-Давыдов И.В.-ның җәзасын биргән, күрәсең, ул әйләнә дә бөгәрләнә... Сатлык!]

Күпме ятканмындыр, аны белмим, әмма, миңа калса, бер гомер узып, икенчесе башланган кебек... Иптәшләрнең әйтүләренә караганда, 5-6 минут күмелеп ятканмын. Билгеле, бөтенесе бик нык курыкканнар иде!..

Шулай итеп, тарих өчен каберлекләр казыйм, дип, үзем дә кабердә ятып чыктым. Әгәр хорафый кеше булса, бу «Ходайның каргышы» булып күренер иде...

Һәрхәлдә, мин бик җиңел котылдым: 3-4 кубометр туфрак басып мускулларны изгәләве генә булмаса (аркалар, уң як кабыргам, сул кул, сул аягым һәм җилкәм ярыйсы гына авырта), үлемнән дә, сыну фаҗигасеннән дә котылдым... Ә тәннең авыртуы 3-4 көннән бетәчәк. Гомумән, зарыгып көтүче хатынымның, корсактагы баламның бәхетләре бар икән. Начар ата булсам да, бар ата булыйм... Яшерен генә елап алдым. Шатлыктан...

Хәзер түшәктә ятам...

25.08.1962.

Бүген ял. Ләкин мин бик иртә уяндым. Йоклап булмый. Төрле уйлар томаны томалады...

Менә дүрт көн инде, җир астында булып чыккач, чатырда тик яттым. Укыдым. «Киек эзләреннән» исемле китабыма берничә хикәя дә сызгалап куйдым. Бик эшлисе килә бу әсәр өстендә: мин аны 1957 нче елларда башлаган идем, хәзер якынча 13-14 хикәянең караламасы бар. Якынча яртысы булыр...[2] Иртәгәдән эшли башлыйм. Ләкин күпкә хәтле әле балта-көрәккә тотынып булмас...

Безнең отряд командиры И.В. бик әшәке кеше икән: костырырлык дәрәҗәдә ялагай, ләкин түзәм хәзергә. Минем авария аңа бик зур сабак булды бугай: шапырынуы кимеде...

27.08.1962.

Бүген эшкә чыктым. Җиңел генә ул-бу белән шөгыльләндем. Көч тә, хәл дә юк, тиз арыйм. Гомумән, Сармат кабере танытты үзен...

2.09.1962.

Ял. Хәзер яңгыр ява. Иртәнге якта елгага барып ике судак тотып кайттым. Бик аз калдык – 13 кеше. Көннәр начар булгач, кәеф тә шәптән түгел... Әйтүләренә караганда, элекке профессор Туган-Барановскийның малае килгән, имеш. Минем белән бик кызыксына, имеш. Нигә? Кичен сөйләшербез.

3.09.1962.

Т[уган]-Барановский[3] начар кеше түгел кебек; китаплар да яза икән, ләкин күбрәк бөгештереп җибәрә малаең. Алтын Урда тарихы белән кызыксына икән...

8.09.1962.

Быел берничә җирне казыдык: 1) былтыргы №2 казылманы; 2) мине җир басып калган сыер абзарының эчен; 3) И.В. уйлап чыгарган хәсрәт төрбәсен (хәер, аннан XX гасыр әйберләре шактый чыккан; чыккан, дим, чөнки мин үзем ул казуда эшләмәдем, авырый идем) һәм 4) былтыр казый башлаган «валны» (№10 раскоп). Соңгы участокта әйберләр күп табылды. Шулай да канәгатьләнерлек түгел. Хәер, бер әйбәт кенә хәнҗәр чыкты, мин казыган каплан.

Көннәр бер көе уза. Көндезләрен эшләп, кичләрен балык тотабыз. Мин быел да зур судак тоту буенча рекорд куйдым! Балыкчыларның күзләре янды!.. Их, соңра үзем дә төштә генә күргән кебек булырмын.

14.09.1962.

Кичә эштән кайтышлый, бер чуен кисәкләре яткан җиргә очрадым. Җентекләп карагач, җирдән чыгып яткан казан кырые күренгән иде. Бүген башлыкларга әйтеп казыган идек: төгәл бер казан килеп чыкты. Шәп! **Материаллар табуда да рекорд куйдым: бу Европадагы бөтен казаннарның иң беренчеседер, чөнки моңарчы Болгарда да бөтен казан табылмаган икән!..**

Беренче казан – минем соңгы археологик табышым...

---

[2] Госманов М. Киек сукмаклары: аучылык, киекләр һәм табигать турында язмалар. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1966. – 94 б.

[3] Сүз язучы Михаил Михайлович Туган-Барановский (1902-1986) хакында бара. Ул Литва татары Гайшәгә өйләнә. Аларның уллары Жучи (1948-2015) – тарихчы, Волгоград дәүләт университеты профессоры.

16.09.1962.

Эшләрне бетердек. Иртәгә китәбез. Бүген көндез Маләй[4] дигән татар авылына барып, җырлар язып алып кайттым. Ярыйсы гына матур әйберләр. Иртәгә сәфәр!..

17.09.1962.

Көндезге берләрдә Волгоградка килдек, йөкләрне музейга төшерешкәч (монда Алтын Урда буенча күргәзмә булачак), иптәшләр белән саубуллашып, елга портына киттем. Шушы айның 2-3ләрендә Мирфатыйх абый Зәкиевкә хат язган идем, Әстерхан архивына керер өчен таныклык сорап, чөнки миңа кайчан да булса ул архивка бер килергә кирәк булыр иде, шуңа күрә мин хәзер барып разведка ясарга булдым. Махсус килгәндә, нәрсәләр барын ачыграк белер өчен. Мирфатыйх абый бик әйбәт документ җибәргән (ул числоның уннарына килеп җиткән иде, уңган кеше шул Мирфатыйх абый). Менә хәзер «Герцен» теплоходында китеп барам. Иртәгә анда булачакмын. Анда 3-4 көн булырмын. Теплоходка утыру белән душка кереп юындым: и сагынганмын җылы суны! Шундый рәхәт каһәр суккан комнан соң... Кайбер киемнәремне юдым...

Теплоходта баруы бик рәхәт!.. Ләкин өйгә дә кайтасы килә: сагындырган, шайтан алгыры...

Заманага

17.09.1962.

Өнсез, телсез ята вәйран хәрабәләр,
Заманалар адымыннан карап алар.
Вакытында бу бер олуг дәүләт булган,
Вакыт килеп, вакытлардан ул да тузган...

Минем алда кеше башы, төпсез күзле,
Кайчандыр ул булган, беләм, телле-сүзле;
Әмма хәзер авызына туфрак тулган –
Ышанам ки, өмет-нәфесе аның туйган.

И замана, серле дә син, төрле дә син,
Күз яшедәй пакь һәм тәмам керле дә син!
Яллап-айкап бик күпләрне вәйран иттең,
Авызың ачып, хәзер инде кемгә җиттең?

Үз башымны кайгыртмыймын, уйлама һич:
Нурлы күзләр сүнәчәкләр иртә йә кич.
Тәгам ташкан авызыма тулыр туфрак,
Тәнкәйләрем үрләп үсеп, булыр яфрак.

---

[4] Маләй (Маляевка) – Волгоград өлкәсендәге татар авылы.

Әмма хәзер әйт, замана, кемгә җиттең,
Кайсы илне нәүбәт көткән корбан иттең?!

***

Чишәлмыйм сорау элмәген:
Матурмы булган күлмәге?
Эчкәнме хәмер йә әйрән?!
Калган тик сынык чүлмәге...

21.09.1962.

Кич сәгать 6да «Воровский» теплоходына утырып, Казан тарафына сәфәр тоттым.

Әстерханда булган 3 көн бушка узмады: архив материаллары белән таныштым – бик бай, бик борынгы, бетмәс хәзинә! Бу өч көндә, әлбәттә, бөтен фондлар белән танышырга мөмкинлек булмады, нибары ике генә фондтан 40лап дело карадым; шулай да архивның байлыгы турында шөбһә юк. Исәнлек булса, киләчәктә махсус килеп, айлар буенча өйрәнеп, кирәкле материалларның фотокопияләрен алырга туры килер.

...Ә хәзер кайтып барам. 1 класс каютада берүзем: чиста, аулак, күңелле! Ике ай комда ятудан соң җәннәт диярсең!

25.09.1962.

Иртәгә, ягъни 26 сентябрьдә иртәнге 6да Казанга килеп җитәчәкмен. Пароходта баруы бик күңелле булды. Ашадым, эчтем, йокладым, палубада «ак күмәч белән һава ашадым»! Көненә бер 4-5 сәгатьләп утырып, аучылык истәлекләрен язам. Кайбер кыска хикәяләр ярыйсы гына уңышлы чыга кебек. Ләкин, кем белсен, укучылар ничек каршылар? Ә минем өчен ул истәлекләр бик кадерле! Искә төшерә язган чакларымда яңадан бер дулкынланып алам!..

Фарсы теле белән шөгыльләнәм. Тел өйрәнер өчен яшьнең узган булуы күренеп тора: хәтер сиземсезләнгән...

Тәүфикъ әл-Хәкимнең «Рухына кайтуы»[5] исемле романын укыйм. Шәп әсәр, бик сөйкемле юмор.

Һәрхәлдә, әйбәт кенә эшләдем бу 4-5 көнне, өстәвенә, бик начар түгел ял иттем. Чисталык, комфорт. Әйе, беренче класста баруы бик шәп! Уңайлы пароход өчен чехословак дусларга кычкырып рәхмәт әйтәсе килә!..

Иртәгә иртә белән Казанга җитәм; шулай итеп, археологик экспедициягә нокта куела...

Сәлисәм каршы алырмы икән? Былтыр бу вакытта ул бары таныш кыз, бик артып китсә, кәләшем генә иде, ә хәзер хатыным. Йөкле хатын бик сөйкемле булырга тиеш.[6] Күз алдыма булачак миһербанлы ана килеп баса... Их, хәят, кызык син!..

Көндәлекне басмага ***Диләрә Госманова*** *әзерләде.* ■

[5] Тәүфикъ әл-Хәким (1898-1987) – Мисыр язучысы, «Возвращение духа» исемле атаклы роман авторы.
[6] М.Госмановның олы кызы Айсылу 1962 елның 12 декабрендә туган. Хәзерге вакытта ул КФУ галиме, микробиолог.

Безнең мирас №8 август 2021

Бибимаһруй Үтәмешеваның кабер ташы

Айдар Гайнетдинов

Бибимаһруй Исхак кызы Үтәмешева – атаклы татар династиясе вәкиле. Аның нәсел-шәҗәрәсе мондый: беренче вариантта – Бибимаһруй бинте Исхак бине Муса бине Габдулла бине Габдессәлам бине Үтәмеш бине Ишмән бине Туктаргали бине Көчек бине Тәбеҗ; икенче вариантта – Бибимаһруй бинте Исхак бине Муса бине Габдулла бине Габдессәлам бине Хәлил бине Йосыф бине Ишмән бине Туктаргали бине Көчек бине Тәбеҗ бине Кодеш бине Сөләйман Кирмәни. Бибимаһруй Үтәмешева 1862 елның апрелендә дөньяга килгән. Ул башта Габденнасыйр Курсавиның абыйсы Габделхаликъ хәзрәттә, аннары аның оныгы Гайшә абыстайда укыган, гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнгән. 1882 елда Бибимаһруй дин галиме Галимҗан Барудига кияүгә чыккан һәм укуын ире карамагында дәвам иткән. Бибимаһруй Үтәмешева 1889 елда үзе дә кызлар укыта башлаган, соңра кызлар мәктәбе ачкан һәм анда яңа (җәдиди) ысул белән мөгаллимлек иткән. Атасыннан калган байлыкны ул мәгарифкә һәм хәйриячелеккә тоткан, үзеннән соң бик күп изгелекләр калдырган.

Р.Фәхреддин Бибимаһруй абыстайның һиҗри 1322 елның 2 рабигыль-әүвәлендә 42 яшендә бакыйлыкка күчүен теркәп калдырган. Ире Г.Баруди язганча, ул шул елның 3 рабигыль-әүвәлендә, милади 1904 елның маенда озак авыруыннан бакыйлыкка күчкән һәм Казанның Яңа Бистә зиратына җирләнгән. Аның кабер ташы хәзерге көнгә хәтле чагыштырмача яхшы сакланган. Текстының укылышы мондый:

Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Мулла Галимҗан
2) әл-Баруди хәлиләсе
3) 42 йәшендә Бибимаһруй
4) бинте Исхак кызы
5) 3 нче рабигыль-әүвәлдә
6) 1322 сәнәдә вафат».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:
1) «Мулла Галимҗан
2) Барудиның сөеклесе
3) Бибимаһруй Исхак
4) кызы 42 яшендә
5) һиҗри 1322 елның 3
6) рабигыль-әүвәлендә вафат».

Таш үлчәмнәре: 114(144)x33x22.

Язучы, педагог, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Шәһәретдин Шәрәф Бибимаһруй абыстай хакында болай язган: *«Маһруй ханым үзенең акылын, сәләтен һәм булган кадәрле мәгълүматын үзенең җенестәшләре булган хатын-кыз галәменең агаруына сарыф итте. Шулай ук үзенең байлыгын да халыкның агаруына, тәрбия һәм укытуның таралуына сарыф итте».* ■

Безнең мирас №8 август 2021

Омскидагы татар матбугаты

«Азат Себер» газетасы



«Азат Себер» газетасы

«Азат Себер» 1919-1921 нче елларда – Омск, 1921-1936 нчы елларда Новониколаевск (Новосибирск) шәһәрләрендә нәшер ителә. Матбугат белгече Исмәгыйль Рәмиев әлеге газета турында: *«1919 елның 23 декабрендә Русия коммунистлар партиясенең Омски вилаяте комитеты янындагы мөселман секциясе һәм Омски ревкомитеты тарафыннан чыгарыла торган әдәби һәм сәяси татарча гәзитә булып, Себер өлкәсендә Колчак бандалары таратылганның соңында чыга башлады. Себердә чыгарылган гәзитәләрдән иң озак дәвамлысы һәм төп гәзит булып шушы калды. Төрле форматта, атнага бер-ике тапкыр чыкты. Бу гәзиткә нигез салучы Фәхри Әхмәдов булып, соңыннан идарәсе Новониколаевск шәһәренә күчерелгәч һәм гәзит тә РКПның Себер бюросы янындагы татар-казакъ бүлеге һәм Себер ревкомы нашире әфкяре булып әверелгәч, аңа Муса Йосыпов мөхәррирлек итте. Хәзерендә җаваплы мөхәррире – Сарим Фәхри»,* – дип яза.

«Азат Себер»не ил күләмендә билгеле татар матбугатына, Себер өлкәсе газетасына әверелдергән кеше **Муса Йосыпов** була. *«Утырып эшләргә иркен форсат булмауга, күп вакыт, ат өстендә язган кебек, ашыгыч үтәргә мәҗбүр булуларына карамастан, бу революция безгә яхшы итеп гәзит алып барырлык мөхәррирләр тудырды... Ерак Себердәге Муса Йосыпов... — болар барысы да бервакыт винтовка, аннан бушаган арада каләм тотып яза килгән яшь, яңа пролета-*

Газетаның баш мөхәррире Муса Йосыпов

Газетаның җаваплы мөхәррире Сарим Фәхри

рий мөхәррирләредер», – дип яза аның хакында Галимҗан Ибраһимов. Себердә чыныккан **Муса Йосыпов Уфада татар телендәге «Башкортстан» һәм «Яңа авыл» республика газеталарының мөхәррире була,** Казанда Татар педагогия институты директоры (1933-1934), Татар дәүләт академия театры директоры (1934-1937) вазыйфаларын башкара.

1921-1923 нче елларда газетага кушымта булып «Яшьләр сәхифәсе» журналы, 1933-1934 нче елларда «Яңалифче» журналы һәм «Яңалиф походы» газетасы чыгуы билгеле. «Азат Себер» үз укучыларын сәяси һәм икътисад яңалыклары белән таныштыра, мәгариф, мәдәният һәм Идел буендагы ачлык мәсьәләләренә урын бирә.

Игътибарыгызга газетадан кайбер өзекләр китерәбез.

Омскида

Гыйнвар аенда яшь коммунистлар оешмасы каршында булган һәвәскәрләр труппасы тарафыннан татар балалары йортлары файдасына спектакль булып үтте. Тамашага «Азатлык өчен көрәш» дигән 3 пәрдәлек инкыйлаби пьеса һәм «Адашу» дигән бер пәрдәлек комедия куелды. Уйнаучыларның бу спектакльгә ашыгычлык белән, кыска вакыт арасында хәзерләнүләрен игътибарга алган вакытта, драма да, комедия дә – һәр икесе шома гына уйналдылар. Спектакльдән калган саф файда ике миллион биш йөз мең сум «Балалар йортларында эшләрне яхшырту комиссиясе»нә тапшырылды.

Азат Себер. – 1922. – 21 февраль.

Ач балаларга ярдәмгә әзерлек булырга тиеш

Волга буендагы ачлык дәһшәте кыш дәверендә күзгә ачык бәрелеп тормады. Узган көздә һәр көн тимер юлыннан агылып тора торган ачлар кыш керү белән тукталды яки сизелерлек рәвештә булмады. Ач балаларның да шалун-шалун* килүләре бераз туктап торды. Ачлыкның дәһшәте турыдан-туры күзгә бәрелеп тормый иде. Телеграмм һәм хәбәрләр генә Себер гражданнарына аз тәэсир иттеләр. Алар ачлыктан берсен-берсе ашарлык хәлгә килгән Волга буе ачларына, сораучыга сузган ике тиенне бирү белән канәгатьләнделәр. Алар өстләренә төшкән гражданлык бурычына бик салкын карадылар.

Ләкин моннан соң болай булырга тиешле түгел. Кыш узды. Җылы вакытлар якынлаша. Озакламый тимер юл буена Волга буендагы ачлар тезелә башларлар. Без бу ачларны көтәргә тиешбез. Чөнки боларның килүләрен һичбер төрле куәт туктата алмаячак. Кыш буе ачлыктан-ялангачлыктан кеше ашый башлаган, рәхимсез суыклык сәбәбеннән китә алмый калган ачлар төрле якка, беренче мәртәбәсендә үк Себергә юнәләчәкләр.

Узган елның көзендә тәртипле рәвештә Себергә 5-6 мең бала китерелгән иде. Тәртипсез рәвештә кыш буена 25 меңләп ятим, ач балалар килде. Бу ел тагын 30 мең бала килүе көтелә. Димәк, бу балаларның барысы йөз меңнәргә җитәргә тиеш.

Безнең өстә авыр мәсьүлиятле *(җаваплы)* эшләр тора. Бу балаларның күбесе татар-башкорт балалары булачак. Волга буеның алдагы көндәге чәчәге булган бу балаларны коткару эше, һәрбер гражданның бурычы булган кебек, Себер татарказагы һәм башкортларының да беренче вазыйфалары-бурычлары.

Себер гражданнары, калачак балаларына үзләрен Себер тарихының кара сәхифәләрендә күрсәтмәс өчен һәм адәмчелек намына бөтен көчләрен сарыф итеп, ачлык сәбәпле һәлакәт алдында тора торган яшь буынны коткарырга һәм алып калырга тырышырга тиешлеләр.

Ачның хәлен тук белми, диләр. Ләкин моннан соң белергә, ачлыкның нинди дәһшәтле нәрсә икәнен аңларга кирәк. Шул вакытта гына без ач балаларны саклап алып кала алырбыз. Без, бөтен бер илне һәлакәттән коткару, ач балаларны саклау өчен үзебезгә кирәк нәрсәләрдән өлеш чыгарсак кына, киләсе көндә газапланачак вөҗдан газабыннан котылачакбыз.

Азат Себер. – 1922. – 1 май.

Ачлыкның нәтиҗәләре

Татарстанның хисап алу идарәсе «Крестьян хуҗалыкларын барлап чыгу» дигән әсәрен тәмам иткән. Бу әсәрдән карап 1920 ел белән 1922 елның февраль ае арасында нинди аермалар булганлыгын күрергә мөмкин.

Халык саны 1920 елда Татарстанда 2 миллион 640 мең кеше булган. 1922 елда 2 миллион 230 меңгә калган. Шул вакыт эчендә 400 мең кеше (15 процент) кимегән. Ирләр күбрәк кимегән. Шул вакыт эчендә 234 мең (20 процент) ир, 176 мең хатын-кыз (12 процент) кимегән. Җөмһүрияттән чит вилаятьләргә чыгып китүче ирләр дә шул хисапта.

* Шалун – эшелон.

Күпме үләләр? Ачлыкка кадәр мең кешедән ел саен 29ы үлеп торган. Ачлык вакытында (1922 ел, февраль) бер меңнән 122 кеше үлә башлаган. Ел саен туганнарның саны меңгә 43 туры килә. Димәк, үлүчеләрнең саны бер меңгә 80 туры килә. Шул вакыт эчендә төрле авырулардан – 43 мең кеше, ачлыктан – 102 мең кеше, барысы 145 мең кеше (6 процент) үлгән.

«Омскида хәрби, иҗтимагый, әдәби башкорт милли газетасы татар телендә 1919 елның 19 октябреннән чыга башлый.

Терлек-туар бигрәк тә күп кимегән. Бердән, аларны ашатырга азык булмаган, икенчедән, терлек-туар суелып ашалган. Сарыкларның 80 проценты, кәҗәләрнең яртысы (24 мең баш калган); үгез, тана, бозауларның 85 проценты беткән. Эре мөгезле хайваннарның 266 меңе кими, сава торган сыерлар 160 мең башына калган. Эшче атларның 65 проценты бетеп, 1922 елның февраленә 147 меңгә генә калган. Кеше көче 16 процентка, хайван көче 75 процентка кимегән. Шуның нәтиҗәсендә чәчү җиренең күләме дә, аерым хуҗалыкларның саны да азайган.

Азат Себер. – 1922. – 4 июль.

Казан авылында

Тара өязендә Казаннан күчеп килүчеләрдән җыелган кечкенә (50 йортлы) Казан авылында мәктәп электән үк дәвам итсә дә, матди ягын тәэмин итәрдәй берәр мөәссәсә *(оешма)* кулында булмаганлыктан, уку исемендә генә. Шуралар хөкүмәте вакытында мәктәп хөкүмәт карамагына күчсә дә, укытучыларның ел саен алмашынып торуы, укуларның соң башланып, иртә тукталуы вә башка шундый сәбәпләрнең булуы аркасында, 1921 елга кадәр укулар һаман тигез эзгә төшә алмаган иде. 1921 елдан башлап ике укытучы (мөгаллим, мөгаллимә) өзлексез укытып киләләр, бу арада мәктәп беркадәр юлга салынды. Бу өч елның әүвәлге икесендә мәгариф шөгъбәсеннән ярдәм бик аз булса да, авыл халкының ара-тирә ярдәмнәре аркасында мәктәпнең кайбер таләпләре (дәреслекләрдән башкасы) үтәлә килде. Балалар өчен әдәбият кичәләре, халык өчен дә аң-белем тарату эшләре, зурлар мәктәбе вә башка шундый эшләр эшләнде.

Бу уку елында бер укытучының Омски шифаханәсендә ятуы сәбәпле, 22 декабрьгә чаклы алтмыш балалы мәктәп ялгыз бер мөгаллимә карамагында калган иде. Бу вакыт эчендә аның артык мәшгуль булуы аркасында, мәктәптән тыш эшләр эшләнмәде. 22 декабрьдән (укытучы кайтканнан) башлап мәктәптән тыш эшләргә дә көч куела башлады. Яңа елдан соң зурлар курсын ачу, аң-белем тарату эшләре планга куелды.

Бу ел мәктәпнең күп кирәге җитешә. Бер укытучыны, дәреслекләр һәм башка уку әсбаблары белән тәэмин итүне волость ярдәм комитеты үз өстенә йөкләде. Шул ук комитет мәктәп өчен бер бина бирде. Ләкин бина мәктәп өчен кечерәк күләмле булганга, киләсе елга «Халык йорты» итеп күтәрергә уйланыла.

Азат Себер. – 1924. – 22 март.

«Каһарман башкорт» газетасы

№ 2. Воскресенiе 26-го Октября 1919 года.

КАҺАРМАНЪ БАШКУРДЪ

(ГЕРОЙ — БАШКИРЪ).

Башкирская военная, общественная, національная и литературная газета.

Адресъ Редакціи: Омскъ, Госфортовская улица, д. №3., Тел. № 50-6

قهرمان باشقرد

روسیه‌نی بالشیویزم هم فتنه‌دن قوتقارغانده غنه باشقرد یاشای آلاچاقدر!

Только при освобожденіи Россіи отъ большевизма и бунта Башкиры могутъ существовать!

رسمی قسم

غراماتاسی

Омскида хәрби, иҗтимагый, әдәби башкорт милли газетасы татар телендә 1919 елның 19 октябреннән чыга башлый. «Каһарман башкорт»ның шигаре: «Русияне большевизм һәм фетнәдән коткарганда гына башкорд яшәй алачакдыр!» И.Рәмиев, «имля, өслүб, фикерендә үрнәк итеп», газетаның 1 нче номерыннан әлеге юлларны күчерә: *«Русиядә күпчелек тәшкил итүче рус халкы илә дустанә мөнәсәбәттә торып, аның куәтерәк булган таифәләренә таянып эш күргәндә генә, башкорт халкы үз мәгыйшәтен үзе алыр. Шул сәбәпле башкорт халкы үзенең өч йөз илле еллар бергә дустанә яшәп килгән күршеләренең Русия мәмләкәтен төзү юлына ярдәмгә дәртле җегетләрен мобилизовать итеп йибәрде. Башкорт халкы исеменнән мәйданга чыгып, казаклар илә башкортлар арасында күп күңелсезлекләр чыгаруга сәбәп булган авантюрист Вәлиди хөкүмәтен ыргытып ташлап, Русия халкын талаучы вә динсез большевиклар тырнагыннан коткарып, тәртипле сурәттә иркен вә якты тормышка йиткерүне өстенә алган вә дөньяның иң бөек дәүләтләренә таянып эш күрүче адмирал Колчак хөкүмәтен танып, аңа ярдәм итәргә тотынды. Большевиклардан һәм Вәлиди авантюрасыннан котылгач, башкорт вәкилләре, тәкрар (кабат) мәртәбә Омскига килеп, Верховный правитель һәм хөкүмәт алдында башкорт халкының кирәкләрен гарыз иттеләр (белдерделәр), ризалык та алдылар. Шул эшләребез һәм большевикларның кылган золым вә вәхшәтләре хакында хәбәрләр йиткереп тору нияте илә шушы гәзитәне нәшер итәргә башладык. Ходай насыйп кылса, бу гәзитә башкорт вәкилләре арасында чыгып торачак».*

Газетаның баш мөхәррире Мөхәммәтгабделхәй Корбангалиев

Колчак армиясе Омсктан чигенгәч, газета Иркутск шәһәрендә чыгуын дәвам итә.

Газетаның баш мөхәррире Мөхәммәтгабделхәй Корбангалиев мәгърифәтче, җәмәгать, сәясәт һәм дин эшлеклесе, мөһаҗирлектә Япониянең беренче мөфтие, Токио мәчетен нигезләүчеләрнең берсе (1938) була.

***

Шунысы игътибарга лаек: Омскидагы татар телле матбугатны казан һәм себер татарлары, кыргыз-казакъ, үзбәк, башкорт халкы яратып укыган. XX гасырның урталарына кадәр биредә татар теле төрки халыклар өчен уртак аралашу теле булган.

Рәйсә Шәрәфиева *һәм* ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Троицк байларыннан Габделвәли Яушев

Габделбари Баттал

Троицк татар мәгарифе һәм мәдәнияте тарихында зур урын алып торган шәһәр. Биредә мәшһүр эшкуарларыбыз һәм зыялыларыбыз яшәгән, данлыклы «Рәсүлия» мәдрәсәсе эшләгән. Бөек Тукаебыз да, кымыз эчеп дәваланыр өчен, Троицк сахраларына килгән.

1911 елда тарихчы, үзе дә Троицкиның «Рәсүлия» мәдрәсәсен тәмамлап, шунда ук мөгаллим булып эшләүче Габделбари Баттал хәйрияче һәм эшкуар Габделвәли Яушев хакында китап яза. 1912 елда әлеге хезмәтен Оренбург шәһәренең «Вакыт» матбагасында бастырып та чыгара.

Габделвәли Яушевның эшчәнлеге бүгенге татар байларына да үрнәк булганлыктан, 110 еллык тарихны кичкән әлеге китапны хәзерге заман укучысына да тәкъдим итәргә булдык.

Редакциядән

Габделвәли Әхмәтҗан угылы Яушев

Мөкаддимә *(сүз башы)* урынына

Габделвәли Яушевның туган йорты

Троицк байларыннан вә хәйрат ияләреннән Габделвәли Яушевның тәрҗемәи хәлен «Асар»га кертү өчен, Ризаэддин хәзрәт, шуның өчен мәгълүмат җыйдырып җибәрүләрен үтенеп, хәзерге Яушевлар тиҗарәтханәсенең *(сәүдә йортының)* патроны *(хуҗасы)* булган Муллагали әфәнде Яушевка хат язган; ләкин, ни өчендер, бу хат җавапсыз калган. 1910 елның җәендә мин Троицкига килгәч, Ризаэддин хәзрәтнең бу теләген Габделвәлинең угылларына сөйләдем. Алар, ошбу тәрҗемәи хәлне яздыруга карар биреп, бу хезмәтне миңа тапшырдылар. Мин моны «Асар»га кертерлек рәвештә язып бетереп, инде җибәрдем дип торганда, «Асар» оригиналларының конфискацияләнүен газеталардан укыдык.

Габделвәлинең балалары: «Аерым рисалә *(җыентык)* итеп бастырсак ничек булыр икән?» – дидекләреннән, бу турыда киңәш итеп, Ризаэддин хәзрәткә мәктүб *(хат)* яздым. Мәктүбемә каршы ошбу җавапны алдым: «Габделвәли тәрҗемәсен язып бетерүегез өчен шатландык. «Асар»ның ни вакыт кайтуы мәгълүм түгел, сәламәт кайтуы да шөбһәле. Кәгазьләре тегелмәгән, бит саннары куелмаган иде. Мөкаддимәсен *(кереш өлешен)* язып тәмам иткәннән соң: «Имде бит саннарын иртән торгач куярым», – дип калдырып урыныма яттым, шул кичәдә мәгълүм афәт килде. Иртән битләрен тәртип итеп, сәгать 10да үз хозурымда «Бисмилла» куйдырып, хәреф җыярга башлатмак хыялыннан идем, фәкать насыйп булмады. Сезнең язганыгыз, иншәАллаһ, үзенә мөстәкыйль бер рисалә булырга ярар, булган нәрсә тик ятмасын, ихтимал, безнеке кеби булмаса да, башка бер афәт килмәктән иминият юк. Шуның өчен басылуын теләр идем, ягъни бу көннән үзенә аерым рисалә

ителеп басылсын. Кеше сүзеннән курыкмагыз, басылсын. Бүгенге кешеләр сүзләренә игътибар юк. Игътибар исә киләчәктәгеләргәдер. Киләчәкләр рәхмәттән башка бернәрсә дә әйтмәсләр».

Тәртип иткәнем ошбу тәрҗемәи хәлне хөрмәтле остаз Ризаэддин хәзрәткә җибәреп күрсәткән идем, ул хуш күреп, кайбер кимчелекләрен күрсәтеп, аерым билгеләр куеп җибәрде. Аларны төзәттем. Рисалә шәкелендә басылачак булгач, аерым-аерым сүз башлары ясарга вә бәгъзе нәрсәләр арттырырга туры килде. Габделвәли Яушев хакындагы мәгълүматның иң күп өлешен ахунд хәзрәт Рахманколый вә Мөхәммәт хәзрәт Бикмәтидән алдым. Ошбу мөхтәрәм өч затка чын күңелемнән тәшәккер итәмен *(рәхмәт белдерәм)*.

« **Бүгенге кешеләр сүзләренә игътибар юк. Игътибар исә киләчәктәгеләргәдер. Киләчәкләр рәхмәттән башка бернәрсә дә әйтмәсләр.**

Троицки, 1911 ел, 2 октябрь

Габделвәли Яушев

Бабалары вә аларның ватаннары Троицкида.
Гайсәдән таралган Яушевлар.

Габделвәли бине Әхмәтҗан бине Гайсә бине Йосыф бине Бикбау бине Мортаза бине Морад бине Габдулла бине Дустмөхәммәт бине Ягуш бине Яуш[1].

Бу затның балалары Казан өязендә Иске Мәңгәр авылында көн иткәннәр. Троицкига Гайсә Йосыф угылы күчеп килгән. Бу шәһәрдә булган Яушевларның һәммәсе шушы Гайсәдән таралганнар. Моның Фатыйма Габдерәфыйкъ кызы исемле хатыныннан Әхмәтҗан, Мөхәмммәтҗан, Хәкимҗан, Шакирҗан, Исмәгыйльҗан вә Закирҗан исемле угыллары; Гайшә, Зөһрә вә Гафифә атлы кызлары; Мәхбүбкамал исемле икенче бер хатыныннан Мөхәммәтлатыйф исемле бер угылы булган.

Сахибе тәрҗемә – тормыш юлы, тәрҗемәи хәле, биографиясе язылган шәхес. Бу очракта Габделвәли Яушев турында сүз бара.

[1] Троицкида Габдулла Хәкимҗан угылы Яушев кулындагы русча тәртип ителгән *(язылган)* шәҗәрәдән *(родословное князей Яушевых)* күчерелде. Шәҗәрәнең астында язылган русча язуларының укырга мөмкин булган кадәресеннән бу шәҗәрәнең 1856 елда Габделвәлинең бабасы Гайсә тарафыннан төзелдереп, Казан шәһәрендәге әллә нинди мәхкәмәләрдә тасдыйк иттерелгәнлеге *(раслатылганы)* аңгарыла. Бу язуларның байтагын, кәгазь вә чүпрәкләре белән бергә, тычканнар ашаган вә бөтен шәҗәрә майланып вә пычранып беткән. Габдулла әфәнде аны миңа әллә кайдан – кладовойдан эзләп табып бирде. *(Автор иск.)*

Безнең мирас №8 август 2021

Габделвәли Яушев вафат булган йорт
(бу көндә угылы Габделгазиз милекендәдер)

Мөхәммәтҗан бине Гайсәнең Мөхәммәтгали, Мөхәммәтшаһ дигән ике угылы бар; болардан әүвәлгесенең хәяттә дүрт угылы вә бер кызы бар; Мөхәммәтшаһ бине Мөхәммәтҗан үзе дә хәяттә; балалары күп.

Хәкимҗан бине Гайсәнең Габдулла вә Мөхәммәтвәли исемле ике угылы бар; Әшраф исемле кызы сахибе тәрҗемә Габделвәлинең тәхте никахында иде; Бәдәрсафа атлы кызы Троицкида Вәлишакир угылы исемле кешегә бирелгән. Хәдичә исемле кызы элек, сахибе тәрҗемә Габделвәлинең Мәүдүдә исемле хатыныннан туган Габдерахман тәхте никахында булган; хәзердә Казанда Яңа Бистәдә имам Кәшшаф Тәрҗемани тәхте никахында булып, бер хәяттәдер.

Шакирҗан бине Гайсәнең гакыйбе *(нәсел дәвамчысы)* юк. Бу – 1871 нче миладида ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый белән хаҗга барганда борадәре *(ир туганы)* Хәкимҗан белән икесе бергә Мәдинә белән Мәккә арасында «Раян» дигән урында вафат вә шунда мәдфүн булганнар *(җирләнгәннәр)*.

Исмәгыйльҗан бине Гайсәнең Маһибәдәр исемле бер кызы гына калган; әле хәяттәдер. Закирҗан бине Гайсәнең гакыйбе юк.

Гайшә бинте Гайсә вакыт илә Троицкида 2 нче мәхәлләдә имам булган Әхмәт хәзрәтнең туганы Габделлатыйф Халит угылының тәхте никахында булган. Моның хәяттә бер кызы гына бар.

Зөһрә бинте Гайсә Троицкида Габдерахман Габбас угылы дигән бер кемсәнең тәхте никахында булган. Моның хәяттә бер угылы, ике кызы бар.

Гафифә бинте Гайсә Петропавелда ахунд булган Габделбарый Габбас угылы Яушевка бирелгән. Аннан Габделваһаб исемле угылы хәзер дә шул шәһәрдә имам вә ахундтыр.

Мөхәммәтлатыйф бине Гайсәнең хәяттә Муллаәхмәт, Мулламөхәммәт исемле угыллары; Мәгъмүрә исемле бер кызы бар.

Әхмәтҗан бине Гайсәнең Габделвәли *(сахибе тәрҗемә)*, Мөхәммәтсадыйк, Мөхәммәтшәриф һәм Муллагали исемле угыллары; Газизә, Маһирә вә Маһитаб атлы кызлары булган.

Мөхәммәтсадыйктан Шакир исемле бер угылы, Маһруй вә Мөстүрә исемле ике кыз, Шакир вафат булып, өч угылы, бер кызы калган. Маһруй белән Мөстүрә икесе дә иргә барганнар вә хәяттәдерләр.

Мөхәммәтшәриф 1906 елда вафат булып, Мөхәммәтлатыйф исемле угылы, Мөнәвәрә исемле кызы калды.

Муллагали хәяттә булып, бүгенге «Торговый дом борадәран Яушевлар» фирмасының патроныдыр.

Газизә Вәлитаһир угылы Уразаев исемле кеше никахында булган. Ул үлгәч, туганы Маһирә дә аңа барган. Газизәдән туган Мөхәммәтҗан Уразаев Ташкент шәһәрендә бер хәят булып, борадәран Яушевлар хезмәтендәдер. Маһитаб, хәзердә 2 нче мәхәлләдә имам, мулла Мөхәммәтзариф угылы Бикмәтевнең тәхте никахында булып, бер хәяттәдер.

Гайсәнең мал табуы, изгелекләре вә торган йорты. Әхмәтҗанның үз алдына эш күрә башлавы. Хәкимҗанның аңа вә сахибе тәрҗемәгә ярдәме. Әхмәтҗанның хаҗ кылуы вә вафаты. Сахибе тәрҗемә эш башында.

Сахибе тәрҗемәнең бабасы Гайсә, Троицкидан Бохарага чыгып китеп, анда чын гайрәт вә һиммәт белән кәсепкә тотынган, кәрван булып ком диңгезләре аркылы төрле шәһәрләргә юнәлә торган дөяләргә артыла вә башка хезмәтләрдә булынган. Шул рәвешчә берничә ел кәсеп итеп, сәрмая *(акча, мал)* ясагач, Троицкига кайтып сәүдәгә тотынган. Минаунида *(алыш-биреш урынында)* вә шәһәр эчендә дөкян-кибетләр ачкан; акрын-акрын игътибарлы вә инабәтле *(ышанычлы)* сәүдәгәрләр рәтенә тезелсә дә, артык байый алмаган, тик угылы Хәкимҗан җитешкәч кенә яхшы ук дәүләт иясе булып киткән вә бай исемен алган.

> Артыла – дөягә йөкләнә торган йөкләрне бәйләү хезмәте.

Гайсә, дәүләт иясе булганнан соң, мәчетләрне карарга бик әһәмият бирә торган булган: 2 нче мәхәлләдәге мәчетне берничә мәртәбә тәгъмир иттергән *(яңарткан)* вә 3 нче мәхәлләдәге мәчетне бөтенләй үз кесәсеннән салдырган.

Ул вакытта шәһәрнең ул як очы хәзерге Һәдиятулла Дивәзиев йортыннан да югарырак булган. Бинаән галәйһи *(шул сәбәпле)*, бу мәчет салынган урын буш дала, өстәвенә, сазлык, сулы бер күлләвек булган. Гайсә, бу күлләвекне балчык вә таш белән тутырттырып, шул җиргә мәчет салган. Ул чакта ул тирәдә татарлар да бик аз булган. Ләкин соңыннан килгән татарларның иң күп өлеше шул тирәгә җыелганнар. Бу көндә татарның иң күп булган урыны шул тирә булып, шәһәрнең татар кыйсеме *(бистәсе)* дип аталадыр.

Гайсәнең тормышы 2 нче мәхәлләдә булган. Аның торган йорты хәзер моның угылы Латыйф балалары милкендәдер. Ак буявы вә, гомумән, стиле – искелек вә борынгылыктан хәбәр биреп торадыр.

Ахунд Әхмәтхаҗи Габделзаһир угылы Рахманколый. Троицкида 1 нче мәчет хозурында 1876 елдан бирле имам; 1890 елда ахунд булган, 74 яшендә

Гайсә сахибе тәрҗемәнең атасы Әхмәтҗанны аерып чыгарган. Аерылып чыккач, Әхмәтҗан, үз алдына сәүдәгә тотынса да, ни өчендер, алга китә алмаган. Атасы белән бергә торган Хәкимҗан, Әхмәтҗанның бу хәлен күреп, аны кызганган вә Гайсә карттан аңа файда уртакка мал биреп, Бохарага җибәрүне үтенгән; Гайсә күнгән. Әхмәтҗан бер баруда ук Бохарадан алып килгән мамыктан бик зур файда иткән дә яхшы гына сәрмая *(сумма)* ясаган. Шуннан соң 1853 елда Бохарага угылы Габделвәлине дә алып барган; Ташкентка да баргалап йөргәннәр.

Шул эшендә Габделвәлинең уяулыгын вә күзе ачыклыгын Хәкимҗан күреп, аны үз култыгына алган вә аңа тагы да зуррак эшләргә катышырга юллар ачкан. Шул рәвешчә, Габделвәли сәүдә эшләренә катышып, җиддият *(тырышып, көч куеп)* белән эш күрә башлаганнан соң, Әхмәтҗан яхшы ук дәүләт иясе булып киткән. Ләкин соңыннан, ни өчендер, Әхмәтҗан «сынган», гайрәтле Габделвәли ата дәүләтен яңадан аякка бастырып, хәзерге Яушевлар байлыгына нигез салган.

Балалары эш башкара башлаганнан соң, Әхмәтҗан 1870 елда ахунд Әхмәтхаҗи Рәхманколый рәфәкатендә *(юлдашлыгында)* хаҗга барып кайткан; 1875 ел февраль 5ендә 57 яшендә вафат булган.

Әхмәтҗан вафат булгач, сәүдә эшләренең башында тагын да җиддият белән Габделвәли йөри башлаган; борадәре Садыйк аңа ярдәмче булган; болар Шәриф вә Муллагали белән дүрт агай-эне бергә торганнар вә берлектә эш йөрткәннәр. Эшне дәхи дә *(тагын да)* ыграк казыкка бәйләр өчен сахибе тәрҗемә үз фирмаларын «Торговый дом под фирмою Габделвәли Әхмәтҗанович Яушев с братьями» *(«Габделвәли Әхмәтҗан угылы Яушев вә борадәрләренең тиҗарәтханәсе»)*

исемендә ясаган. Ләкин, соңыннан Садыйк болардан аерылып чыккан. Дәхи, Әхмәтҗанның хаҗга китмәстән элек сатып алган болгари *(күн)* заводын Габделвәли зурайткан вә киңәйткән. 1881 елда паровой тегермән торгызганнар.

Сахибе тәрҗемәнең туу тарихы вә йорты. Анасы вә бабасы. Хатыннары вә балалары. Укыган җире вә остазлары, гыйлеме, фикере вә сәүдәгәрлеге. Киңәшчеләре: шәех Зәйнулла Рәсүли вә ахунд Рахманколый.

Сахибе тәрҗемә Габделвәли 1840 ел март 12сендә Троицкида 1 нче мәхәлләдә Су буе урамында бәҗиче Һибәтулла Хәмзә угылы йортында туган. Бу йорт бу көндә ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый йортыннан ике йорт аша; Һибәтнең кызларының балалары Биктимеревләр кулындадыр. Ул вакыт беренче мәхәлләдә имам булган Зариф бине Габделҗәмил метрика дәфтәренә сахибе тәрҗемәнең вилядәте *(тууы)* хакында болай дип язган: «Атасы лашманчы Әхмәт, анасы Сәгыйдәбану».

> Бәҗиче – Урта Азиядән килгән малларга тамга сугып торучы.

Габделвәлинең анасы булган Сәгыйдәбану – Мәхмүд Габдеррәшит угылы Әбүбәкирев кызыдыр. Бу исә Казан өязендәге Сабабаш авылыннандыр.

Сахибе тәрҗемәнең тәүге хатыны Троицкилы Мәүдүдә Хәсән кызыдыр. Моннан Габдерахман вә Хәкимҗан исемле угыллары, Фатиха вә Маһибәдәр атлы кызлары булган. Болардан Хәкимҗан 17-18 яшьләрендә вафат булган; Габдерахман соң көннәрендә Петропавел шәһәрендә торып, шунда үлгән. Моннан Хәдичә Хәкимҗан кызыннан туган бер угыл калган. Маһибәдәр, Троицкида иргә барып, Закир исемле бер угыл калдырып вафат булган. Закир инде өйләнгән, Ташкент шәһәрендә тора. Фатиха Казан сәүдәгәре Сөләйман Аитовка никахланган иде. Бу көндә Фатиха ханым Аитова үзенең атаклы кызлар мәктәбе белән мәгъруфтыр *(танылган)*. Сахибе тәрҗемә Мәүдүдәне 1883 ел декабрь 12сендә талак кылган; ул хәзер Казанда, кызы Фатиха ханым янында торадыр.

Икенче хатыны – Норма авылының Мөхәммәткамал кызы Гайшәдер. Моннан Мөхәммәтгали исемле бер угылы булып, Гайшә бу көндә шуның кулында торадыр.

Өченче хатыны – Әшраф Хәкимҗан бине Гайсә кызыдыр. Моннан Мулламөхәммәт, Габделгазиз исемле угыллары, Хәдичә исемле кызы бардыр. Әшраф бу көндә ошбу угылларының кулында торадыр.

***

Габделвәли 2 нче мәхәлләдәге мәдрәсәдә Әхмәт хәзрәт Халид угылы заманында, Верхнеурал өязендәге Илче авылының Юлмөхәммәт вә Гариф исемле хәлфәләрдә укыган. Татарча укырга, язарга белә иде. Үзе «Дәляил әл-хәйрат шәрхе», «Кәрһ Давыд»ны, «Мөхәммәдия» һәм «Алты бармак» китапларын бик сөеп моталәгә итә *(укый)* торган булган. Сәүдәгә бирелеп киткәнлектән, укып гыйлем вә фикер даирәсен киңәйтергә тырышканлыгы беленми. Остаз алдында укуы аз, моталәгасе юк дәрәҗәсендә булса да, ул башлы вә тәдбирле *(эшнең ахырын уйлап эшләүче)* кешеләр җөмләсеннән санала иде. Русча укый да, яза да белми;

ләкин сәүдәгә тәгаллекълы *(бәйләнешле)* эшләрдә хаҗәт үтәрлек кадәр сөйләшә белә иде. «Тәрҗеман» газетасын укыганлыгы беленмәсә дә, русча газеталарны укытып, сугыш, политика вә кызыклы вөкугатка даир *(вакыйгаларга караган)* хәбәрләрне тыңлаштыргалый торган булган.

Исәп-хисапка шәп вә җитез; мәгънәсе илә сәүдәгәр; төрле яңа эшләр башларга җәсарәтле *(батыр, кыю)* булган.

Сахибе тәрҗемә бәгъзе бер үзенә мөшкелрәк күренгән хосусый эшләрендә һәм мәчет-мәдрәсә салдыру, уку вә укытуга ярдәм иту вә шуның кебек җәмәгать эшләрендә ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый, дамелла Мөхәммәт Бикмати вә шәех Зәйнулла Рәсүли белән киңәш иткән.

Мәчетләр бина иттерүе. Ысулы җәдидәнең таралуына хезмәтләре. «Мәшәкател мәсабих»[2] бастыруы. Мөфти Солтанов белән Петербургка баруы. Троицки халкы арасында тоткан урыны. Хәзерге борадәран Яушевлар фирмасы. Сахибе тәрҗемәнең вафаты.

Габделвәли Яушев вә борадәрләре тарафыннан салынган Кустанай мәчете

Сахибе тәрҗемә үз халкыбызга мал белән изгелек иткән кешеләр җөмләсеннәндер. Ул Казан губернасында, Троицки вә әтрафында байтак

[2] «Мәшәкател мәсабих» – «Мәгарифтәге кыенлыклар».

яңа мәчетләр салдырган вә бәгъзе берәүләрен тәгъмир иттергән *(төзекләндергән)*. Троицки өязендәге Звериноголовский вә Борхан авылы мәчетләре һәм олуг вә мәһабәт Кустанай мәчете башлыгы сахибе тәрҗемә булган Яушлар тиҗарәтханәсенең *(сәүдә йортының)* яңадан салдырган мәчетләрнең бәгъзеләредер.



Сәүдәгәр Латыйп Яушевның хатыны һәм балалары

Троицкида татар балаларына махсус русский класс ачарга рөхсәт чыгарту вә шул ук шәһәрдә мөселман җәмгыяте хәйриясе тәэсис итү *(оештыру)* хакында бик зур хезмәт вә иҗтиһадлар *(тырышлыклар)* иткән вә бу ике файдалы мөәссәсә *(оешма)* мәйданга чыгарылган.

Сахибе тәрҗемәнең иң зур хезмәте – Троицки вә әтрафында ысулы җәдидә белән тәгълимнең *(укуның)* таралуына мал белән ярдәм итүедер. Бу якларда моның интишарына *(таралуына)* аның зур һиммәтләре *(тырышлыгы)* булган. Ысулы җәдидәнең мәйданга чыгуына вә халкыбыз арасында таралуына үзебездән берничә каләм ияләре, берничә мулла вә мөгаллим, вә берничә байларның хезмәт иткәнлеге мәгълүмдер. Менә Габделвәли Яушев та шундый байларның берседер. Минем карашымда, аның бу хезмәте мәчетләр салдыру вә төзәттерүеннән әллә ничә кат мөһим вә олугтыр. Бездә мәчет салдыручы, мәчет төзәттерүче, Хиҗаз фәкыйрьләренә садакалар җибәрүче, теләнчеләрне капка төбенә җыеп зәкят өләшүче вә бәдәл хаҗ *(хаҗга үз исеменнән башканы җибәрү)* белән васыять итүче байлар бик күп булганнар. Боларның «изгелекләре» гел бертөрле булганлыктан, вә милләтебезнең хәяте вә бәкасы *(мәңгелеге)* өчен бер тиенлек ярдәм итәчәк эшләр булмаганлыктан, халкыбызда һичбер төрле яхшы әсәр күрсәтә алмаганнар гына түгел, бәлки, кайберләре начар әсәрләр күрсәткәннәр. Милләтләрнең хәят вә бәкасында ибтидаи *(башлангыч)* мәктәпләрнең нинди мөһим урын ишгаль итүләре *(алуы)*, иске мәктәпләребезнең ни дәрәҗәдә черек вә әсассыз *(нигезсез)* булулары, ысулы җәдидә аркасында ибтидаи мәктәпләребезнең күзгә күренерлек рәвештә юлга салынулары вә яңа һәм файдалы юньгә китүләре бәсыйрәт *(аң-гыйлем)* ияләренә ачык мәгълүм булгач, Габделвәли байның ибтидаи мәктәпләрнең төзелүе юлында иткән хезмәт вә ярдәмнәрен ничек мөһим вә олуг санамаска кирәк?

Ысулы җәдидәнең гамәлгә куелуы вә таралуына мал белән хезмәт иткән кешеләр сафка тезелгән тәкъдирдә Әхмәт бай Хөсәеневнең имам урынын тотачагында шөбһә юк. Ләкин Габделвәли дә бу сафның мөһим күрекле бер урынын ишгаль итәчәгендә *(биләячәгендә)* шөбһәләнергә ярамый. Ысулы җәдидәнең тарихын язучылар моны онытмасыннар!

Ысулы җәдидә мәктәпләренә Габделвәлинең кесәсеннән берничә меңнәр сарыф кылыну өстенә, ул вә ярдәмчеләре үз файдасын үзе белмәгән татарларга

вә кире беткән бәгъзе муллаларга «яңача укыту»ны кабул иттерү юлында да күп мәшәкать вә михнәтләр күргәннәр.

Ахунд Рахманколый хәзрәтләре башлап ысулы җәдидәне гамәлгә кую нияте белән үз хәлфәләреннән Мөхәммәтзакир Ваһаповны *(бу көндә Җидесу вилаятендәге Тукмак шәһәрендә тора)* ысулы тәгълим күрер *(укытыр)* өчен Истанбулга җибәргәндә, аңа кирәк булган мәсарифның *(чыгымның)* зур бер өлешен Габделвәли биргән. Ул кайтып, берничә ысулы җәдидә мәктәбен ачып укыта башлагач, сахибе тәрҗемә беренче мәхәллә хозурындагы шул мәктәпнең мөгаллимнәренә айга 50 сум мәгаш *(хезмәт хакы)* бирә башлаган. Троицкиның башка мәхәлләләрендә дә ысулы җәдидә мәктәпләре ачылып укытулар башланганнан соң, ул мәктәпләрнең мөгаллимнәренә дә мәгаш *(акча)* бирергә керешкән; хәтта Троицки вә Чиләбе өязендәге бәгъзе бер авылларда да мәктәпләр ачтырып, мәгашләр биргәләгән. Бу рәвешчә мәктәпләргә ярдәм итүе үзе үлгәнче дәвам иткән.

***

«Мәшәкател...»не бастыруы. 1892-1893 нче елларда мөселманнарның дини китапларын бастыруны тыю хакында чиктән тыш инсафсызлыклар башлангач, Русия мөселманнар арасында күңелсезлек, хәфа вә хәфалану булдыгы мәгъруфтыр *(билгеледер)*. Менә бу хәл, мөселманнар күп торган шәһәрләрнең берсе булган Троицкида да күрелгән. Шушы эш хакында тиешле урыннарга мөрәҗәгать итәр өчен делегатлар сайлап, пайтәхеткә *(башкалага)* җибәрү фикерен сахибе тәрҗемә кузгаткан. Бәс, ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый белән Мулламөхәммәт Бикмати Троицки мөселманнарыннан вәкил сыйфаты илә чыгып киткәннәр, китешли Уфага кереп, Абуссогуд мирза Әхтәмевне алганнар да Петербургка юнәлгәннәр. Шул чорда пайтәхеткә башка шәһәр мөселманнарының вәкилләре дә килгәннәр икән.

Матбагачы Бораганский ахунд Рахманколыйдан басар өчен китап сораган. Ахунд үз иптәше Мулламөхәммәт хәзрәт белән «Мәшәкател мәсабих»ны тәкъдим иткән. Хәлбуки, аннан элек шул хәлендә бу китапны басарга рөхсәт бирелмәгән икән. Ләкин бу юлы, бер яктан, Бораганскийның ялварулары вә, бер яктан, Троицки вәкилләренең кулларыннан килгән тәдбирләрдә *(чараларда)* кимчелек итмәүләре таш бәгырьләрне йомшаткан вә «Мәшәкател...»не басарга рөхсәт бирелгән. Шушы «Мәшәкател...» сахибе тәрҗемәнең хәраҗаты *(акчасы)* белән басылган. 1000 нөсхә басканнар, 6000 сум акча тотылган. Китап бик нәфис вә мөкәммәл рәвештә басылган ки, өстенә карап кинәнеп торырлыктыр.

1895 ел мөфти Солтанов, ахунд Рахманколый белән бергә, сахибе тәрҗемә, падишаһыбыз Николай Александр угылының тәхеткә утыруын котлар өчен, Петербургка барган вә шушы ике юлдаш белән Кышкы Дворецта патша хозурына кабул ителгән вә аның исеменнән императрицага 10 000 сумлык мех һәдия *(бүләк)* тәкъдим ителгән.

***

Габделвәли Троицкида кирәк – татарлар, кирәк – урыслар арасында бик мөһим урын тоткан. Шәһәрнең мөһим эш вә мәсьәләләре хакында аның киңәшеннән башка эш кылынмаган. Татарлар кирәк – сәүдә хосусларында, кирәк – башка мөһим вә гомуми эшләрдә аңа мөрәҗәгать итеп киңәшә вә гакыл сорый торган булганнар; аның фикере вә сүзләре бик мәкъбүл *(кабул ителгән)* вә могтәбәр *(югары)* тотылган. Хәтта Троицкиның әтрафындагы кешеләр дә аның мәслихәт вә гакылыннан файдаланганнар.

Китап авторы Габделбари Баттал-Таймас хатыны Газизә Таймас һәм уллары Билгивар Таймас белән

Сахибе тәрҗемәгә садакате вә сәүдә эшләрендәге гайрәте һәм кайбер малларының мөкәммәл вә шәплеге өчен хөкүмәт тарафыннан берничә медаль бирелгән.

Ул үлгән көненә кадәр сәүдә эшләрен «Габделвәли Әхмәтҗан угылы Яушев вә борадәрләренең тиҗарәтханәсе» фирмасы астында карендәшләре Мөхәммәтшәриф вә Муллагали Яушевлар белән бергә йөрткән. Ул үлгәч, 4-5 айдан соң фирманың исемен «Торговый дом братьев Яушевых» *(«Борадәран Яушевлар тиҗарәтханәсе»)* исеменә алмаштырганнар. Эшләре көннән-көн зурайган, сәүдә мәйданнары киңәйгән. Бу тиҗарәтханәнең хәзерге әгъзалары Муллагали Әхмәтҗан угылы Яушев *(фирманың патроны),* Габделвәлинең ике угылы – Мулламөхәммәт вә Габделгазиз һәм Мөхәммәтшәриф угылы Латыйф Яушевлардыр. Бу фирма хәзер дә ма вараэ Уралдагы *(Урал аръягындагы)* фирмаларның иң дәүләтле, могтәбәр *(хөрмәтле)*, төпле вә ышанычлыларыннан саналадыр. Сәүдәләре һаман көчәя вә табышлары арта барадыр. Дин вә милләт өчен изгелекләре дә юк түгел. Габделвәлинең балалары истикамәтле *(тугрылыклы)* вә үз эшләрен башкаручы кешеләрдер.

***

Сахибе тәрҗемә Габделвәли Яушев 1906 елда сентябрьнең 13ендә иртә белән сәгать дүрттә вафат булган. Яше 67 эчендә иде.

Мәрхүм үлгәндә гомум милләт файдасы өчен зур васыятьләр итәргә муаффәкъ була *(ирешә)* алмаган. Ләкин үзенең хәятендә иткән изгелекләре дә исемен яхшылык белән сагындырырга җитәрлектер. Аллаһы Тәгалә үзенең ризасына мәзъһәр итсен *(кабул итсен)*!

Текстны журналга ***Энҗе Сабирова*** *һәм* ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №8 август 2021

Шәҗәрәбез тарихы

Әнвәр Маликов

Тамырларны барлаганда

Бервакыт, әле үсмер чагымда ук, әти миңа берничә саргайган блокнот бите күрсәтте; аларда баганалап тугыз сәер исем язылган иде: Борай, Кадергол, Дүсмәт, Сөбханкол, Морзагол, Сабанак...

– Бу – безнең шәҗәрә, – диде ул. – XVI гасырда яшәгән Борай бабабыз Башкортстанның төньяк-көнбатыш ягындагы Борай авылына (район үзәге) нигез салган. Дүсмәт бабабыз Борайдан ерак булмаган Дүсмәт авылын корган...

Әдип һәм Әнвәр Маликовлар

Ул елларда сөйләргә ярамаган башка хәлләрне дә бәян итте әле.

Татарларда элек-электән җиде буын бабаңны белү мәртәбә саналган. Шәҗәрәне Коръәннең эчке тышлыгына яисә өйдә сакланган башка китапларга төшергәннәр. Совет хакимияте урнашкан чорда исә, дин белән көрәшәбез, дип, бик күп гарәп имлалы татар китаплары харап ителгән, карап, аерып тормыйча, дәреслекләр, әдәби әсәрләр утка ташланган.

Безнең шәҗәрәне Малик бабам (мулла оныгы, репрессияләнгән мәзин улы) күчереп язган һәм бу «компромат»ны озак еллар саклап тоткан... Ул, дини белем эстәгән авыл укытучысы, гомер буе үзенең кулга алынуын көтеп яшәгән. Кәгазь бите шуннан соң әтинең эш өстәленә – тирәнгәрәк, аскарак, кадерле папкага күчкән... Андагы серле исемнәр миңа байтак вакыт тынгылык бирмәде. Ниһаять, 1989 елның августында, «үзгәртеп кору»ның иң чиллә чагында, «хезмәт ияләре»ннән булмаган бабаңнан оялмый башлаган заманда, мин 68 яшьлек әтине бергәләп аның туган җирен – Югары Чат авылын күреп кайтырга үгетли алдым. Әтинең монда 1934 елдан бирле кайтканы юк иде. Үзем элгәреләребез турында хәбәр-хәтер булмасмы дип өметләндем. Югары Чатта бабамның әтисе Гарифулла мәзин яшәгән.

Гаҗәеп кызыклы һәм гаять уңышлы сәфәр булды ул! Авылда туган-тумача, таныш-белеш калмаганга күрә, әти, үзенең киләсен белдереп, алдан ук Яңавыл райкомына хат язды. Беренче сәркатип безне колач җәеп каршы алды (ул әтине шагыйрь һәм фронтовик буларак бик нык хөрмәт итә иде). Һәркайда татар сүзенең яңгырап торуы күңелгә хуш килде, бу як кешеләренең заманча татар мәдәнияте йогынтысында яшәүләре куандырды. Һәр йортта – Казанда басылган китаплар, журналлар, газеталар, музыкаль язмалар, татар сувенирлары... Безне Югары Чат авылына алып киттеләр. Ни гаҗәп: карт-коры гына түгел, хәтта яшьрәк авылдашлар да

Гарифулла белән Маликны ишетеп белә иде! Могътабәр кешеләрнең дәвамнарын күреп, һәркем чын күңелдән елмаеп сәламләде, кочакка алырга ашыкты. Безгә бик күп мәгълүмат җиткерделәр, елга буена китереп, бабабызның нигезен күрсәттеләр. Монда, пар колачка сыярлык борынгы тал төбендә, мин очы сынган урак табып алдым.

XV гасырга сәяхәт

Совет хакимияте урнашып, авылда кирәксез затка әверелгән Гарифулла мәзин соңгы көннәрен кайда һәм ничек уздырган соң?

«Мал-милке тартып алынгач та Дүсмәт авылына күченмәдеме икән», – дип сөйләделәр безгә (анда кайчандыр әтисе Нурмөхәммәт мулла вазыйфасын башкарган).

Шулай итеп, күрше Борай районына кузгалдык. Мондагы райком да мәшәкатьләребезне тиз хәл итте. Киләсе-китәсе түрә-караны кайгыртып төзелгән кунакханәгә урнаштырдылар, Дүсмәткә барыр өчен машина бирделәр.

Дүсмәткә әтинең беркайчан да кайтканы булмаган. Шунлыктан, табигый, барып төртелер кешебез дә юк иде. Безне элеккеге мәктәп директоры, иң мөхтәрәм картлардан берсе Гыйлемхан Хөсәенов йортына китерделәр. Вакыт кичкә авышкан иде, шуңа күрә агай башта, чит-ятларны күргәч, югалып калды. Әмма кем нәселеннән булуыбызны белгәч, шатлыктан балкый ук башлады: «Гарифулла мәзин!» – дип кычкырып җибәрде. Якыннан белмәсә дә, Гыйлемхан әфәнде аның турында бик күп яхшы сүз ишетеп яшәгән икән. Авылны күрсәтеп чыкты. Безне очраган һәркем белән таныштыра торды. Әлбәттә, беренче килүдә үк бабаңның зирәк киңәшче, иманга өндәүче, дәвалаучы һәм укытучы булуы турында ишетү күңелле дә, рәхәт тә иде. Кинәт бөтенләй бәхет ишелеп төштемени! Урамда 83 яшьлек Гыйльмисабир Гыйльмитаһир улы Таһиров очрады; үзенә чакырып кертте, шәҗәрәсен күрсәтте. Аның нәсел агачы XVIII гасырга кадәр безнеке белән тач туры килә иде диярлек. Әлеге аксакалның чыбык очы туганыбыз булуы аңлашылды. Шушы очрашу нигезендә без шәҗәрәне тагын да тулыландыра алдык, Сабанак исемле уртак бабабызның фетнәче, Салават Юлаевның көрәштәше булуын белдек... Аннан Сабанаковлар нәселе тармакланып киткән. Совет хакимиятенең беренче елларында хезмәт куйган паспортчылар тәшвишләнмәсә, ул фамилияне без дә, әтием белән мин дә, йөртергә мөмкин идек...

Борай шәҗәрәсе

Дүсмәт сүнеп бара иде. Һәр авылның йөрәге булып торган мәктәп без килгән елны, соңгы ике-өч укучысын чыгарып, мәңгелеккә ябылган. Гыйлемхан абыйга аның соңгы директоры булырга язган.

Икенче көнне Борайга юл тоттык. Төбәкне өйрәнү музее экспонатларына ышансаң, тормыш монда күмәк хуҗалыклар оешкач кына яралганга охшый иде. Безгә ярдәм итәрлек кеше табылмады. Район газетасы редакциясе дә андый ерак тарих белән мавыкланырга теләмәде. Алай да туган якны өйрәнүче Әхмәтгали Вәлиәхмәт улы Латыйповның адресын әйттеләр тагын. Ул безне якты чырай белән каршы алды, күп еллар буе җыйган, барлаган хезмәтләрен күрсәтте. Фидакяр эшчәнлегенең кемне дә булса кызыксындыра алуына чиксез шат кебек иде ул. Борайның тәфсилләп төзелгән шәҗәрәсе белән таныштык, аның тамырлары тирәнгә – XV гасырга ук киткән иде. Баксаң, Борайның ерак бабасы Җәлдәк-тархан, үз халкын ияртеп, бу якларга Агыйделнең түбәнге өлешеннән күтәрелгән һәм уң ярда авыл корган икән. Авылны аның исеме белән атаганнар. Урыс теленә ул, табигый, имгәнеп кергән: Ельдец, Ельдецово… Әхмәтгали әфәнде безгә элеккеге Җәлдәк вулысы халкының шәҗәрәләрен тулаем өйрәнеп чыккан Уфа фидакяре Айдар Ислам улы Ахуновның адресын бирде. Алга китеп, шуны әйтим: бу сәфәрдән кайткач, мин аның белән хат алыша башладым; яңа мәгълүматлар табылды, нәтиҗәдә, пазллардан җыелгандай, шәҗәрәбез күз алдында тулыланды, баеды.

Дүсмәт авылы һәм аның тирә-юненең күренеше

Агыйдел суы буйлап

Биш гасыр элек бабаларыбыз килгән юлдан кирегә – агым буйлап аска кузгалдык. Вострецов пристаненда «Метеор»га утырганда, провожатый еракка, елганың борылып киткән җирендәге текә ерганакка ишарәләде:

– Җәлдәк авылы шунда инде…

Катер безнең кан-кардәшләр яшәгән яр читеннән барды.

Мин Татарстанның иң көнчыгыш ноктасында – Актанышта төшәргә тәкъдим иттем. Җәлдәк шул урыннан кузгалган бит. Актаныш пристане һәм район үзәге икесе ике нәрсә булуы кемнең башына килсен! Басу уртасында басып калдык. Аптырап тирә-юньне күзәттек: сизелер-сизелмәслек юл эзеннән кала бернинди җан әсәре, тормыш әсәре юк! Бәхеткә, хәлебезгә керерлек балыкчылар очрап, безне район үзәгенә, автовокзалга кадәр илтеп куйдылар. Монда янә көтелмәгән хәлгә тарыдык. Автобусларның көндезге икедән соң бер генә юнәлешкә дә бармавы беленде. Ә вакыт кичкә авышкан иде инде… Көньякка яисә көнбатышка юл тоткан теләсә нинди техникага, очраклы юлаучыга утырырга да риза идек без. Шундый авантюрага бирелгән өчен үземне битәрләп арымадым! Әмма дөньяның ачысын да, төчесен дә күп күргән эти хәсрәткә чумарга ашыкмады, һәрвакыттагыча, егетләрчә нык торды…

Ул вакытта Мин Татарстан Эчке эшләр министрлыгында матбугат хезмәтен җитәкли идем. Тәвәккәлләп, милиция бүлегенә киттек. Анда төскә-биткә бик

мөлаем замполитны очраттык. Ул урнаштырган «УАЗ»ик безне Мөслим районы эчке эшләр бүлегенә кадәр илтеп куйды. Анда исә ГАИ машинасы табылды. Шуңа утырып без, арыган һәм тузанга баткан килеш, Әлмәткә, әти яшәгән йортның подъезд бусагасына кайтып туктадык…

Шәҗәрәбез – Ирек мәйданында

Бу вакыйгалардан соң күп еллар узгач, шәҗәрәне барлау тарихы бөтенләй көтелмәгән борылыш алды… «Казан» милли-мәдәни үзәгендә урнашкан Татар әдәбияты музее кызыксыну белдергәч, мин компьютерда нәсел агачыбызның сызымын төзегән идем. Музейдагы бу схема (шәрехләүләр белән бергә) республикабызның бер журналына килеп эләккән һәм минем рөхсәтемнән башка дөнья күргән…

2011 елның сентябре. Җәмәгатем Асия шалтырата:

– Ирек мәйданында синең шәҗәрәңне күргәзмә итеп куйганнар! – ди.

Мин, берни аңламаган көе, барча эшемне ташлап шунда юнәлдем. Һәм ни күрим: опера театры каршында башкорт тирмәләре… берсенең бусагасы катында ук – агачта бизәкләп ясалган… шәҗәрәм! Нәкъ минемчә, мин төзегәнчә!

Бу вакытта Татарстанда Башкортстан көннәре уза иде. Тирмәләрне Әбҗәлил һәм Борай районнары корган булып чыкты. Мин тирмә эченә уздым, милли киемнәрдән киенгән «хуҗабикәләр» янына килдем. Исемемне атап, нәсел агачындагы үз «яфрагыма» төртеп күрсәттем. Бер минутка тынлык урнашты. Аннары бу шәҗәрәнең бая телгә алынган журналдан күчереп ясалуы мәгълүм булды…

«Бөтендөнья пәрәвезе» яшәү рәвешенең бер өлешенә әверелергә өлгергән 2010 ел иде. Илләр-җирләр гизеп, китапханәләрдә, музейларда мәгълүмат эзләп утыру күптән онытылган! Шул чакта улым укыган лицейның электрон почтасына Уфадан хат килеп төште. Директор исеменә мондый сүзләр язылган иде: «Хөрмәтле Илдар Ренатович! Мин – UfaGen.ru генеалогия сайтының мөхәррире Госманов Булат. Оренбург губернасына караган Бөре өязе Җәлдәк вулысының тарихы белән кызыксынам. Материал эзләгәндә очраклы рәвештә «Казанские ведомости» газетасында (27.11.2008 көнне чыккан номер) язучы Саҗидә Сөләйманова турындагы мәкаләгә юлыктым. Бу язмада аның ире, шагыйрь Әдип Маликов та телгә алынган иде. Аерым әйткәндә, мондый юллар игътибарымны җәлеп итте: «Әдип Маликов шәҗәрәсе XV гасырдан, Агыйдел буенда биләмә алган Җәлдәк тарханнан башлана. Башкортстандагы район үзәгенә нигез салган Борай да шул ук нәселдән». Бу – Җәлдәк ыруының Җәлдәк антропонимыннан килеп чыгуына ишарәләгән беренче хәбәр, моңарчы андый мәгълүмат күргәнем юк иде. Эзли торгач, мин Сезнең лицей укучысы Маликов Әскәр Әнвәр улының «Гаиләм язмышында Бөек Ватан сугышы тарихы» исемле хезмәтенә тарыдым. Анда ул бабасы Әдип Маликов турында бәян итә. Бу егетнең шагыйрь Әдип Маликов оныгы булуында шигем юк. Зинһар өчен, җаегыз булса, Маликовларга хәбәр итегезче: элемтәгә чыксыннар иде».

Мин, әлбәттә, электрон почта аша хат яздым һәм шунда ук җавап алдым. Хат авторы гаять төпченүчән кеше булып чыкты. Ул миңа шәҗәрәбездәге кайбер төгәлсезлекләрне һәм бушлыкларны тутырырга ярдәм итте. Узган гасырларга караган җанисәп документларының күчермәләрен җибәрде, алар ярдәмендә мин ерак бабаларым турында өстәмә мәгълүмат туплый алдым…

Баксаң, үз тамырлары белән кызыксынучы кешеләр дөньяда шактый күп икән. Коми Республикасының Усинск шәһәрендә яшәүче юрисконсульт Әмиров Илнур-

дан мондый хат килеп ирештe: «Интернетта Сезнең e-mail адресына юлыккач та язарга җөрьәт иттем. Ревизия материалларына нигезләнеп, мин Дүсмәт авылында яшәгән бабамнарны ачыкладым һәм ике яклап тикшерү нәтиҗәсендә Дүсмәтнең үзенә барып җиттем. Сез минем чыбык очы туганым булырга охшыйсыз...» Ул үзенең шәҗәрәсен дә җибәрде. Баксаң, чыннан да, 1790 елда туган Күсәпкол уртак бабабыз икән...

Ары таба мин, интернет аша табып, башка ревизия материалларын һәм җанисәп документларын өйрәнергә керештем. Сәер хәлләргә дә очрамадым түгел: әйтик, кайбер чорларда бертуганнарның берсе – татар, икенчесе башкорт булып язылган. Күп кенә документларда «милләт» графасына «башк.» сүзенең үзгә кул белән, ашык-пошык сырлануына да игътибар иттем...

Бүген шәҗәрәңне өйдән чыкмыйча да төзергә мөмкин. Иң мөһиме – гаиләңә, нәсел-нәсәбеңә, ил-ватаныңа карата кызыксынуың булсын. Ахыр чиктә бу эшнең нәтиҗәсе бер: җир йөзендә һәммә кешеләрнең үзара туган булуын ачыклау лабаса.

Уртак ил-су

Инде бабаларыма һәм алар яшәгән чорларга аерым тукталыйк. Бу, безнең нәселдән битәр, Агыйделнең түбән һәм урта өлешендә яшәгән зур халыкның тамырларын барлауда да ярыйсы гына ярдәмлек булыр дип ышанам.

Элек татарлар Иделне Итил дип атаган. Чуашларда да ул атама татарчага якын: Атӑл. Зур суның кушылдыгы булган елганы да җирле халыкның Агыйдел (Ак Идел) дип атавына гаҗәпләнерлек түгел. Чулман һәм Агыйдел елгалары тоташкан урын һәрвакыт бәрәкәтле туфрак саналган. Монда төрле чорларда төрле ырулар, кабиләләр яшәгән, алар йә бер-берсенә алмашка килгән, йә бер-берсен йоткан, үзара кушылып-катнашып беткән. Бу җирләр аша Урал һәм Себер ягыннан көнбатышка һуннар, маҗарлар ише пассионар халыклар узган. Аларның антропологик «билгеләре» мондагы халыкларда бүген дә саклана әле. Бөек төрки каһанлык чорында Агыйделнең сул ярына кыпчаклар килеп төпләнгән. XV-XVI гасырларда алар төньяккарак юл тоткан, Танып елгасы буена җиткән. Евразия киңлекләрендә (хәзерге Казакъстан белән Украинаны да кертеп) гомер сөргән бу халык та күп милләтләрне туганлаштыруга зур өлеш керткән.

Чулман һәм аның кушылдыклары буйлап борынгы болгарлар, аннары Казан ханлыгы татарлары югарыга күтәрелгән, буш җирләрне үзләштергән. Әүвәл, исламлаштырудан качып, көнчыгышка мәҗүсиләр күпләп күченгән, аннары Явыз Иван чорында, чукындырудан һәм геноцидтан котылырга ниятләп, шул ук юлдан мөселманнар үткән. Алар һәртөрле хакимияттән азат көе үз илаһларына табынып яшәүче урман халкы янында сыену урыны тапкан. Агыйдел буйлап менгәндә күчмә башкортлар, сәүдә һәм кәсепчелеккә маһир себер татарлары белән аралашып узганнар. Шуңа да бу җирләрдә сары чәчле, зәңгәр күзле һәм каракучкыл, коңгырт күзле кешеләр иңгә-иң яши. Аларны уртак ана теле – татар теле берләштерә.

Казан ханлыгы гаять зур территориядә яшәгән бик күп халыкларны җыйнаган, укмаштырган. Хәзерге татарлар ул илнең иң күп санлы һәм иң гайрәтле варисына әверелгән, үзенә мирас итеп төрки телне һәм исламны алган. Беркадәр үзгәрәк рәвештә булса да, Чулман белән Агыйдел буйларында да шул ук хәлләр кабатланган.

Ахыры киләсе санда ■

МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ ТАТАР КИТАБЫ

Тукайның Суомида басылган бер җыентыгы

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы



Төрле сәбәпләр аркасында асыл Ватаныннан, Идел-йорттан аерылырга мәҗбүр ителгән милләттәшләребез, дөньяның кайсы төбәгенә эләксәләр дә, туган телләрен, җыр-моңнарын, гореф-гадәтләрен, тарихи хәтерен, әдәбиятын булдыра алган кадәр сакларга, гомер юлдашлары итәргә, бала-чагаларына, киләчәк буыннарга тапшырырга тырышканнар. Әлбәттә, бу гомуми изге теләк-омтылышка катгый чынбарлык үзенең өстәмә-төзәтмәләрен дә кертеп торган. Аерым гаиләләрдә, төбәк һәм илләрдә ул шактый гына уңышлы барса, икенчеләрендә бик зәгыйфьләнгән, хәтта тәмам диярлек сүнүгә, бетүгә дә юл тоткан. Боларның беренчесенә Суомида гомер кичерүче милләттәшләребез, мөгаен, уңышлы бер

мисал була аладыр. Моның үзенә күрә билгеле бер сәбәпләре дә бар. Мәгълүм ки, әлеге мәмләкәт 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр, йөз елдан артыграк Рәсәй империясе составында була. Төрле сәбәп-максатлар аркасында анда милләттәшләребез инде моннан 150-200 еллар элек күренә башлый. Бара-кайта. Нигездә, сәүдә эшләре белән шөгыльләнә. Сирәгрәк булса да башка тармакларда эшләүчеләр дә очрый. XIX гасырның икенче яртысында, аеруча ике гасыр аралыгында Суомида төпләнеп калучылар да арта бара. Әмма асыл Ватаннары белән элемтә-бәйләнешләр һич тә өзелми. Бару-кайту, күченеп тору даими күренешкә әверелә. Әмма 1917 елдан соң, Финляндия бәйсезлек алгач, мондый бәйләнеш-аралашулар, күчешләр тәмам диярлек өзелә.

Финляндиядә татар рухының, миллилекнең саклануында андагы кавемдәшләребезнең, нигездә, бер төбәктән – Нижгар якларыннан, аеруча Яңапар (Актук) авылыннан булулары да мөһим роль уйный. Күпчелеге татар мәктәп-мәдрәсәсендә укыган, тиешле милли-әхлакый-дини-рухи тәрбия алган. Татарның җыр-моңыннан, сүз сәнгатеннән, «Кыйссаи Йосыф», «Рисаләи Газизә»ләрдән, аеруча заманның Гафури, Тукай, Исхакыйларыннан алар яхшы хәбәрдар булган. Биредәге милләттәшләребезнең шәхси китапханәләрендә Октябрьгә кадәр Рәсәйдә басылган күпләгән татар басмаларын үз күзләрем белән дә күп мәртәбәләр күрергә туры килде.

Ике ил арасында бару-кайтулар бик зәгыйфьләнгәч тә, Суомидагы кавемдәшләребез аптырап калмый: мәктәп-курслар ача, мәчетләр эшләп тора, төрле дини-милли-мәдәни чаралар уздыра. Чит мәмләкәтләр, аеруча ислам илләре, Төркия, аларда яшәгән милләттәшләребез белән ныклы мөнәсәбәтләр булдырыла. Шунысы мөһим: Суоми татарлары, элеккеге татарча басмаларны файдалану белән бергә, үзләре дә дистәләгән газета-журнал чыгара («Мәгърифәт», «Шималь очкыннары», «Ак юл», «Белдереш»), татарча китаплар бастыра.

Бу мәмләкәт, аеруча Хельсинки, Тампере һәм Ярвинпә калаларында бары меңгә якын милләттәшебезнең генә яшәве мәгълүм. Шунысы кызыклы: аларның берничә дистәсе китап чыгару, әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Арада хәтта 50дән артык китап (шигъри, чәчмә, драма, дәреслек, тарих…) чыгарган Хәсән Хәмидулла (1900-1988) кебек күренекле шәхесләр дә бар. Шулай ук Садрый Хәмид (1905-1987), Гәүһәр Туганай (1911-1998), Гайсә Хәкимҗан (1896-1972) һәм кайбер башка каләм әһелләренең дә исемнәре, әсәрләре укучыларга ярыйсы гына таныш. Янә шунысы гыйбрәтле: боларның төп шөгыльләре, нигездә, сату-алу, сәүдә. Әмма алар язу-сызуга, әдәби иҗатка да күп вакыт бирәләр, кавемдәшләрен милли-рухи тәрбияләү эшенең үзәгендә кайныйлар. **Хөсәен Садыйк** (24.12 1908-28.04.1974) – шундыйларның берсе һәм шактый күренеклесе. Ул да чыгышы белән Яңапардан. Суомида имам, шагыйрь, мәгърифәтче буларак та танылa. Бу зат «Фин-татар» («Төрек халык») мәктәбенең идарә хәятен дә дистә елдан артыграк (1958-1969) җитәкли, газета-журналлар чыгаруда да актив катнаша. Аның, ягъни «Садыйк нәүгы Хөсәен»нең эшчәнлеген чордашы, хезмәттәше Садрый Хәмид 1950 елда ук инде менә ничек бәяли:

«...Сатуларын якка ташлап, театрга да катнашыр,
Кирәк булса, милләт өчен аркасында таш ташыр.
Яшьләр белән бергәләшеп чыгардылар «Белдереш....»

Шушы зат 1969 елда Хельсинкида Г.Тукай әсәрләренең махсус җыентыгын туплап, аны латин хәрефләре белән нәшер итә (102 б.). «Abdulla Tukay Şìgirları» (Ciyştıruçı: Hüseyin Sadik) дип исемләнгән уртача форматтагы бу китап шагыйрьнең

рәсеме һәм төзүченең укучыларга мондый мөрәҗәгате белән ачыла: *«...Казан шивәсендә араб хоруфатендә (язуында. – Х.М.) басылган «Әсәр» һәм «Уку» китаплары яшьләребез өчен укырга авырлык китергәнлекдән, Абдулла Тукайның шигырьләрендән зур бер өлешен эченә алган вә сабыйлык вакытындагы үз каләме белән язылган тәрҗемәи хәле яшьләргә укыту вә шигырьләрен таныштыру максаты илә бу кечкенә китапчык яңа хәрефләр белән бастырылды...*

Ошбу шагыйрьне бастыру масрафлары (чыгымнары. – Х.М.) Финляндия Ислам мәхәлләсенең башканы (җитәкчесе. – Х.М.) хаҗи Осман Али әфәнденең хезмәте белән түләнде»* (4 б.).


Хөсәен Садыйк

Осман Али

Билгеле булганча, Финляндиядәге милләттәшләребез урыс (кирилл) язуын кабул итми. Гарәп графикасы белән янәшә алар 20 нче йөзнең урталарында өстәмә хәреф-тамгалар кертелгән үз язуларын – «латин әлифба»сын да куллана башлый. Җыентыкны төзүче «яңа хәрефләр» дигәндә, әнә шуны күздә тота. Габдулла, Гали исемнәренең Абдулла, Али дип бирелүләре, кайбер шундый хосусый күренешләр шул «яңа» графиканың таләпләре белән дә аңлатыла.

Мөһаҗәрәттә Тукай әсәрләрен бастыруның ярыйсы гына тарихы бар. Мәсәлән, Токиодагы «Матбагаи исламия»дә 1933 елда Тукай әсәрләренең биштомлыгы дөнья күрә (646 битлек). Ул гарәп язуында. 1953 елда Хельсинкида бөек шагыйрьнең гарәп графикасындагы «Мәктәбдә милли әдәбият дәресләре» исемле китабы нәшер ителә. Тукайның Ватаннан читтә басылган янә берничә китабы, газета-журналларда дөнья күргән шактый гына әсәрләре бар. Әмма аларның күпчелеге гарәп язуында. Илдәгеләре исә урыс графикасында. 1969 елгы Хельсинки басмасы исә, нәкъ әнә шул хосусиятне күздә тотып, Финляндиядәге яшь буынның ихтыяҗын искә алып әзерләнә.

* 1990 елда бу мәкаләнең авторына Осман ага белән очрашып сөйләшергә, хәтта аларның өендә кунак булырга да туры килде. Мәгънәле генә әңгәмәләр истә калган.

Тукай иҗатының югары сәнгати камиллеккә ия булуы, халыкчанлыгы, теленең искиткеч байлыгы, әсәрләренең көчле милли, әхлакый, инсани, дини рух белән сугарылуы һәркемгә билгеле. Шуңа күрә аның иҗат мирасыннан балалар һәм яшьләр ихтыяҗына, тәрбияви максатларга туры килешле әсәрләр сайлап алу шактый кыен һәм җаваплы эш. 1969 елгы Хельсинки басмасын төзүче Хөсәен Садыйк бу юнәлештә шактый уңышлы эш иткән. Кечкенә генә җыентыкта Тукай иҗатының асылын күз алдына китерерлек төрле характердагы һәм жанрдагы әсәрләр бар. Мәсәлән, без анда тезмә һәм чәчмә юллар белән дә, поэма, газәл, робагый, мәсәл, җыр, баллада һәм башка жанр үрнәкләре, шулай ук тәрҗемәләр белән дә очрашабыз. Болар арасында «Милли моңнар» (китап шуның белән ачыла), «Өч хакыйкать», «Су анасы», «Ана белән бала», «Туган илемә», «Туган тел», «Эшкә өндәү», «Өзелгән өмид» һәм башка шундый атаклы әсәрләр дә бар. Китапның «икенче» өлешендә «Исемдә калганнар» хатирәсе дә урнаштырылган. Болар белән очрашу укучыны милләтнең җаны, рухы белән тоташтыра, шагыйрь белән бер дулкында тибрәлергә, аның белән бергә куанырга, кайгырырга ярдәм итә. Автор теленең байлыгы, матурлыгы, моңы яшь буынның күңелен биләп ала, зиһенен баета, укучыны үз милләтенең улы, кызы итеп тәрбияләргә булыша. Китапта урнаштырылган 70ләп әсәрнең (икесе кабатлана) барысы да максатка ярашлы.

Мәгълүм ки, узган гасырның 60 нчы елларында Финляндиядәге кавемдәшләребез арасында халкыбызның тарихы, рухи-мәдәни мирасы белән кызыксыну тагын да көчәеп китә. 1967 елда күренекле татарпәрвәр Гомәр Таһир һәм мәшһүр тюрколог М.Рясянен катнашында «Тукай җәмгыяте» төзелә. 1969 елда дөнья күргән Тукай җыентыгы да шул дулкында туган мөһим вакыйгаларның берсе. Ул халыкта киң тарала, аеруча яшьләр арасында. Мин моны 1990 елда Финляндиядә өч айлык гыйльми сәфәрем вакытында үзем дә күрдем. Шунысын да әйтим: миңа бу китапны Хөсәен Садыйкның улы Нәгыйм әфәнде үзе бүләк итте. Мин аның гозерен Казанга кайту белән үтәдем. Музейга тапшырган китапта мондый юлларны теркәп куйганмын: *«Бу китапны Тукай музеена тапшырырга дип, җыентыкны төзүченең (ягъни Хөсәен ага Садыйкның) углы Нәгыйм (Наим) әфәнде Садыйк бирде. Ул әүвәл Хельсинки каласында яшәгән, татарлар арасында культура эшләрен оештыруда актив катнашкан. Бик матур җырлый. Хельсинкида моннан бер ел элек чыккан тәлинкә-пластинкада («Ак Идел буйлары») ул күп җырларны башлап җырлый. Бик татар җанлы кеше. Балалары да бик әйбәт татарча сөйләшә.*

Хәзерге вакытта Нәгыйм әфәнде Финляндиянең иң ямьле җирләреннән берсе булган Наантали каласында (Турку-Абодан 16 чакрым ераклыктагы диңгез буе шәһәрчеге) яши, антиквар әйберләр белән сату итә.

Безгә аның белән шушы елның март азакларында Або, Наанталида бергә булырга туры килде. Хатыйп Миңнегулов. 30.04.1990».

Без бүләк иткән 1969 елгы Тукай җыентыгы хәзерге вакытта шагыйрь музееның бик күркәм урыннарының берсендә тора. Шунысын да искә төшерим: без фәкыйрегез бу музейга Тукайның 1933 елда Токиода нәшер ителгән биштомлыгын һәм мөһаҗирлектә дөнья күргән кайбер башка басмаларны да бүләк иткән иде.

Хөсәен Садыйк хакында, аның улы Нәгыйм әфәнде белән 1990 һәм 2000 нче еллардагы очрашу истәлекләре, шулай ук 1969 елгы Тукай җыентыгы турында мәгълүматлар безнең «Дөньяда сүзебез бар» (К., 1990), «Чит илләрдәге татар әдәбияты» (К., 2007), «Озын гомерем хатирәләре. II кисәк» (К., 2020; IX бүлек) китапларында һәм кайбер башка хезмәтләребездә дә бар. ■

«Алар бик нык ышаналар...»

(Нурихан Фәттах көндәлегеннән)

Укучылар хозурына тәкъдим ителгән әлеге юллар Нуриханның көндәлегеннән. Ул аларны университетны тәмамлап Яңавылга кайткан көннәрдә язган булган. Көндәлектә телгә алынган Шамил абый Нурихан турында мәкалә яза алмады, кызганыч ки, бик иртә вафат булды ул.

Руфинә Фәттахова

Тарих-филология факультетының татар әдәбияты бүлеге студентлары (КДУ, IV курс): беренче рәттә сулдан – Роза Хафизова, ..., ..., уңда – Сәгадәт Ибраһимов; икенче рәттә – Фатих Хәсәнов, ..., ..., Рафак Тимергалин; өченче рәттә – Нурихан Фәттах, Настя Боярова, Зәет Мәҗитов. 1950 ел, май



Көндәлек бите

* * *

12 август, 1951 ел

…Иртән Шамил абыйга бардым *(Шамил абый – укытучы, ул елларда мәктәпнең завучы иде.* – Р.Ф.). Бик озак сөйләшеп, гәп сатып утырдык. Әдәбият, культура, татар, башкорт турында, политика һ.б. турында сөйләштек. Бик башлы, ерактан күрә торган, дөрес фикер йөртә торган кеше ул. Әдәбият буенча кайбер әсәрләргә, кешеләргә һ.б.-ларга дөрес сүз әйтә, дөрес фикер йөртә. Мәсәлән: «Далеко от Москвы» *(Василий Ажаев романы.* – Р.Ф.) озак яшәмәячәк, онытылыр ул, – ди.

– Мин аны укып чыктым – онытылды да, ә классиклар гомергә яшиләр, – ди. – Шагыйрьләрне (башкорт) яратып җиткерми, көчәнеп язалар, язарга кирәк өчен генә, берние дулкынландырмый, – ди. – Менә Такташлар, Тукайлар язган!» – ди.

Минем 10 нчы класста аттестат өчен язган сочинением (рус теленнән) анда икән. Унны бетерүгә, мине медальгә дип (алтын медальгә), эшләрне Уфага алып барган иде ул. Монда отлично булган шул сочинениедә берничә элементар кагыйдә буенча бик тупас хата чыккан. Шуңа бирмәгәннәр миңа медальне. «Пашы Ангелиной…» дип язганмын *(Прасковья (Паша) Ангелина – СССРдагы беренче тракторчы хатын-кыз, стахановчы. – Р.Ф.).* Эчтәлек тә, бөтен нәрсә дә килгән, тик әнә шул бозды, ди. Ул сочинение Шамил абыйда саклана икән. Сораган идем, күрсәтмим, ди. «Син зур кеше, язучы булгач, мин аны матбугатта файдаланам, – ди. – Менә шулай-шулай, сочинениедә язучы булу турында язган иде (сочинениедән цитаталар китерәм, ди), менә хәзер шулай булды, дип әйтәм, – ди. – Шуңача саклыйм әле», – ди.

Миңа кызык, көләм. Алар бик нык ышаналар, өмет баглыйлар инде миңа. Ничек булыр шул.

13 август

Бүген көчкә буа буена барып кайттым. Йөзеп булмый – Казандагы кебек. Бар курыкканым шул: ничек кенә эшләрмен икән. Күп укып, язып утырып булмый, баш ката, аяклар өшергә тотына, йөрәк дөп-дөп тибә. Рәт китте минем. «Татар халык иҗаты»н көчкә укып чыктым. Ничек рецензия язарга белмим, ә язарга кирәк. Казанга барганчы язарга кирәк. Бер хикәя уйладым («Вакыты шундый»ны яңартып), аны да язу әмәле юк, тәрҗемә дә шул көе…

14 август

Розадан *(Роза Хафизова. – Ред.)* бернинди хәбәр юк. Хәл начар, йөри алмыйм, Казандагы кебек. Ничек эшләрмен инде – котлар алына. Әгәр бөтенләй эшкә ярамасам? Әгәр башның рәте булмаса? Просто нәрсә уйларга да белмим. Сәламәтлек бозылып беткән. Укуын-укыдым, биш ел интектем, «рәхәтен» күрмәсәм, файда алмасам – ох, нинди кыен, шушы яшьтән үк шулай булуы!

15 август

Розадан ике хат бар. Берсен авылдан, икенчесен Уфадан, поездда барганда язган. Икесе дә әйбәт, озын. Сагынадыр кебек күренә, җылы хисле. Ә минем бер хисем дә юк. Салкын тиде, уйлый да алмыйм. Гомумән, быел капут инде миңа. Берни эш чыгарып булмас кебек – куркам. Терелгән юк. Просто ужас, Саимә *(Саимә Ибраһимова. – Ред.)* әйткәндәй…

18 август

Кичәле-бүгенле бик күп баш эше эшләдем әле. Рецензияне җиңел җирдән – азактан тотындым язарга (хурлаган җире). Тәрҗемәне тикшердем күп кенә. Тик озак утырып булмый, күп булса, ярты сәгать, аннан соң баш бернигә дә ярамый. Шулай да канәгатьләнү туды, пессимизм бетте, диярга була. Ышаныч бар. Казанга баргач, лечениегә йөрермен, рәтләнермен әле. Көн дә бик шәп хәзер. Кояш, эссе, күктә бер генә болыт та юк. Августтан башлап шулай. Күңелле, көн әйбәт булгач. ■

Безнең мирас №8 август 2021

ӘДИП МАЛИКОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Әдип абый – әдәп үрнәге

Эльмира Шәрифуллина

Яраткан шагыйрәбез, шагыйрь Әдип Маликовның хәләл җефете – берничә ел элек кенә 50 яшен тутырган Саҗидә апа Сөләйманованың вафаты бик күпләргә авыр тәэсир итте. Бауман урамындагы Матбугат йортының Тукай клубында үткәрелгән кичәсендә дәртләнеп-ялкынланып шигырьләрен укуы әле дә күз алдында. Искиткеч сылу буй-сын. Кара күлмәгенең җиң очларына, яка уемы тирәсенә ак мех тотылган. Тавышы йомшак, йөзе мөлаем, һәр хәрәкәтендә инсафлылык, күңеленнән, моң булып, шигырьләр агыла...

Югалту ачысы белән язган багышлавым «Татарстан яшьләре» газетасының 1981 елгы 21 июль санында басылды.

Саҗидә апа

Ай-ли, Саҗидә,
Керләр чайкый сай җирдә...

Халык җыры

Алкын суга карап уйларыма чумам,
Дәрья буйларына киләм дә.
Саҗидә апа,
Ай-һай, керләреңне
Чайкагансың икән тирәндә.
Бөтерелеп ага дәрья суы,
Күтәрелә көмеш күбекләр.
Басма өсләрендә – ак сөлгеләр,
Түрләмәләр –
Кершән кебекләр.
Шундый нәфис, гүя берәмтекләп
Таң нурына манып алынган.
Һәркайсына сеңгән балан исе,
Алан исе сеңгән җаныңнан.
Саҗидә апа, ап-ак керләреңне
Чайкагансың бигрәк тирәндә.
Ак сурәтең калды күңелләрдә,
Пакь эзләрең – йөргән җирләрдә!..

1980, 10 май

Шуннан соң күп тә үтми, Саҗидә апаның ире Әдип абый Маликовтан хат алдым. Озын булмаган ул хат зур рәхмәт хисе белән сугарылган иде. Кызганыч, мин ул кадерле ядкярне саклый алмаганмын. Шуннан соң инде Әдип абыйга язмышлар охшашлыгы белән язылган, бер-бер артлы нәшер ителгән ике китабымны җибәрдем. Аларга мондый җаваплар килде.





Кадерле Эльмира!

«Яңгыр җиле» җыентыгың белән чын күңелдән котлыйм. Искә алып миңа җибәрүең өчен рәхмәт. Зөлфәтнең бик матур кереш сүзе белән, ягымлы, шигъри рәсемең белән ачылган бу китап шунда ук үзенә алып кереп китә, җибәрми.

Көчле йөрәк тибрәнешләре, хисләр өермәсе. Саҗидә әйтмешли, язмышлар бәрелеше... Якты моң һәм кайгы-хәсрәт упкыннары. Ансыз шигърият буламыни?!

Мин шагыйрәләребезнең, шул исәптән, синең шигырьләреңне дә күзәтеп, укып барам. Сөенәм, борчылам кайчакта, горурланам да. Борчылам, чөнки бездә моңа кадәр хатын-кыз язучыларны җәберсетеп килделәр. Дөресрәге, күрмәмешкә салышып узарга тырыштылар. Зөлфәт сүзләре белән әйтсәк, «яклауга мохтаҗ» гүзәлләребез үзләре дә шуңа ризалашкан сыманрак яшәделәр. Күрәсең, алай ярамый. Көрәшергә, көрәшергә кирәк. Гаделсезлекнең йөзенә бәреп әйтергә!

Хатымны соңлабрак язам, дөнья мәшәкатьләре бөтереп алды бу атналарда: бер йорттан икенче йортка күченеп йөрдек. Адреска да аз гына үзгәреш керде: Әлмәт, Ленин урамы, 29, кв.12.

Очрашканда бер сөйләшербез әле.

Батыр бул, Эльмира!

Яңа иҗат үрләре теләп, ихтирам белән, ***Әдип Маликов.***

20/VI – 84.

Исәнме, Эльмира сеңлем!

Мине искә алып, санга сугып дигәндәй, «Мизгел»еңне җибәргән өчен бик зур рәхмәт. Повестьларыңны укып чыктым. Яңа китабың белән котлыйм!

«Социалистик Татарстан»да Ләбибәнең рецензиясен укып чыккач та, бу китапны кулга төшерим әле дип уйланып утырган идем. Озак та үтмәде, синнән бандероль килеп төште. Уйларымны белгәндәй.

Әсәрләреңә, бигрәк тә беренчесенә карата, нәкъ үзеңчә, болай диясе килә: «Әйтерсең, хәрефләр, сүзләр язмыйсың, бәлки, йөрәгеңнең кардиограммасын төшерәсең». Әйе, чынлап та, йөрәк кардиограммасы! Аны бит сызып та, төзәтеп тә, арттырып та, киметеп тә булмый.

Бөтенесен кичереп, үз кичерешләремне өстәп, бер тында укып чыктым. Минем дә үз тормышыбыз турында яза башлаган повестем бар. Башларга куркып йөрдем, хәзер тагын тукталып калдым. Җиңел түгел андый әсәрне язуы. Йөрәк өзгәләнгән чакта бигрәк тә. Утырып җылыйсы гына килә...

Түземлек телим, яңа иҗат уңышлары!

Сәламәт бул!

Хөрмәт белән, ***Әдип Маликов.***
18/VII – 86.

***

Еллар үтте… 2014 елда Татнефть акционерлар җәмгыятенең Саҗидә Сөләйманова исемендәге бүләген алу шатлыгын кичердем. Бу вакытта Әдип абый вафат иде. Әмма исән чагында аның белән берничә тапкыр очрашырга, сөйләшеп торырга да насыйп булды. Ул 2006 елда бирелә башлаган әлеге бүләккә минем беренчеләрдән булып лаек икәнлегемне дә әйткән булган…

Югалтулар… Бәхилләшүләр… Иҗат юлымдагы якты маяклар…

Саҗидә апа Сөләйманова әдәбиятыбызның ак алиһәсе булып күңелгә сеңсә, Әдип абый Маликов әдәп-әхлак үрнәге булып хәтердә калды. Урыннары оҗмахта булсын! ■

Безнең мирас №8 август 2021

Ышанычыбыз аклана

Минтимер Шәймиев,
ТССР Югары Советы Рәисе

Фоторәсемдә (сулдан уңга): Әтнә районы «Искра» хуҗалыгының элеккеге рәисе Фәйзи Галиев, ТР Президенты Минтимер Шәймиев, Әтнә районы башлыгы Габделәхәт Хәкимов Олы Әтнәдә мәдәният-спорт комплексын ачу тантанасында. 4 июль, 2005 ел

Габделәхәт Гыйлемхан улы Хәкимов, үзенең якташлары белән бергә, Татарстаныбыз тарихында шактый тирән эз калдырды. 1990 елда Әтнә кешеләренең район статусын кайтару өчен көрәше Татарстанның илкүләм мөстәкыйльлеккә омтылышыннан ким булмады дияр идем. Бу вакыйга хәтеребезгә тирән уелып калды. Бүген дә иманым камил: халык фикеренә колак салып дөрес эшләдек. Бу гамәлнең татар халкы өчен тирән мәгънәсе бар. Әтнә җирлеге Татарстанның үткәнендә дә, хәзергесендә дә, киләчәгендә дә аерым вазыйфага ия.

1990 елда Әтнәдә районны яңадан оештыру белән котлап чыгыш ясаганда: «Сезнең районны тергезүнең төп максаты – Казан артында татар мохитен, милләтебезнең телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен алга таба үстерергә һәм баетырга лаеклы җирлек саклап калу. Элек-электән үк кыйблагыз шушы булган һәм бүгеннән башлап, яңа сулыш белән, сез бу изге юлны дәвам итәргә тиеш. Әгәр дә халкыбызның шушы олы ышанычын акласагыз – районны тергезүнең иң күркәм җимеше шушы булыр», – дидем. Бу сүзләрне район халкы рухланып кабул итте.

Бүген горурланып-сокланып әйтәсем килә: Әтнә кешеләре, Габделәхәт Гыйлемхан улы җитәкчелегендә, үз сүзләрендә тордылар. Әтнә районы ана телебезне, милли мәдәниятебезне, сәнгатебезне, борынгы гореф-гадәтләребезне саклауда бөтен республикага үрнәк булып тора.

Габделәхәт Гыйлемхан улы – эшлекле һәм кешелекле, тәҗрибәле, кешеләрне ярата торган зирәк һәм милли җанлы җитәкче. Аның әлеге асыл сыйфатлары туган җире Әтнә районын җитәкләгән өч дистә ел дәвамында бик ачык чагылыш тапты. Габделәхәт Гыйлемхан улының күпьеллык намуслы һәм фидакарь хезмәте халкыбызның олы рәхмәтенә һәм ихтирамына лаек дип саныйм. ■

Күмәчче Хәким оныгы яки Бисмиллалы гомер

Ләбиб Лерон

«Үз халкыңның насыйп икмәгенә
Кушылганда йөрәк җылысы,
Булыр синең яшәвеңдә мәгънә
*Һәм бәхетнең җирдә олысы».**

Гөлүсә Батталова

Адәм баласы бары тик үз җирендә, туган төбәгендә генә аягында нык басып торадыр, үзен чын мәгънәсендә җир кешесе итеп тоядыр ул. Гап-гади игенчеме син, терлек карауччы яисә җитәкче-фәләнме – кем генә булсаң да, авылдашларыңның, якташларыңның хәерһаклы карашын, җылы мөнәсәбәтен, ихлас ярдәмен тойганда гына, кыласы эш-гамәлләреңнең нәтиҗәсе уңышлы буладыр. Әгәр инде күңелеңдә иман нурлары да булып, ният-теләкләрең изгедән икән, бисмиллалы гомерең бәрәкәттә үтә, киләчәгең якты, ышанычлы була.

«Меңнәр пышылдаган рәхмәт булып,
Нигезенә кайткан юл булып –
Игелектән торган үз юлында
Чын бәхетен табар юлыгып!»

Әтнә районы хакимияте башлыгы Габделәхәт Гыйлемхан улы Хәкимов белән гәпләшкән вакытта мин шул хакта уйлап куйдым.

* Язмада Әтнә районының Түбән Шашы авылы кызы, шагыйрә Гөлүсә Батталованың «Ир язмышы» дигән поэмасыннан шигъри юллар файдаланылды.

Асыл шәхесләрнең чишмә башы

«Бу нәселнең чишмә башы кайда?
Кендек каны тамган туфрагы?»

Олы Әтнә һәм аның күренекле шәхесләре хакында сүз чыккач, Габделәхәт Гыйлемхан улы, зур горурлык хисләре белән, болай диде: «Олы Әтнәдән 20 километр радиуста урнашкан авылларны күздән кичерсәк, алардан татар халкының асыл шәхесләре чыкканын күрербез».

Шуннан соң ул сөекле шагыйребез Габдулла Тукай (1886-1913), мәшһүрләребез – олуг галим һәм дин әһеле Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889), беренче гильдия сәүдәгәр Ногман Габделкәримов (1840-1918), сәясәтче-галим, дәүләт эшлеклесе Садри Максуди (1878-1957), тарихчы-галим, җәмәгать эшлеклесе Хәсәнгата Габәши (1863-1936), тарихчы, язучы, имам-хатип Шаһиәхмәд Мәңгәри (1860-1935), атаклы композиторлар Салих Сәйдәшев (1900-1954) һәм Солтан Габәши (1891-1942), профессор, Төркия һәм Германия Фәннәр академиясе академигы Рәшит Рәхмәти Арат (1900-1964), сәүдәгәр-эшкуар, «Мәңгәрләр» автоконцернына нигез салучы, Анкарада «Казан» журналын чыгарган Әхмәтвәли Мәңгәри (1891-1978), әдипләребез Сибгат Хәким (1911-1986), Хакимҗан Халиков (1933-2002), Самат Шакир ((1924-1998), Нәҗип Мадьяров (1928-2002) һәм Фирая Зыятдинова (1945-2006), шулай ук ата-бабаларының төп чыгышлары шушы төбәктән булган күренекле артист-режиссерлар Хәким Сәлимҗанов (1903-1981) белән Рәфкать Бикчәнтәев (1924-1975) һәм галим Марсель Әхмәтҗанов (1939) исемнәрен санап үтте.

Әнә шундый мәшһүр кешеләре белән данлыклы Әтнәнең матур табигатьле Комыргуҗа авылында туган Габделәхәт Гыйлемхан улының тормыш юлын күздән кичергәндә, кайбер фактларга игътибар итми мөмкин түгел.

Әтнә базары

«Буыннардан буыннарга җитәр
Ак күмәчле Апуш догасы».

Әүвәл Г.Тукайның «Исемдә калганнар»ындагы ошбу өзеккә игътибар итик әле:

«Кайвакыт җәй көне әти белән Әтнә базарына бара идек. Ул үзенең хезмәтләре илә базар арасында йөргәндә, мин атны тотып тора идем.

Авылыбыз мулласы Фәтхерахман хәзрәт, белмим, бер заман әтинең шәриге йә дусты булганмы, нидәндер, миңа атна саен 5 тиен акча бирә иде. Мин ул акчага Әтнә базарында ак күмәч сатып алып, өйгә кайтканда, юл буе ашап кайта идем. Әти мәрхүм, арбаның артында күмәч ашап утырганда, миңа кисәктән әйләнеп карап: «Күмәчеңне әниеңә дә калдыр!» – дип куя иде. Мин дә, әлбәттә, ярар, дия торган идем. Ләкин ул күмәч авылга кайтып җиткәнче, вак-вак кына капкаласам

да, әнигә кала идеме, юкмы – анысын хәтерләмим».

Габделәхәтнең бабасын – заманында Әтнә, Ашыт, Арча һәм Алат базарларында сәүдә иткән, ятимнәргә, мохтаҗларга һәрвакыт өлеш чыгарган Хәкимҗан бабайны, яратып, үз итеп, «Күмәчче Хәким» дип йөрткәннәр. Аның күмәчләрен чират торып, мактый-мактый алганнар. «Бисмилла әйтеп, җиренә җиткереп әзерләнгән ризык тәнгә сихәт, җанга рәхәт бирә ул», – дип әйтә торган булган Хәким бабай.

Кем белә, нәни Апуш (булачак Тукаебыз!), бәлкем, нәкъ менә Хәким бабайның күмәчен авыз иткәндер дә әле?!.



Әтнәдәге Җомга базары

Ата-ана нәсыйхәте

«Әти нәсыйхәте канун кебек –
Тәртип кирәк яшьтән тормышта...»

Габделәхәтнең әтисе Гыйлемхан Хәкимҗан улы туры сүзле, кырыс холыклы, гаделлек өчен көрәшүче кеше була. Тормышның ачысын-төчесен күп татыган Гыйлемхан аганың балаларына таләбе дә катгый, үгет-нәсыйхәте дә үтемле: «Авызыгызга ризык алганда, бисмилла әйтмичә капмагыз. Шәригать кушканча, туяр-туймас кына ашагыз!»

Әнисе Гөләндәм дә ире Гыйлемханның сүзләрен һәрдаим куәтләп, бисмилла әйтү кирәклеген балаларының, оныкларының исләренә төшереп тора.

«Әти кырыслыгы, Әни назы –
Бала җаны барын сеңдерә...»

Миһербанлы, якты күңелле Ата белән Ана, Хәким бабай белән Мәхфүзә әбинең һәм үзләренең яшәү рәвеше үрнәгендә, газиз балаларына бары тик игелекле эшгамәл белән генә тормышта үз урыныңны табу мөмкин икәнлегенә төшендерә. Мәҗит Гафури сүзләре белән әйтсәк:

«Армый-талмый эшләгәндә, һәр теләккә ирешелә;
Якты көннәр, зур бәхетләр эшләгәнлектән килә.
Тырышып эшләүләр кешеләрне югары мендерә.
Эш кенә кешене кеше итә, тугъры юлга күндерә.

Безнең мирас №8 август 2021

Эш белән генә кеше дөньяда шат һәм шәп тора,
Эш кешенең кешелеген дә, дәрәҗәсен дә арттыра».

Күпмедер вакыт үтәр һәм көннәрдән беркөнне Гыйлемхан ага улына: «Сиңа тау калдырып китәм!» – дияр. Әлеге тирән мәгънәле сүзләрне мәңгегә күңеленә беркеткән Габделәхәт үзе исә, кылган-эш гамәлләрен күздән кичереп, мондыйрак фикергә килер: «Кайда гына, нинди генә вазыйфада эшләсәм дә, гомер юлымда мине аңлаучылар, миңа ярдәм кулы сузучылар, чын-чынлап булышучылар очрап торды».

Габделәхәт Хәкимов әти-әнисе, хатыны Сәрия, кызлары Ләйсән һәм Гөлсем белән

Бисмиллалы гомер – бәрәкәтле тормыш… Бу нәсыйхәт Габделәхәт Гыйлемхан улының яшәү рәвешенә әйләнә.

Кайда да тырышырга кирәк

«Сынауларда сынмас нәселдән ул!
Караш горур! Йөрәк тынгысыз!
Хәләл хезмәт – аның өчен иман,
Авыр эшкә куллар талымсыз!»

Габделәхәт Гыйлемхан улы хезмәт эшчәнлеген Сәрдә, Кушлавыч һәм Иске Җөлби авылларын берләштерүче Тукай исемендәге колхозда баш зоотехник буларак башлый. Армиядән туп-туры туган авылы Комыргуҗага кайта һәм «Шахтер» колхозында янә бер ел баш зоотехник вазыйфасын башкара. 1980 елда исә шул ук колхозның рәисе итеп сайлана. Моңарчы артта барган колхоз тиз арада алдынгылар сафына баса. Сарык асрауга тәгаенләнгән комплексны сүтеп дигәндәй, аны савым сыерлары асрау өчен көйләп-җайлап куйгач, сөт җитештерүдә һәм шулай ук игенчелектә дә алга китеш нык сизелә – колхоз беренче урыннарны яулый башлый. Хуҗалыкта төзелеш киң колач җәя: ындыр табаклары, күперләр, ашлама складлары төзелә, элекке корылмалар төзекләндерелә, юллар салына. Нәкъ менә шул вакытларда күрсәткән тырыш хезмәте өчен 1985 елда Габделәхәт Хәкимовка «Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә. Бераздан инде аңа яңа вазыйфа йөклиләр – ул Әтнәдәге совхоз-техникумга җитәкче булып килә. Әтисе

шикелле кырыс, усал һәм таләпчән җитәкче булып танылган Габделәхәтне яңа эшкә тәкъдим иткәндә, авыл хуҗалыгы идарәсенең ул чактагы җитәкчесе Вәгыйз Минһаҗев: «Монда да сиңа усалланырга, упкындагы хуҗалыкны тартып чыгарырга кирәк булачак!» – ди.

Алда исә аны яңа вазыйфа, яңа мәшәкатьләр, яңа җиңүләр көтә... Әйе, эш дигәндә бер дә тынгы белмәгән Габделәхәт Хәкимов кыска гына вакыт арасында үзе җитәкчелек иткән совхоз-техникумны Россия күләмендә иң алдынгылар рәтенә чыгара. Тырышкан табар, ташка кадак кагар, диләр андыйлар турында. Хак сүзләр...

Әтнәлеләр наказы

«Тау калдырам», – дигән әти сүзе
Әллә инде изге фал микән?
Туган җиргә яңа гомер бирү –
Моннан да зур бәхет бар микән?»

1989 ел. Татарстан АССР Югары Советына (ул чакта Дәүләт Советы дип аталмый әле) депутатлыка кандидатлар күрсәтү башланган чак. Габделәхәт Гыйлемхан улы, әтнәлеләр үтенечен истә тотып, депутатлыкка кандидат итеп теркәлергә батырчылык итә. Арча районын аркылыга-буйга йөреп, сайлаучылардан наказлар ала ул. Әтнә районын кабат торгызу, Олы Әтнәдә яңа хастаханә төзетү һәм мәчет салдыру – менә шушы өч наказ Габделәхәтнең күңеленә аеруча якын була. Чөнки ул үзе дә болар хакында күптәннән борчылып, бу эшләрне ничек тә башкарып чыгарга иде бит, дип, адарынып, уйланып йөри.

1990 елның мартында Габделәхәт Хәкимов ТАССР Югары Советы депутаты итеп сайлана. Менә шуннан соң әлеге үтә әһәмиятле эшләрне гамәлгә ашыру өчен чын мәгънәсендә көрәш башлана. Хастаханә комплексының проекты юк, дип, төрле каршылыклар китереп чыгаручылар табыла. Совхоз-техникум директоры гына булуына карамастан, Украина сәламәтлек саклау фәнни-тикшеренү институтына мөрәҗәгать итеп, проект ясата ул. Совхоз проект өчен генә дә 120 мең сум акча түли. Заманы өчен бу искиткеч зур акча – 15 «КамАЗ» машинасы бәясе. Зур тырышлыклар нәтиҗәсендә, ниһаять, хастаханәгә нигез салына...

Икенче наказ – арада иң авыры, иң катлаулысы – Әтнә районын кабат торгызу. 1990 елның 5 маенда Габделәхәт Гыйлемхан улы колхоз рәисләрен киңәшмәгә җыя. Әтнә районын оештыру буенча ун кешедән торган инициатив төркем төзелә. Шунда районны кабат кайтару мәсьәләсен кузгата. Районны торгызуны яклап, бер тәүлек эчендә 15 мең имза җыела. Әтнә районын оештыру буенча ун кешедән торган инициатив төркем төзелә. Халыкның Әтнә районын кайтаруны соравы турындагы хатын Татарстан Министрлар Советы Рәисенең урынбасары Мансур Хәсән улы Хәсәновка илтеп тапшыралар. Әлеге мәсьәлә буенча Министрлар Советы дүрт мәртәбә

утырыш үткәрә (шуның берсе Әтнәдә уза), аларның дүртесендә дә «Әтнә районын торгызу икътисади яктан отышлы түгел» дигән карар кабул ителә. Нервылар киеренке чак. Әтнә халкы, Габделәхәт Гыйлемхан улы җитәкчелегендә, кискен адымнар ясарга, әйтик, 40 автобуска төялеп, Казанның Ирек мәйданына барырга әзер була.

«Ышанганда сиңа меңләп йөрәк,
Син өмете булсаң халыкның,
Була икән таулар күчерергә,
Хакыйкатен аңлап тарихның...»

Шул киеренке көннәрдә Татарстан Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев инициатив төркемне үз янына чакыртып ала да: «Тынычланыгыз, район булыр!» – ди...

«Ил башында – татар зирәклеге:
«Килегез, – ди, – уйлыйк, сөйләшик.
Кайнар йөрәк түгел, салкын акыл,
Гамьле әңгәмәдә киңәшик!»

Шулай итеп, 1990 елның 25 октябрендә, Минтимер Шәрип улының фатихасы белән, Әтнә районы яңадан торгызыла.

ТССР Югары Советы Президиуымы Указы

ТССРның Әтнә районын оештыру турында ТССР Югары Советы Президиумы карар бирә:

1. Татарстан ССР составында тәкъдим ителгән картага туры китереп, Татарстан ССРның Арча районы территориясенең бер өлеше исәбеннән административ үзәге Олы Әтнә авылында булган Әтнә районын оештырырга.

2. Әтнә районы составына Олы Әтнә, Комыргуҗа, Түбән Бәрәскә, Түбән Көек, Күлле Киме, Күәм, Яңа Шашы, Кышлау, Күңгәр, Олы Мәңгәр Авыл Советлары, Арча районының Югары Сәрдә Авыл Советына караган Югары Сәрдә авылын кертергә.

ТССР Югары Советы Рәисе М.Ш.ШӘЙМИЕВ
Казан, Кремль, 25 октябрь, 1990 ел.

Иман нуры

«Ир-егеткә туган җире кирәк,
Хөр тормышлы газиз кешеләр.
Тигез юллар, мәчет, хастаханә –
Читтә торсын дошман ишеләр!»

Өченче наказ – мәчет салдыру. 1997 елның 11 июлендә үзенчәлекле архитектура стиле белән төзелгән яңа мәчет – «Әхәт» мәчете ачыла. «Әхәт» – Аллаһы Тәгаләнең күркәм исемнәреннән берсе, гарәп теленнән «бердәнбер» дигәнне аңлата. Мәчет ачылган көнне яңа хастаханә дә эшли башлый. Ачылышта Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев тә катнаша.

Элек-электән укымышлы, мәгърифәтле, иманлы булган Әтнә халкы, аңа рәхмәтләрен укый-укый, мәчеткә тартыла.

Һәрнәрсәнең үз вакыты, дигәндәй… 2018 елда хакимият башлыгы Габделәхәт Гыйлемхан улы хаҗ кылып кайта.

Үз гомерендә бик күп сынау кичә ул, берничә мәртәбә үлем белән күзгә-күз очраша…

«Үлем белән күзгә-күз очрашкан
Минутлары шактый күп булды.
Егылганда, кулларыннан тотып,
Күкләр аны үзе торгызды!
Ничә тапкыр саклап кала аны
Ата-ана хәер-догасы.
Иман, Коръән – сөйләп йөрмәсә дә,
Тумыштан ук Ирнең кыйбласы…»

Хак юл

«Тауга менсәң, яңа үрләр балкый,
Юллар әйди һаман биеккә.
Әтнә җире фатихасын бирә
Таулар буйсындырган егеткә».

Дөнья бит бу, диярсең: Әтнәгә кызыгучылар, районны бетерергә тырышучылар, аны күпсенүчеләр 2005 елда Әтнә районын эре инвесторга бирергә җыена. Әмма ниятләрен тормышка ашыра алмый калалар. Хакимият башлыгы Габделәхәт Хәкимов районны саклап калуга бөтен көчен куя.

Нәтиҗәдә, Минтимер Шәрип улының вакытында дөрес карар кабул итүе һәм, әлбәттә, аның турыдан-туры ярдәме белән, авыл хуҗалыгы, колхозлар, эшче халык һәм аларга эш урыны саклап калына.

«Без дөрес юлдан барабыз дип уйлыйм», – ди Габделәхәт Гыйлемхан улы.

Мин дә шундый фикердә: хакимият башлыгы хак юлда. Бисмилла әйтеп, Олы Тормыш юлына чыккан Юлчысын Аллаһы Тәгалә адаштырмас, ялгыш юлдан җибәрмәс, дим...

Иң зур байлык – халык

«Тауга каршы атлый – тәкъдиредер,
Аллаһ язган лаек язмышы!
Колагында һаман әтисенең:
«Тау калдырам!» – дигән тавышы».

Әтнә – авыл хуҗалыгы районы. Аның бөтен матди байлыгы – игенчелек һәм терлекчелек. Әтнәдә 46 мең гектар сөрү җире бар. Чагыштыру өчен: күрше Арча районында 120 мең гектар. Хәзерге көндә Әтнә тәүлегенә 280 мең тонна сөт сата. Игенчелек тармагында да шундый ук казанышлар. Мәгълүм хакыйкать: игенчеләр нәтиҗәле эшләмәсә, терлекчелектә уңышка ирешү мөмкин түгел.

Районны яңадан торгызу һәм икъдисади кыен шартларда да аны саклап кала алу – Әтнәнең үзе өчен генә түгел, республикабыз өчен дә мөһим казанышларыбыздан берсе. Һәрхәлдә, ул казаныш әтнәлеләр кылган эш-гамәлләрнең күркәм нәтиҗәсе саналырга лаек.

Г.Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт драма театрында Гөлүсә Батталова пьесасы буенча куелган «Җомга базары» спектакленнән Күмәчче Хәкимгә нисбәтле күренеш. 2020 ел

Бер караганда, әтнәлеләрнең бөтен теләкләре үтәлгән, алай гына да түгел, республикабыз горурлыгы булырлык зур эшләр башкарылган. Берәү бу очракта, аптырап: «Нәрсә җитми бу кешегә, тынычланып, инде рәхәтләнеп үзе өчен генә яшисе дә яшисе?!» – дип сорап куяр.

Габделәхәт Гыйлемхан улын аңлау өчен, бернәрсәне онытмаска кирәк: халык язмышын үз язмышыдай кабул итеп, кешеләргә мөмкин кадәр күбрәк игелек кылырга омтылу – аның яшәү рәвеше. Ирексездән, зирәк акыл иясе булган Гыйлемхан аганың улына әйткән: «Сиңа тау калдырып китәм!» – дигән хикмәтле сүзләре искә төшә. Димәк, Габделәхәт Гыйлемхан улын әле алда тагын да зуррак эшләр көтә... ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – галимнәр, язучылар, журналистлар һәм сәнгать әһелләре август аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Менә алар:

1 август – археолог, тарих фәннәре докторы, ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2004), ТРның атказанган фән эшлеклесе, ТРның фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт премиясе лауреаты **Фаяз Шәрип улы Хуҗин**га 70 яшь (1951);

1 август – физик, физика-математика фәннәре кандидаты, икътисад фәннәре докторы, профессор, Россия Мәгариф академиясе һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы, Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры **Илшат Рәфкать улы Гафуров**ка 60 яшь (1961);

5 август – рәссам, график, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б.И.Урманче исемендәге премиясе лауреаты **Надир Усман улы Әлмиев**кә 75 яшь (1946);

18 август – актер, драматург, ТР Язучылар берлеге әгъзасы (2007), Татарстан Республикасының атказанган артисты (2003) **Шамил Тимергали улы Фәрхетдинов**ка 50 яшь (1971);

23 август – актриса, Татарстан Республикасының халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты **Дания Нургаяз кызы Нуруллина**га 75 яшь (1946);

26 август – шагыйрә, ТР Язучылар берлеге әгъзасы (2011) С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты (2015) **Сирень Мөхибулла кызы Якупова**га 60 яшь (1961);

27 август – журналист, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре **Шамил Шәмси улы Хамматов**ка 75 яшь (1946).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз!

Безнең мирас №8 август 2021

Себер сүзе

Фәүзия Бәйрәмова

Фагыйлә Чумарова ире Раил белән Кумыслы күл буенда

Себердә беренче татарча газета 1912 елда Томск шәһәрендә чыга, аны Фатыймаи-Фәридә һәм Мөхәммәтвагыйз Нәүрузевлар нәшер итәләр. «Сибирия» исеме астында 1913 елның августына чаклы чыккан бу газетаның 145 саны дөнья күрә, анда милләт тормышы, дин-әхлак, мәгърифәт, хатын-кызлар мәсьәләләре киң яктыртыла. Газетаны, нигездә, Фатыймаи-Фәридә ханым чыгара, бу милли матбугат тиз арада бөтен Рәсәй мөселман-татарларының яраткан газетасына әйләнә.

90 ел үткәч, 2003 елда Омск шәһәрендә «Татар дөньясы» дип аталган татарча газета чыга башлый. Мин аны «Милләт тормышының елъязмачысы» дип атадым, чөнки анда милли, мәдәни һәм дини темаларга халык өчен бик файдалы мәкаләләр бастырыла, ә төбәк тарихын яктырткан язмаларны «Себер энциклопедиясе» дип атарга мөмкин. Бу газета аша Омск төбәгендә туып-үскән һәм милләтебезгә хезмәт иткән бик күп күренекле шәхесләрнең тарихы белән танышырга мөмкин, алар халкыбыз өчен горурлык хисләре уята.

Омск өлкәсенә мин 2007 елның апреленнән даими рәвештә бара башладым. Бу Тара шәһәрендә туып-үскән дин әһеле, мәгърифәтче, милли сәясәтче Габдерәшит Ибраһимовның тормыш юлын өйрәнү, 2007 елда шушы төбәктән Төркиягә һиҗрәт кылган себер татарларының тарихын барлау, милләттәшләремнең бүгенге тормышларын белү өчен кирәк иде. 2008 елның августында хәтта «Умырзаая» ансамбле белән Иртыш буенда урнашкан татар авылларына тарихи-мәдәни экспедиция дә оештырдык. Боларның барысы хакында да мин зур-зур фәнни-популяр язмалардан башлап «Һиҗрәт» дип аталган тарихи романга хәтле язып чыктым.

Себернең Омск-Умба төбәге миңа язучы буларак та, тарихчы буларак та бик бай материал бирде. Әле анда өйрәнелмәгән, кул тимәгән мирас иксез-чиксез иде!

Омскида «Татар дөньясы»н чыгаручылар белән дә, анда язучы авторлар белән дә даими элемтәдә торам. Алар арасында Рәкыя Якубова һәм Фагыйлә Чумарованың аеруча актив, күтәргән темаларының актуаль булуына, тасвирлауларының халыкчан, телләренең камил әдәби тел икәнлегенә игътибар иттем. 2019 елда Рәкыя Якубова үзенең мәкаләләрен һәм шигырьләрен аерым китап итеп бастырып чыгарды, ул китапка кереш сүзне мин яздым. Быел исә Фагыйлә Чумарова туган ягы турындагы язмаларын аерым китап итеп әзерләде, аңа да кереш сүзне язарга мин алындым. Чөнки Фагыйләне газета хәбәрчесе буларак кына түгел, «Умырзая» ансамбленең җырчысы, милли эшләрдә актив катнашучы, ярдәмчел, яхшы кеше буларак та беләидем. Ул тотынган эш һәрвакыт яхшы тәмамлана, Фагыйлә Чумарова Омскида уздырылган күп кенә милли чараларның башында тора, өлкәдән читтә дә төрле фестивальләрдә, корылтайларда катнашырга вакыт таба. 2017 елның ноябрендә аның турыдан-туры ярдәме һәм катнашы белән, «Һиҗрәт» китабының презентациясен Омск, Тара шәһәрләрендә, шулай ук Үләнкүл авылында зурлап уздырган идек.

Мин шуңа игътибар иттем: Фагыйләнең язганнары укылышлы, теле җырлап тора, мәкалә геройлары гади, эчкерсез кешеләр, алар – аның авылдашлары, якташлары, шәһәрдәшләре... Ягъни, автор үзе нинди ихлас һәм гадел булса, каһарманнары да шундый. Якты кешеләр хакында яза ул, аларны караңгы Себер урманнарында, төпсез сазлыклар арасында эзләп таба һәм тарихка кертеп калдыра. Тарих дигәннән, Фагыйлә Чумарованың һәр язмасында диярлек авыллар тарихы, аерым кешеләрнең тетрәндергеч язмышы урын алган, шуннан милләт язмышы, милләт тарихы күз алдына килеп баса.

Әле узган гасырның алтмышынчы еллары уртасында Фагыйлә туган авылы Чарналыда башлангыч мәктәпне тәмамлый. Татарча! Ул вакытта Себер авылларының кайберләрендә татарча укыталар әле. Ә инде ул укуын дәвам иткән Үләнкүл авылы урта мәктәбендә укыту урысча була, татар теле, предмет буларак булса да, барыбер керә. Шунысын да әйтергә кирәк: Үләнкүл авылында саф татар мохите саклана, мәктәпләрендә элек тә, хәзер дә миллилек көчле. Фагыйлә гомере буе кулыннан китап төшерми, бала чакта да, хәзер дә ул аларны су урынына эчә. Ә бу китаплар Казаннан килә, саф әдәби татар телендә язылган, аларның һәр сүзе Себер кызы Фагыйләнең аңына, җанына сеңә бара! Һәм, вакыты җиткәч, үз язмалары булып, милләткә тарала...

Гаилә дигән сүзне дә әйттем. Әйе, Фагыйлә саф татар авылында, себер татарлары гаиләсендә тәрбияләнеп үсә. Әтисенең дә, әнисенең дә язмышлары шактый катлаулы. Әтисе – Рәҗәпов Алимулла Динмөхәммәт улы, әнисе – Миргалиева Ниса (Шәмсениса) Мөэмин кызы. Әтисе – Чарналыныкы, затлы бохаралылар нәселеннән, сугыш ветераны, тарихка кереп калган «Тәһран-43» вакыйгасында катнашкан кече лейтенант. Сугыштан кайткач та хөкүмәт куйган төрле эшләрдә эшли – дәүләт инспекциясендә дә, колхоз председателе булып та, бригадир да, ферма мөдире дә – барысын да булдыра. Үләнкүл авылында аерым совхоз оештырылгач, аны кадрлар бүлеге мөдире итеп куялар. Әмма сугыштан соң гел үпкә чире белән газапланган Алимулла әкә, пенсиягә чыгу белән, 1983 елда яман чирдән үлеп китә.

Әнисе Шәмсениса – Кумыслы авылыннан, Тубылда педагогия училищесын тәмамлый, Казанлы авылында укытучы булып эшли. Әмма кияүгә чыгып, Чарналыга кайткач, аңа кибеттә сату эшен тәкъдим итәләр, ул анда озак еллар хезмәт куя. *«Шәхсән минем күңелемдә казан татар теленә мәхәббәт уятучы әнием булгандыр, ул шулай ук Казан авылы кешеләренең сөйләмен бик ярата иде, тел байлыгына, мәкальләр кысты-*

рып, җор иттереп сөйли белүләренә соклана иде, шул арада үзенең аз сүзле булуына уфтана иде. Укытучы шундый буламыни? – дигән уйлар да башына килә иде», – дип искә ала газиз әнисен Фагыйлә Чумарова «Тормышлар бәйләнеше, язмышлар әйләнеше» дип аталган мәкаләсендә.

Шушы ук язмасында ул Столыпин чорында аның реформаларына бәйле рәвештә Себергә килеп урнашкан казан татарлары турында да шактый мәгълүмат бирә. Фагыйлә Чумарова туып-үскән Большеречье районында берничә казан татарлары авылы бар. Алар узган гасыр башында хәзерге Апас районының Күккүз авылыннан кубарылып чыгып китеп, бирегә килеп, Тузказан һәм Казан авылларына нигез салалар. *«Икенче төркем Криводаново авылыннан 4 чакрым ераклыкта төпләнергә булган. Патша хөкүмәте алар өчен алдан ук «барлык яшәү шартларын булдырып куйган икән – өч кое казытып куйганнар һәм: «Рәхәтләнеп яшәгез!» – дип, китеп тә барганнар. Татарларга җиң сызганып эшкә алынырга гына калган – карурман, сазлык арасында урман кисеп йортлар тергезә башлаганнар, җирләрне сөреп, ашлык чәчеп, урып, күлләрдән балык тотып, урманнардан киек-каз, җәнлек-җанвар тотып, күрше авыллардан малтуар сатып алып үрчетү эшләре белән мәш килеп, тормыш корып җибәргәннәр. Шулай итеп, Казан авылы барлыкка килгән...»*, – дип дәвам итә автор.

Әйткәнемчә, Фагыйлә Чумарова һәр мәкаләсендә диярлек авыллар тарихына, аның үткәненә һәм бүгенгесенә җентекләп туктала, аларның киләчәге өчен борчылып, укучы каршына сораулар куя. «Еланлы авылының бүгенгесе» дигән мәкаләсе дә бик нык уйланырлык. Бу – бик борынгы, себер татарлары авылы Яланкүл. 2007 елда мин үзем дә анда булып, тарихларын һәм бүгенге тормышларын өйрәнгән идем, бу турыда язып та чыктым. 1907 елда Төркиягә һиҗрәт тә шушы авылдан башлана, халыкның бер өлеше, алда көтеп торган фаҗигаләрдән качып, ислам иленә күчеп китә. Яланкүл авылы милләтебезгә «Идегәй» дастанын кире кайтарган авыл. Әле 1919 елда ук бирердә галим Нигъмәт Хәким булып, шушы дастанны язып алган, хәзер ул Казанда, Мирасханәдә саклана. Шулай ук бу авылда Хәмит Ярми, Мөхәммәт Садри да булган, алар да бик күп дастаннар һәм озын җырлар язып алганнар. Яланкүл авылы милләтебезгә тарих фәннәре докторы Фоат Вәлиев һәм аның хатыны, тарих фәннәре кандидаты Суфия Исхакованы биргән, алардан башка да биредән күп галимнәр чыккан.

«

Яланкүл авылы милләтебезгә «Идегәй» дастанын кире кайтарган авыл. Әле 1919 елда ук биредә галим Нигъмәт Хәким булып, шушы дастанны язып алган, хәзер ул Казанда, Мирасханәдә саклана. Шулай ук бу авылда Хәмит Ярми, Мөхәммәт Садри да булган, алар да бик күп дастаннар һәм озын җырлар язып алганнар. Яланкүл авылы милләтебезгә тарих фәннәре докторы Фоат Вәлиев һәм аның хатыны, тарих фәннәре кандидаты Суфия Исхакованы биргән, алардан башка да биредән күп галимнәр чыккан.

«Большеречье районы карамагында булган күп санлы татар авылларының берсе – Яланкүл, үзебезчә әйткәндә, Еланлы авылы. Тарихи чыганаклар буенча, ул 1427 елда барлыкка килгән, соңыннан Аубаткан авылы белән кушылган. Яланкүл авылында (Аубат-

кан белән бергә), 1897 елгы беренче халык санын исәпкә алу мәгълүматлары буенча, 429 кеше яшәгән. Соңгы елларда авыл бик картаеп киткән сыман күренә. Хуҗалары калдырып киткән буш калган ярым-җимерек йортлар, җирләреннән кубарып үк алып киткән нигезләр, чалшаеп-муртаеп калган читән-коймалар, кычыткан-тигәнәкләр басып киткән тыкрыклар – болар барысы да күңелгә моңсулык өсти, авылны ятим итеп күрсәтә. Чынбарлыгы шул: Еланлыдан ел саен бер-ике гаилә, авылны калдырып, шәһәргә күченә тора. Авылда көчләре ташып торган эшмәкәр ирләрне, гаилә тормышыннан тәм табып яшәгән яшь хатыннарны, яшьлеге белән масайган егетләрне, алма кебек тулып пешкән сылу кызларны очратырмын димә – гел олы яшьтәге апалар, абзыйлар, кунакка кайткан бала-чагалар гына очрап тора», – дип яза автор да, бу хәлләргә уфтанып.

Әлбәттә, ул моңсуланып, уфтанып кына йөрми, авылда калган өлкән агайлар һәм апалар белән бу турыда ачыктан-ачык сөйләшә дә. Авыл ни сәбәпле бетә? Адәм баласы нигә аягүрә чери? Үз-үзенең һәм якыннарының гомерен ни сәбәпле кыя? Фагыйлә Чумарова да, аның белән әңгәмә корган авыл халкы да моның төп сәбәбен динсезлектән күрәләр.

Фагыйлә Чумарова үзенең «Яшьлек сукмагы буйлап» дип аталган мәкаләсендә язма герое артыннан тагы Еланлы авылына әйләнеп кайта. Сәгыйть Хәбиров 1952 елда бу авыл мәктәбенә Татарстаннан рус теле укытырга җибәрелә, аннан мәктәп директоры була, Еланлы кызы Оркыяга өйләнеп, гаилә кора. Әмма туган якларында калган ялгыз анасын карау өчен, гаиләсен алып, Норлат авылына кайтып урнаша, мәгариф өлкәсендә эшләвен дәвам итә. 55 ел бергә гомер иткән хатыны үлгәч, ул яңадан аның туган якларына – Еланлыга кайта, авыл халкы белән бәхилләшеп китә. Мәкалә герое Еланлы авылын бик яратып искә ала: *«Шулай, бу якларга тәүге тапкыр аяк баскач, кешеләр белән танышырга, дип, йорттан-йортка йөри идем. Бер йортта, бүрәнә стенада, берничә мылтык белән рәттән, скрипка уен коралы эленеп торуын күрү гаҗәеп тәэсир калдырган иде... Баксаң, авылның мәргән сунарчысы Шәрип ага Ибраһимов шундый ук осталык белән скрипкада уйный белә булып чыкты. Кергән һәр йорттан чәй эчермичә чыгармыйлар иде. Минем туган якларда – Татарстанның Шөгер авылында – ит бәлеше пешерсәләр, аның күп өлеше бәрәңгедән хасил була, «эләктерә» алганнарга берничә кисәк ит эләгә иде. Бу якларда ит бәлеше – чынлыгы белән ит бәлеше: ат, сыер, сарык, кош-корт итләрен бергә кушып, тозлап-борычлап, каз маена су кушып изелгән камырга бөреп куялар да, зур мичләрдә пешереп алалар... Камыр эчендә, кайнарлыгы озакка җитәрлек иттереп ягылган мичтә, үзе бүлеп чыгарган ит шулпасында пешкән, бу якларда гына очратып була торган шул үзенчәлекле бәлешнең тәмен беркайчан онытасым юк! Әле һаман шулай икән: олылап кунакка дәшәләр, өстәл өсте төрле ризык белән тулы булуга карамастан, ит ашлары беренче урынга куела. Рәхмәт яусын Еланлы авылы халкына кунакчыллыклары, киң күңелле, гади булып кала белүләре өчен!»*

Менә бит нинди күңелле туган халкың турында шундый матур сүзләр ишетү! Милләтем шулай киң күңелле, кунакчыл, тәртипле булган, инде алга таба да шушы асыл сыйфатларына әйләнеп кайтсын иде! Моның өчен нишләргә соң? Фагыйлә Чумарова ул сорауны Татарстаннан килгән чал чәчле кунакка – Сәгыйть Хәбировка да бирә. *«Һәркемгә билгеле: динне кайтармыйча булмый. Халыкка Аллаһы сүзе кирәк. Динле кеше аракы-хәмерне үз итеп эчеп-исереп йөрмәс иде. Мисал өчен шуны әйтәсем килә: дингә каршы булган шаукымлы елларда күпме мәчетләр юкка чыгарылды, җимерелде. Яндырылды. Ә менә мин яшәгән Норлат авылы халкы мәчетләрен яклап кала алган! Норлат хәзер бик зур булып үсте, мәчетләр дә берничә... Ә менә шул борынгы мәчет,*

халык өчен иң кадерле мирас булып, бүген дә аның тарафыннан күз карасы кебек сакланып карала. Коръәндә: «Кыр тавыгы оясы хәтле генә мәчет салсагыз да, Мин сезгә оҗмахта хан сарае бүләк итәрмен», – диелгән. Авылларга мәчет кирәк! Мәчеттә генә Аллаһы сүзен тыңларга мөмкинлек бар!» – дип җавап бирә кунак.

Автор үзе дә халыкның бу хәлгә төшүенә, дин белән бергә телнең дә юкка чыгуына бик борчыла, һәр мәкаләсендә диярлек шушы теманы күтәрә: *«Заманалар башкамы, кешеләр үзгәрәме икән? Кайчандыр ислам динен халыкка җиткерер өчен кешеләр үз язмышларын куркыныч астына куйганнар. Бөтенләй чит-ят җирләргә китеп, кешеләргә Аллаһы сүзен ишеттерергә омтылганнар. «Уңайсыз-җайсыз, шартлар юк», – дигән уй күңелләренә кереп тә карамагандыр. Ә нәрсә булган соң үзебезнең өлкә мәхәлләсеннән белемле кешеләр килеп, өр-яңадан ислам динен авыл халкына ирештерергә тырышсалар? Юк шул, юк, андый батырчылыкка хәтта ислам дине өчен дә үзен корбан итәрлек дин әһелләре бүтән тумагандыр бу Җиргә! Ул гына да түгел, дин белән рәттән, татарлар үз ана телләреннән ваз кичәргә дә әзер кебекләр. Мәктәпләрдә татар телен укыту кыскартылганнан-кыскартыла бара. Ул беркөнне бөтенләй юкка чыкса да, халыкның моңа бик исе китмәс кебек тоела. Хәзерге көндә Татарстаннан Себергә укытучы булып эшләргә килергә теләк белдерүче кеше табылыр идеме, дисәң, аның кирәге дә юк: үз яшьләребезнең Казанга барып укып кайтырга мөмкинлекләре бар, тик анда киткәч, кире Казаннан кайтырга теләүчеләре генә юк».*

Әйе, барысы да хак. Һәм Фагыйлә Чумарова үзенең моңлы-сагышлы, әрнүлеярсулы мәкаләләре белән халык алдына шушы сорауларны куя. Карурманнар уртасында, төпсез сазлыклар чолганышында милләт, себер татары буларак, ничек исән калырга?! Кайлардан көч-кодрәт алырга, кемнәрдән ярдәм сорарга, кемнәргә сыенырга? Аның үзенең моңа җавабы әзер: бары тик Аллаһтан гына ярдәм сорарга һәм Аңа сыенырга, бары тик үз милләтеңә генә таянырга, бергә булып, укмашып исән калырга!

Фагыйлә Чумарованың «Чарналы авылына мәчет кирәкме?» дигән мәкаләсе дә бик уйланырлык. *«Шул арада олылар сүзенә кысылмыйча гына кул арасына кереп булышып йөрүче яшүсмер бер малай түзмичә әйтеп куйды (бу сорау аны кызыксындырадыр дип уйламаган да идем):*

– Мәчете булса, йөрүчесе табылыр! Менә миңа кирәк мәчет, мин йөрермен! Мин үзем генә түгел, минем иптәшләрем дә йөрерләр! – дип сүз катты...

Әйе, шундый икән хәлләр... Нишләптер, дин, мәчет турында сүз чыкса, без олы яшьтәге кешеләрне генә истә тотабыз, яшь буынны искәрми калабыз... Менә безнең тагын бер зур ялгышыбыз...

– Кем малае соң син, балакаем? – дип, мин зур кызыксыну белән бу чая үсмергә таба борылдым.

– Минем кече улым ул, Фагыйлә апа, – диде Кашфия исемле яшь хатын.

– Син нәрсәдән чыгып шундый фикердәсең, балам? – дип, тагын аңарга борылдым.

– Мәчете булмаган авылда динне белмиләр. Динне белмәгән авылда бәрәкәт булмый, – диде малаем, мине шаккаттырып. – Авылда калган яшьләр бары тик эчүчелек белән генә гомер уздыралар. Аларның бүгенгесе дә юк, иртәгесе дә юк. Мал табарга дип читкә китеп эшләп кайталар да, үз көчләре белән тапкан акчаларын эчеп бетерәләр. Алардан чыга барлык тәртипсезлек, алар олыны – олы дип, кечене – кече дип тә белмиләр. Берничә елдан соң мин һәм иптәшләрем үсеп җитәчәкбез – без дә алар рәтен тутырырга тиеш булачакбызмы?»

Моны бала кеше әйтә бит! Әле әтисе дә молдован милләтеннән икән, Владислав исемле бу баланың күңелендә иман орлыклары бар! Һәм мәчет аңа кирәк! Татарларның күпчелегенә кирәкмәгән мәчет шушы балага кирәк… Нинди зур гыйбрәт

Мәкаләнең авторы Фәүзия Бәйрәмова һәм Фагыйлә Чумарова (алда) Тарадагы татар зыялылары белән

бу безнең өчен! Һәм Фагыйлә шушыны күреп алып, моны йөрәк җылысы һәм әрнүе белән халыкка җиткерә алган! Барысын да күңел күзе белән күргән...

Фагыйлә Чумарованың барлык геройлары да диярлек якты, максатчан кешеләр, күбесе – хатын-кызлар. Ул алар хакында бик белеп һәм яратып яза. «...*Минем геройларымның күбесе – хатын-кызлар. Мин шуңа бик шатланам. Алар турында күпме язган саен, аларның тормышны сөеп-яратып яшәүләренә, ихтыяр көчләренә сокланам. Тормыш авырлыклары алдында баш ия белмәгәнлекләренә гаҗәпләнәм. 103 яшәр ак яулыклы Әшрәф әбием, кечкенә буйлы мут Мөнәвәрә апаем, чит илләрне яулый алган Факия дустым һәм дә башка бик күпләр... Сез зур җисемне – хатын-кыз җисемен йөртәсез. Сез барыгыз да төрле-төрлесез, шул кабатланмас төрлелегегез белән тагын да күркәм һәм матурларсыз! Сез – тормышның алып баручыларысыз, дөньяның терәгесез! Сезне яратып, сезгә сокланып, сезнең алдыгызда олы ихтирамымны белдереп, баш иям! Кайсыгыз гына булмасын, бәхетле була күрегез!*» – дип яза ул.

***

Фагыйләнең Омскида «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе икәнлеген дә, «Умырзая» ансамбленә йөрүен, борынгы себер татарлары җырларын бик яратып башкаруын да әйтергә кирәк. Аңа үз вакытында зур укулар, институтлар эләкмәгән, ул төзелештә авыр эштә эшләгән, ә күңеле белән гел җырлаган да язган, җырлаган да язган... Тормыш иптәше Раил белән ике ул тәрбияләп үстергәннәр, хәзер өч оныклары бар, алар барысы да Фагыйлә нәнәләре куенында. Ире һәм уллары белән шәһәр читендә бик матур өй салып чыкканнар, Фагыйлә аны зәвык белән бизәгән, куышыннан хан сарае ясаган. Мин Фагыйләнең өс-башына, үз-үзен тотышына да игътибар иттем – аларда нечкә зәвык һәм затлылык сизелә, мәдәниятлек күренә. Себер сүзе, Себердә татар сүзе бүген син һәм синең кебек фидакарь затлар кулында, Фагыйлә сеңлем, шул җаваплылыкны беркайчан да онытмагыз! Татар хатын-кызы Фатыймаи-Фәридә узган гасыр башында үзенең газетасы белән бөтен Себер Илен, Татар дөньясын яктырткан булса, бүген Омскида сез чыгарган «Татар дөньясы» тирә-юньгә нур сибә, мәгърифәт тарата. ■

Валлаһи

Габдулла Тукай

Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,
Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!

Ак күмәч берлән ашарлык саф һава;
Җир яшел; кошлар да сайрый, валлаһи!

Ак болыт, күчмә казакълардай күчеп,
Бер кунышлык күкне сайлый, валлаһи!

Аз гына бер җил исү берлән, үлән
Җирдә уйный кайный-кайный, валлаһи!

Бу шигырь Г.Тукайның Троицк сахрасында кымызда ял итүе уңае белән язылган. Ахырга: «Иштә бу — сахрада беренче көнемдә язылып ташланган бер кәгазьдән алынган җырулар!» — дип искәрмә дә бирелгән. ■

Троицк. Базар мәйданы

Тукай Троицкига кайтты

9 июльдә Троицк шәһәрендә бөек татар шагыйре Габдулла Тукай бюсты ачылды. Әлеге чарада Чиләбе өлкәсе губернаторы **Алексей Текслер,** Россия югары мөфтие, шәех-әл-ислам **Тәлгать хәзрәт Таҗетдин**, Чиләбе өлкәсе татарлары конгрессы Башкарма комитеты рәисе **Лена Колесникова,** Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары **Илгиз Халиков,** «Мәдәни җомга» газетасының баш редакторы **Вахит Имамов,** «Безнең мирас» журналының җаваплы мөхәррире **Ленар Гобәйдуллин** һ.б. катнашты.

***Ленар Гобәйдуллин** фотолары* ■

Нурихан ага ватанында

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире **Рөстәм Галиуллин,** «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире **Вахит Имамов,** «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире **Ләбиб Лерон** һәм җаваплы мөхәррире **Ленар Гобәйдуллин** Башкортстан Республикасының Яңавыл районындагы Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты, Татарстан халык язучысы Нурихан Фәттах (1928-2004) белем алган Яңа Уртавылда һәм әдип дөньяга килгән Күчтавылда булды.

Нурихан Фәттах яшәгән һәм белем алган Яңа Уртавыл күренеше

Фронтовик шагыйрь Гайнан Әмири исемен йөрткән Яңа Уртавыл мәктәбе каршында

Мәктәптәге Гайнан Әмири музееның бер күренеше

Мәктәп ишегалдында башкорт милли хәрәкәтендә катнашкан Хәлим Әмиров бюсты тора

Нурихан Фәттахның әнисе Салиха апа кабере янында

Яңа Уртавылда Нурихан аганың әнисе Салиха һәм аның сеңлесе Нәгыймәгә салып биргән йорты. Авыл читендә, нарат-чыршы урманы эчендә урнашкан йорт хәзерге вакытта ташландык хәлдә

Нурихан Фәттахның Кучтавылда яшәүче туганы белән очрашу

Кучтавылда Нурихан Фәттах туган нигез

Нурихан Фәттахның туганнарына бүләк иткән автографлы китабы

Әдип хаты:

«Тимергали абзый!

Күп итеп сәлам сезләргә безләрдән, Казандагы туганнарыгыздан. Сәлам Чибәрттәйгә, Шәрифәгә, яшь килен белән энекәшкә, бәләкәй энекәшкә. Былтыр, моннан бер ел элек, сез ничектер Казанга килергә җыенганыегыз. Ләкин яшь килен (сеңлекәш) сиңа операция булды дип язды да, әллә синең хәлең начар булып, әллә башка сәбәптән, килми калдыгыз. Без сезне көттек, килмәгәч аптырадык, билгеле. Синең хәлең ничегрәк соң? Кузгалмадымы яраң, төзәлдеме? Авылга кайткач, сезнең турыда берни ишетелми. Инәкәй әле авылда. Каникул вакытында улымны алырга җибәрермен дип торам. Җаегыз булса, сез дә килегез. Кышкы каникулда дип әйтмим – үз вакытыгыз белән. Кыш көнеме, язга табамы, хәзер үкме – үзегез карарсыз. Хәлегез ничек – бер-ике сүз белән генә булса да хат языгыз. Чибәрттәй тазамы, өйдәгеләр тазамы?

Миннән, Руфиядән, Алмас белән Чулпаннан янә күп сәлам.

Нурихан дип белерсез.

13 декабрь 1975 ел, Казан».

Ред.: Хатның икенче ягында (фотода) Н.Фәттах үзе яшәгән йортка килү өчен схема сызган. ■

Безнең мирас №8 август 2021

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Шанхай-Куан. XX гасыр башы

Шанхай-Куан янындагы монастырь

Кич җиткәч, без Давуд әфәнденең өенә кайттык. Биредә бай табын, төрледән-төрле ризыклар әзерләнгән, мәхәлләнең дәрәҗәле кешеләреннән берничә кунак та бар иде. Һиндстаннан килгән мөселман кардәшебезне дә чакырганнар иде, безнең белән ул да килде.

Биредә Һиндстан кешеләре шактый булып, боларның күбесе гаскәрилек һәм полиция хезмәтләренә эшкә керә икән. Аз гына санда булса да, сәүдәгәрләре дә бар. Барысы да диярлек кытайча белә. Бик кызганыч, ләкин араларында инглизләргә җасуслык, ягъни шпионлык хезмәте башкаручылар да очрый икән. Шул ук җасуслар дини хезмәт күрсәтүдән дә баш тартмыйлар: кайберләре авыл-

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

ларда укытучы булып тора, кайберләре Һиндстан китапларын бастырып чыгара, Кытай мөселманнарын азмы-күпме хәбәрдар итәләр икән.

Мин иртәгесе көнне Шанхай-Куаннан китәргә карар кылган идем, тик Давуд әфәнде мине җибәрмәде, тагын бер көн калырга күндерде. Минем һич кенә дә вакытны бушка үткәрәсем килми иде. Бүген дә имам әфәнде белән, атларга атланып, якын-тирә авылларны карап йөрергә дип чыктык.

Авыллар

Шанхай-Куанның әйләнә-тирәсендә мөселманнар яши торган авыллар бик күп. Кайбер авылларда мәҗүсиләр дә, мөселманнар да бар, ә кайберләрендә исә, күбесе мәҗүси булып, араларында берничә генә йорт мөселман кешеләре яши икән.

Билгеле булганча, кытайларның тышкы күренешләреннән кайсының мәҗүси, кайсының мөселман яки христиан икәнен аерып булмый, бар да бер кыяфәттә. Йортлар да барысы да бертөрле, мәҗүсилек заманында ничек булса, шулай. Игътибар белән карагач кына күренә: мөселманнар яши торган өйләрнең ишек өсләрендә гарәп язуы белән кәлимә-и тәүхид: *«Лә иляһе илләАллаһ»*, ягъни «Аллаһтан башка илаһ юк»; *«Йа мүфәттихә-л-әбваб»,* ягъни: «Әй ишекләрне ачучы», – дип язылган була. Авылларда да шундый ук хәл. Шулай да, балаларда бераз аерма бар һәм бу игътибарны бик нык җәлеп итә.

Мөселман бала-чагалары, читтән килгән мөселман кешесен күрүгә, күңелләренә хуш килгәнен күрсәтеп: *«Муслимани ләйля*[1]*, муслимани ләйля», ягъни «Хуш килдең, мөселман, хуш килдең, мөселман»,* – дип кычкыра-кычкыра ияреп баралар. Бу юлы, без авылга кергәндә, кечкенә генә мәйданчыкта сигез-ун бала уен уйный иде. Безне күреп алгач, араларыннан берсе, аерылып чыгып: *«Муслимани ләйля»*, – дип кычкырып, артыбыздан ияреп бара башлады. Мин имам әфәндедән:

– Башкалары ник килми? Әллә бу бала Сезне таныймы? – дип сорадым.

– Бу – мөселман баласы, калганнары – мәҗүси, кяфер, – дип җавап бирде имам.

– Бу бала безнең мөселман икәнебезне ничек белде? – дип соравыма, имам мыекларын күрсәтте дә:

– *Муслимани шәрибуһу касыйр,* – диде, ягъни «Мөселманның мыегы кыска була», дип әйтте.

Чынлап та, кытай мөселманнарында мыекны кыска итеп кисү диннең кушуы һәм исламның бер билгесе итеп кабул ителә.

Балаларның мөселман кешесен күреп сөенүләре, әлбәттә, рухи канәгатьлек хисе бирә. Мин бу хәлне Кытай иленең бөтен җирендә диярлек күрдем. Кая гына барсам да, мыегыма карыйлар иде.

Ләкин үз араларында бу бик сирәк хәл, чөнки кытайларда мыеклы ирләргә караганда мыексызлары күбрәк. Сакал исә бик сирәк очрый. Бездәге кебек сакал хәтта бөтенләй юк. Минем сакалымны күреп хәйран калалар, кайчак йөзләп кеше бергә җыелып карап тора: «*Муслимани ләйля»*, – дип кычкыра торганнар иде.

Кытай авыллары үтә гади алачык сыман өйләрдән гыйбарәт булса да, төзелеш рәвешләрендә тәртип бар. Урамнар, тыкрыклар шактый тигез. Бу яктан үзенә күрә бер мәдәният чагылышы булып күренә. Бик күп авыл күрдем: урамнарында тәртип, төзеклек бар иде.

---

[1] Ләйля – хуш килдең дигәнне аңлата *(Габдерәшит Ибраһимов иск.)*.

Ланго дип аталган бер авылда, иртәнге ашыбызны ашарга дип, бер ашханәгә килдек. Ишегенә комган һәм тәсбих рәсемнәре төшерелгән иде. Имам әфәнде: *«Аләмәт-и мүслимани кяфир ля»,* – диде. Болар бу ашханәнең кяфернеке түгел, мөселманныкы икәнен белдерә, дип әйтергә теләде, әлбәттә. Кытайда күбесенчә шундый билгеләр кулланыла икән.

Кытайларда бик күп ит, камыр ашлары була, балык һәм үсемлек тамырларын да азык итеп кулланалар. Бигрәк тә камыш тамыры киң кулланыла. Ашамлыклары шактый туклыклы, японнарныкы белән чагыштырганда, хәтта бик туклыклы. Аннары биредә йөргәндә тагын бер нәрсәгә игътибар иттем: бөтен җирдә, тауларда, кыялар өстендә, калкулыкларда, авыл капкаларында ак бөҗра бар. Беркөнне тауларда йөргәндә, монастырь янында да күргән, тик ул вакыт артык игътибар итмәгән идем, бу юлы кызыксындым:

– Бу бөҗралар нәрсә өчен? – дип сорагач, имам әфәнде:

– Зи'бун кәсир йәкулү ганәмән раҗулән йәкулү. Даиратун әнә йәдхулү ләйәкуль, – диде, ягъни «Бүре күп, сарыкларны ашый, кешене дә ашый. Мин бөҗра эченә керсәм, бүре тими, ашамый», дип әйтергә тели иде.

Шул рәвешле, якын-тирәдәге авылларны карап йөрдек. Кытайларның авыл тормышында игътибарны җәлеп итәрлек башка берни дә күрмәдем. Бары тик әфьюн кулланучыларның күплеге генә игътибардан читтә калмады.

Кичкә кырын кабат Шанхай-Куанга, Давуд әфәнденең өенә кайттык. Давуд әфәнде биредә шактый танылган кеше икән. Алда да әйткәнемчә, Петербургка килгән вакытында безнең өебездә кунак булган иде. Шул вакыттан бирле мине хәтерендә саклаган икән.

Сәер хәл яки җаһиллек

Кытай тимер юл станцияләрендә игътибарны җәлеп итә торган бер нәрсә бар, шул хакта да сөйләп китәргә телим.

Станциягә поезд якынлашкан вакытта кытай гаскәриләре аны каршы ала. 12 солдат станциянең бер башында һәм тагын 12 солдат икенче башында тора. Араларында бер офицер да була, кулларына корал тоткан килеш сәламлиләр. Болай поездны сәламләү гадәте бер җирдә дә юк, бары тик Төркия белән Кытайда гына бар. Сәбәбе нәрсәдә – моны һич белмим. Башыма шундый бер фикер килгәне булды: Аурупа кешеләренең бик үк тәрбияле булмаган берсе, безнең ахмаклыгыбызны сынап карау өчен, бер нәрсә уйлаган һәм аны берәр станция мөдиренә әйткән булса кирәк. Безнең ул заманнардагы ахмак офицерлар бу күрсәтмәне кабул иткәннәр дә, соңыннан бу гадәткә әйләнеп киткән, мөгаен. Аннан соңгылар исә: «Бу элек-электән килгән гадәт!» – дигәннәрдер. Тора-бара бу кагыйдә хәленә килгән, вәссәлам.

Мин моны, Аурупа юлы белән Истанбулга килгән вакытта, Җиср-и Мустафапашада[2] күреп, бик ачуым килгән иде. Ул безнең бичара җандарм гаскәриләре, бер аягында – итек, икенчесендә – ботинка калдыгы яки башмак, төймә дип әйтерлек берни юк. Аурупадан килүче юлчыларга: «Менә бу без инде!», – дигән кебек, мәсхәрә хәлдә, кайберләре чуксыз фәс киеп, кайберләре, иртән иртүк булса, эчке күлмәк-ыштан гына киеп чыгып басалар да поездны сәламлиләр. Аурупага таш-

[2] Җиср-и Мустафапаша – Госманлы дәүләте чорында Әдирнә шәһәренең төньяк-көнбатышында, аннан 30 км ераклыкта урнашкан, бүгенге көндә исә Болгария җирләрендә калган һәм Свиленград дип атала торган шәһәрчекнең иске исеме *(тәрҗ.иск.)*.

кын булып барып-кайтып йөри торган пашаларыбыздан, офицерларыбыздан ник бер кеше булсын?! «Ходаем, бу ни хәл? Кемне сәламлисез? Аурупада нәрсә бар?» – дисеннәр иде. Ул заманның бичара, мескен гаскәриләре һәр станциядә шулай басып торалар, мылтыклары күгәргән, гомерендә бер тапкыр да сөртелмәгән була иде. Без, читтән килгән мөселманнар, бик ояла идек.

Шуның кебек үк, бу гадәт Кытайда да инглизләр күрсәтмәсе буенча башкарыла иде булса кирәк. Мукденнан Шанхай-Куанга кадәрге юлда ул поезд сәламләү күренеше гел күземә ташланды, күргән саен Төркияне искә төшерде.

Тензин (Тяньцзинь)

Мин Шанхай-Куаннан соң Тензин (Тяньцзинь) шәһәренә юл тоттым. Бу бик зур һәм төзек шәһәр иде. Биредә яшәүчеләрнең күбесе – Аурупа кешеләре. Йортлар, биналар да күп кенә яктан Аурупа ысулы белән төзелгән. Зур, күп катлы биналар Аурупа мәхәлләләрен хәтерләтә. Арулыкка, матурлыкка да игътибар бирелгәне беренче караштан ук аңлашыла. Бу төбәкнең идарә ителүендә ниндидер чит йогынты сизелә.

Биредә мөселманнар да бик күп. Мин Нандизи мәхәлләсендә мәчеткә кердем, күрдем. Мәдрәсәләрнең төзелеш рәвеше бөтенләй башка, бик төзек, тәртипле. Бу биналарны күреп, күңелдә өмет уяна. Тензиндагы мәчетләр шулкадәр матур, Кытайның башка бер җирендә дә андыйларны очрата алмассың. Боларны төзү өчен йөз мең акчалар сарыф ителгәндер дип уйлыйм. Мөхәндис (инженер) яки рәссам булсам, тагын да тәфсилләп сурәтләр идем. Аларның фотосурәтләрен төшертеп алган идем, ләкин алар гел Русия почта юлларында югала барды. Бу мәчетләрнең фоторәсемнәре генә түгел, гомумән, бик күп нәрсәләрем почталарда югалып әрәм булды.

Тензин мөселманнары арасында гаять бай кешеләр бар. Зур капиталларга ия мөселманнар да бар икән. Бик зур фабрикалар да бар. Ләкин мин аларны хуплап, мактап, болар белән артык киң итеп таныштыра алмыйм, чөнки бик яхшылап күрә һәм аңлый алмадым.

Әмма мәчетләрдәге тәртип, төзеклек һәм матурлык, һич шөбһәсез, биредә яшәүче мөселманнарның тырышлыгы белән барлыкка килгән. Мәдрәсәләр дә бик төзек, тәртиптә тотыла, ләкин дәресләргә килгәндә, *иннә лиллаһ вә иннә иләйһи раажи'ун,* нәрсә дип әйтим, аһ, йа Рабби, син үзең беләсең. Тагын шуны әйтим, биредә бер имам бар: әйтергә теләгән фикерен аңлата алырлык дәрәҗәдә гарәпчә дә белә. Шактый гыйлемле бу мөхтәрәм зат белән якыннан таныштым һәм бик зур ярдәмен күрдем.

Тензинда 12 мең мөселман кешесе яши икән. 9 кечкенә, 3 зур мәчет бар. Боларның барысының да яннарына мәдрәсәләр урнашкан.

Монда килгәч, башта имам әфәнде белән минем арада бәхәс барды. Имам җәнаплары, бик зур ачу белән, миңа: «Тәмам туйдык без бу мөселманнарның теләнчелегеннән. Сезнең мәмләкәттә теләнчелекнең хәрам икәнен беләләрмеюкмы?» – диде, тагын әллә ниләр сөйләнде. Мин бик тыныч кына тыңлап тордым. Бераздан имам Мәдинә-и Мөнәүвәрәдә яшәгән Сәйид Хамза исемле бер кешенең зур кимчелекле эшләре турында сөйләде дә берара тынып торды. Шул арада мин имам җәнапларына болай дидем:

– Сүзләрегез бик дөрес, мин дә фикерләрегезгә кушылам, ләкин Сез бераз ашыктыгыз дип уйлыйм. Башта минем белән сөйләшеп, кем икәнемне, ни эшләп

йөрүемне аңларга кирәкми идеме икән? Болай тота-каба ташлануыгыз урынлымы? Минем ачу-үпкәм юк, аңлыйм, кешенең нинди халәте булмас. Сез миңа сөйләргә рөхсәт итеп сүземне тыңласагыз, мин бик канәгать калыр идем. Мин Сездән бары тик бер сәгать вакытыгызны аерып, мине тыңлавыгызны үтенәм, башка бернәрсә дә теләнергә җыенмыйм, бары тик бер сәгать вакытыгызны алачакмын. Аннан соң бер кәлимә сүз дә сөйләмәм, тыңлап кына торырмын.

– Рәхим итегез, тыңлыйм.

– Мин Мәккә кешесе түгел, Мәдинә кешесе түгел, барыннан да бигрәк, теләнче дә түгел. Моннан соң да ышандырып әйтә алам, Сезгә сөйлисе сүзләрем дә бары тик ислам кардәшлеге һәм дин гайрәте таләбе буенча гына сөйләнәчәк, үгет-нәсыйхәт түгел. Бу бары тик бер танышу гына, башка максатым юк икәнен катгый ышандырып әйтә алам. Сез акча бирергә уйласагыз да, мин алмам.

– Алай булса, Сез минем бу хата-кимчелегемне гафу итегез. Соңгы вакытларда берничә кеше килде, канымны боздылар, шуңа мин Сезне күрүгә, гафләткә бирелеп гасабыйландым, үтенеп сорыйм, гафу итегез! Инде мин тыңлыйм, Сез сөйләгез.

– Мин – Русиядән килгән мөселман кешесе. Бирегә Сезнең кебек мөселман кардәшләрем белән танышырга дип килдем. Мин әле Кытай илендә бик гизмәдем, дүрт-биш шәһәр, егерме-утыз авыл гына күрә алдым. Күргәннәрем нәрсә, беләсезме: канлы яшьләр түгәрлек хәлләр! Сезгә һәммәсен сөйләп бирергә телим. Теләсәгез, кабул итәрсез, теләмәсәгез – юк. Тик кабат әйтәм: борчылмагыз, төп максатым дини вазыйфамны үтәүдән генә гыйбарәт, башка берни дә түгел. Шушы көнгә кадәр Кытай илен күргән голәмә арасында Сезнең кадәр сәләтле, Сезнең кадәр сүз аңлаган кеше күрмәдем. Тик ни кызганыч, Сезнең дә Коръән укуыгыз Аллаһка ялваруны тиешле дәрәҗәдә үтәү өчен җитәрлек түгел. Сез Ибраһим Халәбинең «зәлләтүл-карый»[3] мәсьәләсен тагын бер тапкыр бик игътибар белән укып өйрәнегез әле. Намазыгызның тиешле дәрәҗәдә түгеллегенә үзегез үк фәтва[4] бирерсез. Бигрәк тә Мукден, Цицикар, Шанхай-Куан имамнарының Коръән укулары бернинди кагыйдәгә дә сыймый. Мәҗүсиләрнең гыйбадәтханәләрендәге көйләп сөйләү рәвешен алгансыз. Нәүзубиллаһ[5], мондый Коръән уку буламы?! Иһдинан сырат, дип укыйсыз. Гомумән, «Фатиха» сүрәсен башыннан ахырына кадәр хаталы укыйсыз. Мин менә Сездән нәкъ шушыларны төзәтүегезне, яхшыртуыгызны үтенәм.

– Йа Аллаһым! Мин бик зур хата ясадым, зинһар, кичерә күрегез, мин Сезнең күңелегезне рәнҗеттем.

– Зарар юк. Минем моннан соң әйтәсе сүзләремне кабул итсәгез, мин бик шат булырмын. Болары үтәр, аңа борчылмагыз. Бүгенге көндә Кытайда җитмеш-сиксән миллион мөселман кешесе яши, бөтен җирдә дә хәл сездәгедәй булса, менә аңа борчылырга кирәк. «Әлхәмдүлилләһ, мөселманмын», – дисез үзегез, тик мөселман динендә элек-электән кардәш белән кардәш күрешкән вакытта сөннәт саналган сәламләшү бар. Сез ул сәламләү сүзен дә дөрес әйтмисез. «Ансалям алейкум», – дисез, гаеп түгелме бу? Бөтен гадәтләрегез – мәҗүси гадәтләре, бу тырнакларыгыз нәрсә инде, йә? Бу чәчләрегез? Болар турында ник уйланмыйсыз? Аллаһ каршысында бу хәлләрдән сез – голәмә – җаваплы тотыласыз. Моннан тыш, сәяси җәһәтегезгә килсәк, сезнең бу мәмләкәттә бернинди хокукыгыз

[3] Коръән укудагы хата-кимчелекләр *(тәрҗ.иск.)*.
[4] Фәтва – шәригать сагында торучы кешенең берәр хәл, вакыйга турында биргән хәбәре, чыгарган карары *(тәрҗ. иск.)*.
[5] Аллаһ сакласын! *(тәрҗ. иск.)*.

юк. Кытай хөкүмәте сезне түбәнсеткән, кешелек хокукларыгызны аяк астына салып таптаган – сезнең хәбәрегез дә юк. Кеше саныгыз сиксән миллионга якын булса да, хөкүмәт идарәсендә бер генә кешегез дә юк. Бүген Япониядә ун мең кытай студенты арасында 30-40 мөселман кешесе бар. Сезнең боларны игътибарда тотканыгыз булдымы? Моннан соң кытайлар да түгел, сезнең белән чит ил кешеләре идарә итәчәк, ул вакыт хәлегез нәрсә булыр икән? Болар турында ник уйламыйсыз? Менә минем биредә килүемнең максаты – шушы. Менә шул хәлләр турында сөйләшеп, фикер алышырга теләсәгез, әзер булсагыз, мин Сезне ислам кардәшлеге күзлегеннән күрергә һәм Сезнең белән кардәш буларак күрешергә телим. Гарәп телен дә шактый яхшы беләсез. Әгәр инде: «Юк, теләмим», – дисәгез, мин Сезне моннан ары борчымам, мәдрәсәгездә бер кич кунармын да юлымны дәвам итәрмен.

– Бик яхшы, бик яхшы! Сезнең белән күрешүемә бик шатмын. Сез – олы кунагыбыз, мәдрәсәбездә бер ай яшәп калсагыз да, мин шатланган кебек, мәхәллә халкы да, бөтен мөселманнар да канәгать булып шатланачак. Үтенеп сорыйм: гафу итегез мине, мин ашыгычлык белән хата ясадым. Бүген бу җирләр – Кытай мәмләкәте һәм Кытай хөкүмәте, ләкин без, мөселманнарның, һәр хәрәкәтен инглизләр күзәтү астында тота. Менә тагын бер-ике генә көн калсагыз, үзегез дә күрерсез. Безнең хәлебезне аңларсыз, шулвакыт минем бу мөгамәләмне дә кичерерсез.

– Инглизләр ничек итеп сезне күзәтү астында тота алалар? Биредә инглиз түрәләр бармы?

– Әйе, биредәге түрәләрнең күпчелеге – инглизләр. Бигрәк тә полиция идарәсе гел алардан гына тора. Безнең өстебездә карчыга кебек торучылары исә – инглиз рәисләр кул астында хезмәт итүче Һиндстан мөселманнары. Кем килде, кем китте, нәрсәгә килде – болар турында бездән берәм-берәм сорашып белгәннән соң, яшерен үз күзәтүләрен дә өстәп, җитәкчелеккә җиткерәләр.

– Менә мин аңларга теләгән җәһәт тә шул. Карагыз, әгәр бераз фикер йөртеп, киләчәкне уйласагыз, бүген бу мәмләкәт белән бернинди бәйләнешләре булмаса да, сезнең хокукларыгызны кимсетәләр икән, иртәгә бу залимнәр мәмләкәтнең идарә эшен тулысынча үз кулларына алсалар, сезгә нинди генә золым эшләмәсләр?! Болардан тыш, бүген бөтен әйләнә-тирәгезне сарып алган миссионерлар халкыгызны туры юлдан яздырып, хаклыктан ерак торган фикерләренә күндерергә теләсәләр – сездә гади халык бар да җаһил – аларны аз гына вакыт эчендә, бик җиңел юллар белән күндерә алачаклар. Гади халыкны гына түгел, голәмәгезне дә туры юлдан яздырсалар, шулвакыт Сез ни эшләрсез? Үзегезне ничек саклап калырсыз? Мин Сезнең белән менә шулар турында сөйләшергә телим. Бу җәһәтләргә кагылышлы, минем күңелемне тынычландырырлык фикерләрегезне генә әйтегез, шәһәрегездә бер көн дә торып калмам, Сездән бер тиен акча да сорамам. Иртәгә үк юлга чыгачакмын.

– Инде мин Сездән үтенәм: безнең шәһәребездә бер-ике көн генә булса да кунак булып калыгыз. Сездән моны олы ихтирамым белән, үтенеп сорыйм.

*Төрекчәдән **Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №8 август 2021

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

Икенче дәрес
АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ КОДРӘТЕ, ГЫЙЛЕМЕ, РӘХМӘТЕ

Мөгаллим: Безнең бу мәктәпне кем ясаган дигән идек әле?

Шәкерт: Агач осталары ясаганнар.

Мөгаллим: Агач осталары өйне һичбер нәрсәсез ясый алалармы?

Шәкерт: Юк, ясый алмыйлар. Өй салыр өчен бүрәнәләр, агачлар кирәк.

Мөгаллим: Агач осталары шуның белән генә өйне сала аламы?

Шәкерт: Юк, сала алмыйлар. Агачларны ярырга, кисәргә пычкы вә балталар, юнырга вә тишәргә юнгыч вә өтергеләр, башка кораллар да кирәк. Ансыз агач осталары өй сала алмыйлар.

Мөгаллим: Шулай шул. Өй салыр өчен агач һәм кораллар кирәк. Таш өй булса, таш, кирпеч, балчык вә известь кирәк! Шунсыз өйне салып булмый. Ә Аллаһы Тәгаләгә боларның берсе дә кирәкми. Аллаһы Тәгалә бөтен дөньяны вә дөньядагы бөтен нәрсәне һичбер нәрсәсез юктан бар кылган. Чөнки Аның һәрнәрсәгә көче җитә. Ул һәрнәрсәне эшли ала. Ягез әле, балалар, бердән әйтик: «Аллаһы Тәгаләнең һәрнәрсәгә көче җитә. Аның кодрәтенең чиге юк».

Аллаһы Тәгаләнең һәрнәрсәгә көче җитә. Ул бөтен дөньяны, дөньядагы без күргән вә күрмәгән бөтен нәрсәләрне юктан бар кылган, дигән идек. Шулай булгач, Ул бөтен нәрсәне белә дә, Ул моңарчы булган нәрсәләрне дә, булып торган нәрсәләрне дә, булачак нәрсәләрне дә – барысын да белә, барысын да күрә. Безнең кылган эшләребез дә, кылачак эшләребез дә – барысы да Аңа билгеле, һичбер нәрсә Аңа яшерен түгел. Яле, балалар, барыбыз бердән әйтик: *«Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәне белә. Булган вә булачак нәрсәләрнең барысы да Аңа билгеле. Безнең кылган вә кылачак эшләребез дә – барысы Аңа билгеле. Аңа һичнәрсә яшерен түгел».*

> **«Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәне белә. Булган вә булачак нәрсәләрнең барысы да Аңа билгеле. Безнең кылган вә кылачак эшләребез дә – барысы Аңа билгеле. Аңа һичнәрсә яшерен түгел».**

Йә, Габдерахман, сөйлә әле: син башыңдагы кәләпүшне кайдан алдың?

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

Шәкерт: Әткәй базардан алып кайтып бирде.

Мөгаллим: Ә читегеңне кем бирде?

Шәкерт: Аны да әткәй алып бирде.

Мөгаллим: Ә күлмәгеңне кем тегеп бирде?

Шәкерт: Әнкәй тегеп бирде.

Мөгаллим: Шулай шул, синең кигән киемнәреңне әткәң алып биргән, әнкәң тегеп биргән. Алар сине ашата-эчертә, тәрбия кыла. Әнкәң сиңа йоклар өчен урын түшәп бирә. Сине кадерли, хөрмәтли. «Балам», – дип, башыңнан сөя. Алар сиңа һәрвакыт яхшылык телиләр. Беләсеңме, ни өчен алар алай итәләр?

Шәкерт: Чөнки алар мине яраталар.

Мөгаллим: Дөрес, алар сине ятратканга күрә шулай тәрбия итәләр, кадерлиләр, хөрмәтлиләр. Алар сиңа бик шәфкатьлеләр, бик мәрхәмәтлеләр шул. Менә син әйт: күк, җир, күктә вә җирдә булган нәрсәләрне кем яралткан иде әле?

Шәкерт: Аллаһы Тәгалә яралткан.

Мөгаллим: Ә безне?

Шәкерт: Безне дә Ул яралткан.

Мөгаллим: Соң без бу нәрсәләрдән файдаланабызмы?

Шәкерт: Файдаланабыз.

Мөгаллим: Әлбәттә, файдаланабыз: җиргә иген чәчәбез, болыннардагы печәннәрне чабып алабыз. Урманнарны кисеп, өйләр салабыз, утын итеп ягабыз. Чишмә, елга вә күлләрнең суларын эчәбез, балыкларын тотабыз. Кояштан җылылык алабыз. Ул безгә яктылык бирә. Ай вә йолдызлар караңгы төннәрдә безгә яктылык тараталар. Хайваннардан файдаланабыз: атларны җигәбез, атланып йөрибез. Сыерларны савабыз: сөт, катык, май вә итләрен ашыйбыз. Сарык, куй вә кәҗәләрнең итләреннән, йоннарыннан, тиреләреннән файдаланабыз. Беләсеңме, Аллаһы Тәгалә бу нәрсәләрне безгә ни өчен биргән?

Шәкерт: Чөнки Ул безне ярата, шуның өчен биргән.

Мөгаллим: Бик дөрес әйттең. Ул безне бик ярата. Ул безгә гаять мәрхәмәтле. Аның рәхмәтенең иге-чиге юк. Шул рәхмәте сәбәпле, Ул безне яралтып, безгә җан биргән. Күрергә күз, ишетергә колак, сөйләргә тел, тотарга кул, йөрергә аяк, уйларга аң вә акыл биргән. Ягез әле, балалар, барыбыз бердән әйтик: *«Аллаһы Тәгалә бик мәрхәмәтле. Аның рәхмәтенең иге-чиге юк».*

«Аллаһы Тәгалә бик мәрхәмәтле. Аның рәхмәтенең иге-чиге юк».

Текстны басмага ***Мәдинә Әбделганиева*** *әзерләде.* ■

Себерне өйрәнгән галим

Алсу Вәлиева*



Егет чак. Фоат Вәлиев (сулда) яшьлек дусты белән

Әтием, танылган этнограф, тарих фәннәре докторы, профессор, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе Фоат Таҗ-Әхмәт улы Вәлиев (1918-2010) турында язу һәм сөйләү җиңел һәм бер үк вакытта авыр да, чөнки бу хикәяләү тулы бер гасырны тәшкил итә. Аңа Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән озын гомер революциянең соңгы чорын, Гражданнар сугышын, Сталин репрессияләрен, Бөек Ватан сугышы һәм аннан соңгы елларны, социализм төзелеше, үзгәртеп кору, һәм, ниһаять, хәзерге тынычсыз елларны колачлый.

Фоат Вәлиевнең тормышы турында фактик материаллар 1943-2003 нче елларда үз кулы белән язылган көндәлекләрдә сакланып калган. Ул соңгы көннәренә хәтле армый-талмый үзенең хатирәләрен барлады, җанын борчыган нәрсәләр турында язды. Кайда гына яшәмәсен, ул тамыры, хәтер күзәнәкләре белән Себернең елга-күлләренә, ак кар белән капланган тигезлекләренә һәм бай кара урманнарына береккән иде.

* Вәлиева Алсу Фоат кызы – социология фәннәре докторы, Бөтенроссия дәүләт юстиция университетының Казан филиалы профессоры, композитор.

Фоат Вәлиев һәм хатыны София

Әтием Фоат Вәлиев 1918 елның 14 ноябрендә Омск өлкәсенең Тара районындагы Яланкүл (Еланлы) авылында күп балалы ярлы крестьян гаиләсендә туган. Күршедәге Үләнкүл мәктәбендә укыган. Бабам Таҗ-Әхмәт Шәриф улы себер татарларының фольклор мирасын яттан белгән, татар һәм рус телләрендә бик яхшы сөйләшүче, халык җырларын бик оста башкара торган кеше иде. Аның «Төрек

маршы»н җырлаганын үземнең дә ишеткәнем булды. Бабаларым гарәп телен яхшы беләләр иде, аларның гарәп графикасында язылган хатлары өйдә әле дә саклана. Таҗ-Әхмәт Шәриф улы, авылның укымышлы, гаять актив кешесе буларак, 1927-1929 нчы елларда Яланкүл Авыл Советы рәисе, соңрак кибетче булып эшли. Әтиемнең бабасы Шәриф Вәли улы, гади крестьян булса да, гарәп телен яхшы белгән. Авылда аны **«Шәриф мулла»** дип атап йөрткәннәр. Фатилә Мөэмин кызы – минем әбием, себер татарлары теле белән әйткәндә карт инәм була. Ул дөньяга 18 бала тудыра, аларның өчесе генә Себердәге коточкыч ачлыкта исән кала. Шуларның берсе – әтием, икенчесе – әтиемнең фронтта югалган энесе Гыйффат һәм сеңлесе Наҗия.

«Әти безгә себер татарлары әкиятләрен сөйли иде»

Авыл Советы рәисе булган вакытта, бабам Таҗ-Әхмәт Казаннан татар телендәге китаплар китертеп, аларны Сабан туе көнне Яланкүл һәм якын тирәдәге авыллар халкына тараттыра торган булган.

Шулай итеп, әтием Фоат сабый чагыннан ук гыйлемгә тартыла. Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов әтиемнең иң яраткан язучыларыннан иде. Булачак галим татар башлангыч мәктәбендә белем ала. Моннан тыш, ул Большереченск тулы булмаган урта мәктәбендә рус телендә дә укый. Аны тәмамлагач, 1931 елда, ягъни 12 яшендә Тара педагогик мәктәбенең 1 нче курсына укырга керә, әмма, гаиләнең матди хәле авыр булу сәбәпле, белем алуын дәвам итә алмый. 1933-1934 нче елларда әтием Үләнкүл крестьян яшьләр мәктәбен тәмамлый, аннары ул Омск авыл хуҗалыгы академиясенең рабфагына укырга керә. Соңрак берничә ел Яланкүлдә рус һәм инглиз телләре, математика укытучысы булып эшли. Армиягә чакырылу сәбәпле, Омск педагогика университетының тел һәм әдәбият факультетындагы укуын өзеп, Урал хәрби округында шофер булып хезмәт итә, аннары Төрекмәнстан-Иран чигендә юл төзелешендә эшли.

Фоат Вәлиев (уңнан икенче) хәрби укулар вакытында

Бөек Ватан сугышы елларында әти 2 нче гвардия танк армиясендә Украина һәм Белоруссия фронтларында сугыша, политрук, батальон командиры урынбасары булып хезмәт итә. Варшаваны, Праганы азат итү сугышларында катнаша. 1945 елның февралендә каты яраланып, ул Җиңүне Көнбатыш Украина госпиталендә каршылый, аннары Карловы Варыга (Чехословакия) дәваланырга җибәрелә. Әти сугышны капитан дәрәҗәсендә тәмамлый, соңрак полковник дәрәҗәсенә күтәрелә. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, күп медальләр белән бүләкләнә.

Әтиемнең кулында немец профессорының җәрәхәтне дәвалау турында киңәшләре язылган белешмә кала. Ул аны бик кадерләп саклый һәм, еш кына искә төшереп, немец табибларының совет офицерларына һәм солдатларына карата дошманлыгы, нәфрәте булмавын белдерә. Әтием сөйләвенчә, медконсультация Бранденбург капкасы янындагы хастаханәдә үткән. Анда аны, җитди яраланган яшь капитанны, хирург карый, ярасын бәйли һәм авыруы турында белешмә бирә.

Сугыш тәмамлангач, Ф.Вәлиев Омскка кайта, Педагогика институтының тарих факультетына укырга керә һәм 1948 елда аны уңышлы тәмамлый. Аннары ул кабат кораллы көчләр сафына алына, бу юлы Омск танк-техник училищесы укытучысы булып эшли һәм аңа майор дәрәҗәсе бирелә. Берничә ел укытканнан соң, аны Көнбатыш Себер гарнизонына танк полкы командиры урынбасары итеп күчерәләр һәм ул анда 1960 елга кадәр эшли. Мин балачакта әтиемне соры хәрби шинельдә, кулына компас, сыбызгы тоткан һәм хольстерында (кобурада) пистолет белән хәтерлим. Аннары ул Оборона министрының боерыгы белән эшеннән азат ителә һәм Омск инженерлык институтында укытучы булып эшли башлый. Моннан тыш, Омск университетында, Педагогика институтында һәм Омскиның башка югары уку йортларында тарих буенча лекцияләр укый.

Безнең мирас №8 август 2021

Фоат Вәлиев архивында себер татарлары коллекциясе

«Минем өчен профессор Фоат Вәлиев – беренче чиратта әти. Мине ат җигеп чанага утырткан, кичен себер татарларының җырларын көйләгән, соңгы көннәренә кадәр безнең турында кайгыртып, акыллы һәм төпле киңәшләрен биргән, онытылмаслык Кеше булды ул.

Әнием София Мөнҗир кызы (1922-2004) да Бөек Ватан сугышында зенитчы һәм элемтәче булып хезмәт итә, 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә. Гомерләренең иң матур елларын Ватанны саклауга багышлаган ике фронтовик 1950 елның җәендә кавышып, ярты гасырдан артык бер-берсенә терәк булып яши. Аларның тормышлары бәхет-шатлык, зур җиңүләр, сынау-газаплар белән бергә үрелеп бара. Ә иң мөһиме – алар һәрчак оптимист була, гомерләрен шәкертләре һәм яраткан балалары белән бергә уздыра.

Борынгы фәнни үзәк – Татарстанның башкаласы Казан һәрвакыт әти-әниемне җәлеп итә. Әтием Фоат, тарихчы, этнограф, Себер татарлары мәдәнияте белгече буларак, Казанда танылa. Ә әнием София – Казан университетын тәмамлаган тюрколог, себер татарлары теле һәм фольклорын фәнни нигездә тикшергән галимә, КДПИ доценты. Энем Булат Вәлиев та әти-әнием эзеннән барды. Ул, инглиз, немец

һәм төрек телләрен камил үзләштереп, гомерен тәрҗемә һәм эшкуарлык хезмәтенә багышлады. Энем белән мин әти-әнинең фәнгә тугрылыгын, максатчанлыгын күреп үстек. Алар үз идеяләрен якладылар, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен яздылар, төрле дәрәҗәдәге конференцияләрдә актив катнаштылар, Мәскәү, Ленинград, Ташкент, Төмән, Омск, Новосибирск һәм Россиянең башка шәһәрләренә сәяхәт иттеләр.

Фоат Вәлиев Казан дәүләт төзелеш һәм архитектура институты профессоры

Әтиемнең бөтен фәнни хезмәтләре себер бохаралылары, үзбәк, таҗик, каракалпак һәм башка төрки халыклар турында. Гомере буе Себерне, Төньяк һәм Ерак

Көнчыгыш халыклары, себер татарларының тарихын һәм этнографиясен өйрәнә ул. Күптән түгел әтиемнең бай этнографик китаплар тупланмасын туган ягына – А.С.Пушкин исемендәге Омск дәүләт китапханәсенә бүләк иттем.

Әтиемнең ата-бабалары – Себер бохаралылары. Ф.Т.Вәлиевнең кандидатлык диссертациясе – «XIX гасырның икенче яртысында-XX гасыр башында Себер бохаралылары» (1965) заманы өчен бик мөһим һәм нәтиҗәле булып чыга. Әлеге хезмәт җирле себер татарларының чын тарихка күзләрен ача, алар үзләренең бай тарихына, мәдәниятенә төшенә. Ф.Вәлиев яшь галимнәргә себер татарларының Хәрәзем, Бохара, Коканд кебек ханлыклар белән багланышларын тикшерү өчен юл ача. Шулай итеп, әтием этнография фәнендә Көнбатыш Себернең җирле халкын монографик планда өйрәнгән, себер татарларының бай мәдәниятле халык булуын дәлилләгән беренче галим булды.

Узган гасырның 60-70 нче елларында безгә гүзәл Төркиядән гарәп һәм латин графикасында язылган матур открыткалар һәм хатлар килә иде. Аларны мөһаҗир туганнарыбыз – XX гасыр башында Себердән Төркиягә киткән татарлар, бохаралылар туган илләрен сөеп-сагынып, елый-елый яздылар. Якташларының фаҗигале язмышы әтиемне яңа фәнни эшләргә рухландырды. 1988 елда Ф.Вәлиев Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясенең Н.Н.Миклухо-Маклай исемендәге Этнография институтында «Себер татарлары (XIX гасырның икенче яртысында-XX гасыр башында): этнокультуралы үсеш проблемалары» исемле докторлык диссертациясен яклый, аның фәнни консультанты күренекле этнограф, археолог, көнчыгыш белгече С.И.Вайнштейн була. Диссертация, монография һәм фәнни мәкаләләр язганда, әти күп галимнәр белән даими элемтәдә тора, алар белән хат алышып, үзенең концепциясе һәм идеяләре өчен киңәшләр ала. Этнографлар Ф.Итс, Ю.В.Бромлей, Н.А.Томилов, В.С.Томиловаларның, үзбәк тарихчысы Хәмид Зияев, тюрколог Әнвәр Тенишев кебек галимнәрнең исемен без гаиләдә аеруча еш ишетә идек.

Әти гомерен багышлаган мөһим фәнни хезмәтне балалары гына түгел, оныклары да аңлады һәм мөмкин булганча аңа ярдәм итте. Елена Фәйзрахманова (Панькина), Сәид һәм Тимур Вәлиевләр дә фән юлын дәвам итте. Беренче оныгы Елена (минем кызым) студент чагыннан ук бабасының «фәнни сәркатибе» вазыйфасын башкарды, аның архивын тәртипкә салып, мәкаләләрен бастырып чыгарды.

Ф.Вәлиев Казан дәүләт төзелеш һәм архитектура институты студентларын укытуга да күп көч һәм вакытын бирде, кафедра мөдире вазыйфасын башкарды. Студентлар һәм хезмәттәшләре аны һәрвакыт рәхмәт һәм хөрмәт сүзләре белән искә төшерә. Алар хәтерендә ул принципиаль, әдәпле, эш сөючән, игелекле, сәләтле кеше, патриот-ветеран, галим, укытучы булып калды. Аның өчен батырлык үрнәге совет генералы, Себер кешесе Дмитрий Карбышев булды. Әти генералның сеңлесе белән очрашты, аның турында бик кыйммәтле материаллар туплады һәм батырлыгы турында берничә мәкалә язды.

«Здравия желаю, товарищ полковник!» – профессор Фоат Таҗ-Әхмәт улы Вәлиев аудиториягә килеп керү белән, студентлары аны менә шулай сәламлиләр иде. Олы яшьтә булуына карамастан, аны институтка Россия тарихы буенча лекцияләр укырга чакырдылар. Ул яшь буында ватанпәрвәрлек тәрбияләүне алга куйды, кеше соңгы сулышына кадәр Ватанына тугры хезмәт итәргә тиеш дип санады.

Минем өчен профессор Фоат Вәлиев – беренче чиратта әти. Мине ат җигеп чанага утырткан, кичен себер татарларының җырларын көйләгән, соңгы көннәренә кадәр безнең турында кайгыртып, акыллы һәм төпле киңәшләрен биргән, онытылмаслык Кеше булды ул. ■

Безнең мирас №8 август 2021

Себер киңлегеннән – халык күңеленә

(Фатих Урманче истәлегенә)

Лилия Мөхәммәтҗанова

Ф.Урманче фольклор экспедициясендә. Сарытау өлкәсе, 1963 ел

Татар фәнендә чал тарихның үзе кебек үк борынгы, бай, четерекле, тирән һәм тәэсирле, бүгенгенең рухи тамырларын тәшкил иткән, «халык иҗаты» дип аталган гаҗәеп мәгънәле бер өлкә бар. Төбендә энҗе-мәрҗәннәр тулы мул сулы дәрья белән дә чагыштырырга мөмкин аны. Халкыбызның шушы гаять үзенчәлекле җәүһәрләре бүгенге фән-техника казанышлары чорында да игътибарны җәлеп итә, ихтыярсыз сокландыра, үткәнебезгә горурлык хисе тудыра, тарихи хәтеребезне яңартып, киләчәккә өмет кабыза икән, димәк, фәннең әлеге тармагында талантлы галимнәребез шактый күп көч куйган. Халкыбыз мирасының тарих тузанына күмелеп калмавында да, тиешле югарылыкта халыкка җиткерелүендә дә, башка халыклар сафында горур яңгырарлык ядкярләребезнең сакланып калуында да зур өлеше бар бу шәхесләрнең.

Сүзебез гомере буе фольклор әсәрләрен гасырлар тирәнлегеннән сөзеп алып, безнең чорга якынайту, кыйммәтен билгеләп, киләчәк буынга тапшыру белән шөгыльләнгән эрудит-галим Фатих Ибраһим улы Урманчеев турында. Әйе, бөтен

гомерен халкыбызның эпик һәм лиро-эпик мирасын туплауга, шул ядкярләрне өйрәнүгә, халыкның үз байлыгын үзенә кире кайтаруга багышлаган фидакяр зат иде Фатих ага. Фән юлын матур уза белгән галимнәрнең берсе булды ул. Аның хакында татарның мәгълүм галимнәре, язучылары һәм хәтта шагыйрьләре дә шактый язды. Барысы да Фатих Урманчеевны татарның милли җанлы, затлы галиме дип раслый. Мондый асыл шәхесләребез хакында кат-кат сөйләү, аңа хас сыйфатларны ассызыклау, казанышларына янә игътибарны юнәлтү беркайчан да артык була алмый.

Шагыйрь җанлы Фатих абыйның үзеннән дә, сүз сөрешеннән дә, басылган хезмәтләреннән дә теләсә кайсы чор һәм теләсә кайсы катлам өчен тансык җуелмас кыйммәтләр – затлылык, галимлек, яхшы мәгънәсендәге эрелек, аксакаллык, тирәнлек һәм киңлек, ваклыклардан һәрвакыт өстен кала белгән олуглык, шулар белән бергә нечкә күңеллелек бөркелә иде. Болар – һәркемне тартып тора торган күркәм сыйфатлар һәм аларның сирәк кешедә генә очрый торганнары.

Фатих аганы хезмәтләре аша студент вакытымнан ук белсәм дә, аның үзе белән аралашып эшләү бәхетенә Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына килгәч ирештем. Язмышымның бәхетле сукмагы үз вакытында институтның нәкъ менә шушы олпат шәхес җитәкчелек иткән халык иҗаты бүлегенә алып килүен тормышымдагы иң уңышлы вакыйгалардан саныйм. Төрки дөньяда исеме билгеле зур галим Фатих Урманчеев үз өлкәсендә дистәгә якын фән кандидаты, берничә фән докторы әзерләде. Аның мәктәбен үтүчеләр галимнең хезмәтләрен өстәл китабы итеп тота. Гап-гади кебек тоелган мөнәсәбәтләр артына олуг галимнең фәнни тырышлыгы гына түгел, оста педагогик эшчәнлеге, сизгер психолог булуы, эшкә дәртләндерә белүе, алдан күрүчәнлеге, кече күңеллелеге һәм, әлбәттә, башка гаҗәеп сыйфатлары белән бергә, һәрчак үз урынында булуы, галим кеше нинди була дигәндә, аның шәхси үрнәгенең югары дәрәҗәдә торуы яшеренгән. Фатих аганың шәкертләре бүген инде үзләре дә фән докторлары, алар минем белән ихластан килешерләр дип уйлыйм: ул – милләтнең киләчәге турында алдан уйлап, сиздерми генә кайгырта белә торган чын милләтпәрвәр-остаз иде. Күренекле Хәмит Ярми нигез салган, бүгенге көндә фән дөньясында танылу алган Казан фольклор мәктәбенең иң якты йолдызы, олы ихтирамга лаек могтабәр шәхесебез ул Фатих ага.

Быелның 28 маенда алыштыргысыз остазым, күренекле фольклорчы-галим Фатих Урманчеевка 85 яшь тулган булыр иде. Аның гомере һич кенә дә заяга үтмәде, гаять дәрәҗәдә нәтиҗәле булды. Фатих Ибраһим улы узган юл – татар халкы өчен бәрәкәтле нәтиҗәгә ия олы фән юлы. Себер киңлекләренең тугыз гына йортлы бер авылында дөньяга килеп, үз гомерендә халкы өчен шактый зур эшләр эшләргә өлгерде, төрки фән дөньясында мәгълүм зат булып танылды ул.

Фатих Ибраһим улы Урманчеев 1936 елның 28 маенда Омск өлкәсенең Азов районындагы Кызыл Маяк авылында туган. 1955 елда – Омск дәүләт педагогия училищесын, 1960 елда Омск дәүләт педагогия институтының киңәйтелгән тарих һәм филология факультетын тәмамлаган. Студент елларында ук халык иҗаты белән кызыксына, доцент В.А.Василенко җитәкләгән фольклор түгәрәгенең старостасы булып, түгәрәк эшчәнлегендә актив катнаша, рус студентлары алдында татар халык җырлары һәм бәетләренә багышланган эчтәлекле чыгышлар ясый, Мәскәүдә чыгып килә торган «Русский фольклор» альманахында исә бу хакта мәгълүматлар басыла. Булачак галимнең халык иҗаты белән кызыксынуы шушы чорда ук башлана.

Ф.Урманче Татарстанның халык шагыйре Р.Миңнуллин белән

Институтны тәмамлаганнан соң, ул туган ягындагы Сосновка авылы урта мәктәбендә ике елга якын укыта. Ф.Урманчеевта өметле яшь белгечне күреп алган Казан галимнәре И.Надиров һәм Э.Касыймов 1962 елда аны Татарстан башкаласына, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына аспирантурага чакыралар. Егет тәкъдимне кабул итә, язмышы аны менә шулай нурлы Казан белән бәйли.

Аспирантураны тәмамлагач, Ф.Урманчеев 1965-1969 нчы елларда шул ук институтның Халык иҗаты һәм халык сәнгате тарихын өйрәнү секторында кече фәнни хезмәткәр булып эшли, 1968 елда «Татар совет халык иҗатында төп жанрларның үсеш юллары» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. 1961-1971 нче елларда ул – Казан дәүләт педагогия институтының рус һәм чит телләр әдәбияты кафедрасында әүвәл – ассистент, соңыннан укытучы-доцент хезмәтендә. 1971 елдан Ф.Урманчеев Алабуга педагогия институтында дүрт ел буе – институтның читтән торып уку бүлеге проректоры, 1975 елдан уку-укыту эшләре буенча проректоры була. Язмышы һәм СССР Мәгариф министрлыгы тәкъдиме галимне чит җирләрдә дә йөртә: 1980-1984 нче елларда ул Венгриядә махсус командировкада булып, Эгер шәһәрендәге педагогия институты студентларына рус әдәбияты тарихын укыта. 1984 елда яңадан Алабугага кайтып, педагогик эшчәнлеген дәвам итә. Ә 1989 елда галим Ташкентта докторлык диссертациясе яклап, 1990 елда әдәбият кафедрасы профессоры дигән гыйльми исем ала. Ф.Урманчеевның әле чит илгә киткәнче үк язып тәмамланган, докторлык диссертациясенә бәрабәр, әмма ул еллар өчен гаять шикле саналган «Татар халкының героик эпосы» дип аталган зур хезмәте исә китап булып бераз соңрак дөнья күрә.

1992-2009 нчы елларда галим – Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында – халык иҗаты бүлеге мөдире, аннан соңгы елларда – бүлектә баш гыйльми хезмәткәр.

Ф.Урманчеевның иң зур хезмәтләре татар халык иҗатының эпик һәм лиро-эпик жанрларына багышланган: «Халык авазы: татар халык бәетләре тарихыннан» (1974), «Эпические сказания татарского народа» (1980), «Героический эпос татарского народа» (1984), «Дастаннарга лаек замана: борынгы фольклор һәм хәзерге поэзия» (1990), «По следам Белого волка: ранние этнокультурные связи тюрко-татарских племен» (1994), «Волшебный клубок: Муса Джалиль и народное творчество» (1995), «Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә» (1997), «Народный эпос «Идегей» (1999), «Борынгы миф һәм бүгенге шигырь: Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин шигъриятенә бер караш» (2002), «Лиро-эпос татар Среднего Поволжья» (2002), «Роберт Миңнуллин: шигъри осталык серләре» (2005), «Каһарманнар йолдызлыгы: тарихи-фольклористик очерклар» (2006), «Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек. 3 томда», «Тюркский героический эпос» (2015).

Гыйльми эшчәнлегендә төп урынны халык иҗаты алып торса да, галимнең эзләнүләре күпкырлы булды. Аны язма әдәбият, этнография, тарих, мифология мәсьәләләре тирәнтен кызыксындыра иде. Ул бу мәсьәләләрне һәрвакыт гаять оста итеп татар фольклоры белән бәйләде. Ф.Урманчеевның һәр язганы, чын галимнәр хезмәтенә хас булганча, фәндә яңа сүз булып кабул ителә килде.

Аерым китап булып басылып чыккан дистәдән артык фәнни монографиясе, ул төзегән, татар мифологиясенә багышланган өч томлык уникаль энциклопедиясеннән тыш та әле галим – вузлар өчен татар халык авыз иҗатыннан төзелгән иң беренче дәреслек (2004) һәм хрестоматия (2004), көндәлек матбугатта фольклор, тарих темаларына һәм тарихи шәхесләр турында, язучы-прозаиклар һәм бигрәк тә шагыйрьләр иҗатына, әдәбият-мәдәниятнең актуаль проблемаларына, гыйльми хезмәтләргә багышланган өч йөзгә якын фәнни мәкалә, очерклар, рецензияләр һ.б. авторы.

Ф.Урманчеев – Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1996), Халыкара төрки академия академигы (1997) иде, 1996 елда Татарстанның Мактау грамотасы белән бүләкләнде, Татарстан һәм Россия Язучылар берлеге әгъзасы да булып торды.

Гомере буе халкыбызның фольклор хәзинәсен барлаган, аның биниһая могҗиза булуына төшенеп, башкаларга да бу өлкәнең мавыктыргыч серләрен ачкан, фольклор дөньясына дәшеп, үз артыннан ияртә белгән көчле фикерле, күренекле татар галиме иде Фатих Ибраһим улы Урманчеев. Фәннең шактый катлаулы, филология һәм тарихи фәннәрдән генә дә түгел, фәлсәфә, дин гыйлеме һ.б. өлкәләрдән дә гаять киң мәгълүматлы булуны таләп итә торган фольклористикага мөкиббән чын галим иде ул. Дөресен әйткәндә, андыйлар бик сирәк, галимнәр арасында Фатих абый кебеге башка юктыр да. Аның фикер колачы киң булды, яхшы гамәлләре бихисап иде, әйткән сүзе һәрвакыт зиһен ачыклыгына этәрде. Галим татар халкы өчен генә түгел, бөтен төрки дөнья һәм эпос фәне белгечләре өчен зур әһәмияткә ия фәнни хезмәтләр калдырды. Гыйльми казанышлары, якты исеме, даны онытылмас Фатих Ибраһим улының. Фәндә ул юл күрсәткән затлар шактый һәм аны үзенең остазы дип санаучылар татар галимнәре генә дә түгел; бөтен төрки дөнья фольклорчы галимнәре, шулай ук Идел-Урал төбәге эпос белгечләре Фатих Урманчеевның зур галим булуын таныйлар, аны ихлас сагынып искә алалар. Шунысы куанычлы: галимнең эше бүгенге көндә киң колач белән дәвам итә. Рухы шат булсын остазның! ■

Безнең мирас №8 август 2021

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

ИСМӘГЫЙЛЕВ ГОМӘР (1907-1983)

Атаклы татар режиссеры. 1907 елның 15 июнендә Чиләбе шәһәрендә вак сәүдәгәр гаиләсендә туган.

1944 елда НКВД тарафыннан Кырымтатар театры коллективы белән Урта Азиягә сөрелә. 1956 елда аклана. Үзбәкстан театрында баш режиссер булып эшли.

Әндиҗан зиратында җирләнгән.

ИСХАКЫЙ ӘХМӘТХӘСӘН (1896-1940)

Ана теле мөгаллиме. Татарстанның Чистай өязендәге Яуширмә авылында мулла гаиләсендә туган.

Атаклы татар әдибе Гаяз Исхакыйның энесе булганга күрә, НКВД тарафыннан эзәрлекләнә, зинданга ябыла (1937-1939). Аны бик каты җәзалыйлар. Җәзалауларга түзә алмыйча, Әхмәтхәсән үз-үзенә кул сала.



ИСХАКОВ ӘСХӘТ (1921-1976)

Журналист, хәрби командир. «Азат Төркестан» газетасының баш мөхәррире. Кытайдагы Колҗа шәһәрендә бай татар сәүдәгәре гаиләсендә туган. Инкыйлаб гаскәренең штабында сәркатип булып хезмәт итә.

1962 елда мәдәният инкыйлабы (мәдәни революция) вакытында кулга алына. Җәзалауларга түзә алмыйча, зинданда һәлак була. Каберенең кайдалыгы билгесез.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

ИСХАКЫЙ ГАЯЗ (1887-1954)

Татар әдибе, сәясәтче. Казан губернасының Чистай өязендәге Яуширмә авылында мулла гаиләсендә туган.

Исхакыйны патша жандармериясе берничә тапкыр кулга ала. Совет хакимияте килгәч тә, большевиклар аңа көн күрсәтми. Нәтиҗәдә, ул чит илгә китәргә мәҗбүр була. Төркиядә (Анкарада) вафат була. Кабере – Истанбулның Әдернәкапы зиратында.

ИСХАКОВ МӘРГУП (1923-1992)

Колҗадагы татар мәктәбе укытучысы (Кытай). Тарбагатайдагы Дурбулжине авылында сәүдәгәр гаиләсендә туган. Хәрби кеше буларак, ул баш күтәрүдә катнашкан. Полк командиры, полковник. 1955 елдан – генерал-майор (НОАК).

Кытай хөкүмәтенә каршы яшерен тәшкилат оештыруда гаепләнеп, берничә тапкыр кулга алына. Афәт якынлашканын сизенеп, ул 1960 елда Казакъстанга кача. Алма-Атада җирләнгән.

КАВИ ХӘМИТ (1906-1944)

Татар язучысы. Чуашстанның хәзерге Козловка районындагы Әлмән авылында мөгаллим гаиләсендә туган.

Украинаның Волынск өлкәсендәге Друженополь авылы тирәсендә барган каты сугышта һәлак була – танкта янып үлә.

КАВРИ АБДУЛЛА (1910-1943)

Кырымтатар композиторы. Кырымда, Ялта төбәгенең Симеиз саласында туган. Кырымны фашистлар басып алгач, Абдулла фашистларга каршы көрәшер өчен корылган яшерен оешмага языла.

Гестапо яшерен оешманың эзенә төшә һәм оешма әгъзаларының бөтенесе дә, шул исәптән Абдулла Каври да кулга алына. Оешмада катнашучыларны, бик каты җәзалаганнан соң, атып үтерәләр.

*Текстны басмага **Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Истә, һаман да истә!

Шагыйрь
Әдип Маликовның
туууына 100 ел

Шагыйрь, 1939 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1979), Р.Төхфәтуллин исемендәге әдәби премия иясе Әдип Малик улы Маликов 1921 елның 16 августында Башкортстанның Яңавыл районына караган Югары Чат авылында туган.

Ул 1946-1949 нчы елларда Татарстан радиосында әдәби-драматик тапшырулар редакторы булып эшли. 1955 елда Әлмәт шәһәрендә әдәби иҗат берләшмәсе оештырып, 1960 елга кадәр аңа җитәкчелек итә. 1963 елда әдәби берләшмә Әлмәт Язучылар оешмасына әйләнә. 1965-1967 һәм 1972-1982 нче елларда Ә.Маликов бу оешманың җаваплы сәркатибе булып эшли.

Кайбер китаплары: «Сахалин язмалары» (1948), «Кайнар эзләр» (1956), «Без кояшны юлда каршылыйбыз» (1964), «Кембригә юл салучылар» (1965), «Гашыйклар юлы» (1978).

Ә.Маликов 2009 елның 23 апрелендә Әлмәт шәһәрендә вафат булды һәм шунда җирләнде.

Язучы
Ибраһим Сәлаховның
туууына 110 ел

Язучы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1990), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1992), 1962 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, «Тайгак кичү», «Күкчәтау далаларында» һәм «Имәннәр тамыр җәйгәндә» романнары авторы Ибраһим Сәлахов 1911 елның 30 августында Казакъстанның Күкчәтау шәһәрендә туган.

Ул 1927 елда Казанга килә һәм педагогия техникумына укырга керә. Укуын 1930 елда тәмамлый. «Яшь ленинчы» һәм «Кызыл яшьләр» газеталарында, «Ялкын» журналында әдәби хезмәткәр булып эшли.

Репрессия фаҗигасен кичкән шәхес (1937 елның 25 октябрендә кулга алына, 1947 елның 25 октябрендә азат ителә).

Ибраһим Сәлахов 1998 елның 7 июлендә Күкчәтау өлкәсенең Кызыл Яр авылында вафат булды һәм шунда җирләнде.

2002 елда Казакъстанның Күкчәтау шәһәрендәге бер урамга әдип исеме бирелде.

Безнең мирас №8 август 2021

Актриса
Мәрзия Миңлебаеваның
тууына 110 ел

ТАССРның халык артисты (1970) Мәрзия Галимбай кызы Миңлебаева 1911 елның 11 августында Сарапул өязендәге Ижау шәһәрендә (Вятка губернасы) туган.

1931 елда ул Татар театр техникумын тәмамлый һәм Казан эшче театрында эшли башлый. 1936 елдан – Татар академия театрында.

Башкарган рольләре: Галиябану («Галиябану», М.Фәйзи), Гөлйөзем («Наемщик», Т.Гыйззәт), Зөбәрҗәт («Зөбәрҗәт», Ф.Сәйфи-Казанлы), Хатирә («Һиҗрәт», Н.Исәнбәт), Халидә («Тормыш җыры», М.Әмир) һ.б.

М.Миңлебаева 2000 елның 20 августында вафат булды.

Композитор
Рөстәм Яхинның
тууына 100 ел

Композитор, ТР Дәүләт гимны авторы, РСФСРның (1981) һәм СССРның халык артисты (1986), Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1959), ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1964) Рөстәм Мөхәммәтхаҗи улы Яхин 1921 елның 16 августында Казанда туган. Ул күренекле мәгърифәтче Таиб Яхин белән бер нәселдән. Аның нәсел җебе Саба районының Шыңар авылына һәм Теләче районының Казаклар авылына барып тоташа. М.Мәһдиевнең әнисе Бибирабига да шушы затлы тамырдан.

Рөстәм 3 яшендә пианинода үзлегеннән халык көйләрен уйный башлый. 13 яшендә музыка мәктәбенә укырга керә һәм 7 еллык мәктәпне 3 елда тәмамлый.

Р.Яхин 1993 елның 23 ноябрендә вафат булды.

Шагыйрь
Харрас Әюпнең
тууына 75 ел

Шагыйрь Харрас Гыйльмегали улы Әюпов 1946 елның 21 августында Татарстанның Мөслим районындагы Түреш авылында туган. Түрештәге башлангыч мәктәпне һәм шул ук районның Күбәк урта мәктәбен тәмамлаганнан соң Казанга килеп, 1964-1969 нчы елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. 1969-1972 нче елларда исә Мөслимдә чыга торган «Авыл утлары» район газетасында әдәби хезмәткәр вазыйфасын башкара. 1972-1983 нче елларда «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясендә эшли. 1983 елның декабреннән – Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе редакторы, мөдире. 1994-2007 нче елларда – нәшриятның баш редакторы.

Х.Әюпов 2008 елның 7 октябрендә кинәт вафат булды. Кабере Мөслим районының Түреш авылы зиратында.

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №8 август 2021

Әнвәр абый Гобәйдуллин рухына догам…

Әхтәм Зарипов, режиссер

Бу исем исемә төшкәндә күңелемә ниндидер рәхәт җылылык, яктылык нурлары үтеп, дәртләнеп, гамьсезлектән уянып киткәндәй булам.

Иҗади чишмә башым театр булганлыктан, театрыбызга төп йортыма баргандай, артистлар белән күрешеп сөйләшкәндә үземне туганнарым белән очрашкандай хис итәм. Әнвәр абый белән очрашу изге бер йола үтәгәндәй тәэсир калдыруы аерым игътибарга лаек хәл. Ул, театр дигән могҗизалар учагы сүнмәсен өчен, кирәк чакта җитәрлек ягулык өстәп торучы сакчыны хәтерләтә.

«Кыю кызлар» (Т.Гыйззәт) спектакленнән бер күренеш. Шәмгун – Ә.Гобәйдуллин, Шәйхезаман – Һ.Солтанов. 1968 ел

Моңа, театрга кайчан барсам да, Әнвәр абыйны очратуым, аңа нинди генә сорау белән мөрәҗәгать итсәм дә, тулы җавап алуым гына түгел, ә бәлки, йөзендә чагылыш тапкан ихласлыгы, ярдәм итәргә ашкынып торуы да сәбәп булгандыр. Бик тә ярдәмчел кеше иде ул. Алар Сания апа белән мәхәббәтле озын-озак гомер кичереп, кешеләргә борчу китермичә, мәшәкать тудырмыйча тыныч кына бакыйлыкка күчеп, үрнәк булырлык яшәүләре турында гыйбрәтле истәлекләр калдырдылар.

Сания апа белән Әнвәр абый яшьтән үк бер-берсенә гашыйк булып үссәләр дә, язмыш аларны кушылып яшәүдән мәхрүм итә. Сания апаны, ирексездән кияүгә биреп, Ташкент якларына озаталар. Ул анда ир бала таба. Әнвәр абый мәгъшукасын оныта алмый. Нәтиҗәдә, ул аны эзләп барып, баласы белән Казанга алып кайта. Белгән-күргән кешеләрнең сөйләүләренә караганда, ул баланы яратып, матур итеп 10 яшенә кадәр үстерсәләр дә, гомере кыска була. (Фаҗигале үлемгә дучар булуын сөйлиләр иде.) Башка балалары булмый. Әйтеп узуымча, Сания апа бөтен җылылыгын, мәхәббәтен Әнвәр абыйга юнәлтсә, Әнвәр абыйның исә терәге дә, узганы да, киләчәге дә театр иде.

Сарысыз кош йомыркасы, тәгәрмәчсез арба, тәрәзә һәм ишексез йорт булмаган кебек, Әнвәр абыйны мин театрсыз күз алдыма китерә алмыйм.

Артист буларак, аның кискен холыклы рольләре юк иде. Әмма ул катнашкан һәр спектакльдә башкарган рольләре нәкъ аныкы, спектакльне чынлыкка якынайткан холыклар иде. Әнвәр абыйны спектакльдә «фәлән рольдә уйнады» дип түгел, ә «яшәде» дип кенә хәтерләү дөресрәк булыр.

«Зәңгәр шәл»дәге, «Яшь йөрәкләр»дәге чуашын, «Казан сөлгесе»ндәге утын агачына карап вәгазь сөйләгән каравылчыны гына хәтергә төшерү дә аның үзенчәлекле талант иясе булуын раслый.

«Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш) спектакленнән бер күренеш. Екатерина – В.Минкина, Исак – Ә.Гобәйдуллин. 1985 ел

Әнвәр абый хакында язуымның максаты артистның башкарган рольләренә бәһа бирү түгел, ә, шәхес буларак, холкындагы кайбер кыйммәтле сыйфатларын гына искә төшереп узу. Бу үрнәк һәм гыйбрәт алу өчен кирәк.

Мин ул чорда профсоюз эшләре белән мавыгып, театрга ял йортлары төзү өчен Идел буендагы «Зеленый Бор» дигән урманнан җир алу мәшәкатьләренә күмелдем. Әгерҗе районында хатыным Җәмилә авылында 3х4 метр зурлыгында юкә агачыннан бура буратып, аны салу чыгымнары барысын да оныттырды.

Бураны күтәреп, эшне бетерәбез дип куанганда яныбызга сумка аскан бер урыс килеп: «Рөхсәт язуыгыз бармы?» – дип сорады. «Бар», – дип, кайда кем йорты торырга тиешлеге расланган язуны күрсәткәч, бу кеше «мүкләп салырга рөхсәт иткән» махсус язу сорагач, миңа ярдәм итешергә килгән иптәшем Әхмәт Рәшитов бу адәмне, фәлән-фәлән җиргә кит, дип куып җибәргәч, бу адәм туп-туры Совет районы башкарма комитеты рәисе Яркимбаевка бара. Ә Яркимбаев директорыбыз Рәшидә апаны чакыртып, мүкләп салган йортның кеше яши торган йорт дип саналуын, андый йорт хуҗасының фатир алырга чиратта торырга хакы юклыгын аңлата. Коты алынган директорыбыз, мине чакыртып, ашыгычлык белән күтәрелгән бураны сүтеп, мүкләреннән арындырып салырга кирәклекне аңлата. «Ярар», – дип, сүздә ризалашсам да, хәлемне аңлатып Әнвәр абыйга сөйлим. Үзе дә фатир көтеп йөргән кеше буларак, ул, хәлемә кереп, киңәшен бирә: «Гариф Гобәй дигән язучы «Школьный переулок» дигән тыныч урамда Салих Батыев белән бер йортта яши. Дөресен сөйләп хәлне аңлатсаң, Батыевка кереп, йортны төзеп бетерергә рөхсәт ителәә, дигән язу алыр ул», – ди.

Мин каршы килүемне сиздерәм. Әнвәр абый исә үзенекенә күндермәкче: «Радиода редактор булып эшләүче Эльза Гобәйдуллинаны беләсең бит. Аның, диктор Абдулла Дубинга кияүгә чыгып, туйлап йөргән чагы. Үзеңнең кыюлыгың җитмәсә, хәлне Эльзага аңлат. Бердәнбер кызының сүзен тыңламый калмас».

Чынлап та, икенче көнне үк Эльза миңа әтисенең чакыруын әйтте. Бардым, әлбәттә. Гариф Гобәй кулында Салих Батыев кул куйган мөһерле язу иде. Шул язуны алырга дип кулымны сузгач, Гариф Гобәй: «Бу язуны бирәм бирүен. Тик бер шарт белән: ул йортны миңа сатасың», – диде. Минем югалып калып ык-мык килүемнән соң ул: «Эшләнеп бетмәгән шул йортыңа ничә сум сорар идең?» – дип өстәде. Мин аны сатарга җыенмавымны сиздердем. Шуннан соң ул Батыев биргән язуны каядыр яшерде дә: «Ихтыярың, – диде. Бераздан: – Риза, дисәң, иртәгә машина яллап аны карап кайтырмын да, хакы турында сөйләшербез», – дип, сүзенең тәмам булуын белдерде.

Барган, караган, ошаткан.

– Йә, тиярен генә әйт: күпме сорыйсың? – ди бу.

– Минем исәбемчә, бурату, китерү, күтәрү чыгымнарын кушып исәпләгәндә, кимендә 3 мең, – дидем мин.

Гариф Гобәй мыскыллап көлде дә:

– 800 сум, – диде.

Кая барып, нихәл итим, дип, ризалыгымны белдердем, акчаны хәзер үк бирүне үтендем.

Гариф Гобәй, сатулашуны яраткан Бишбалта кешесе булуын күрсәтеп:

– Акчасын кияү булачак Абдулла Дубин белән кызым Эльза түләр, – диде.

Шулай итеп мин, телевидениегә күчеп эшли башлагач та, хәләл көчем белән салынган ял йорты өчен театрдан 800 сумны алып бетерә алмадым. Абдулла Дубин белән Эльзаның никахлары ныклы булмады.

Озынга китсә дә, кайбер гыйбрәтле хәлләрне искә төшереп узсам, Әнвәр абыйның рухы рәнҗемәс дип өметләнәм. Аның бәхәссез якты, нурлы кеше булуына беркем дә шикләнми.

Шулай беркөнне сәгать 2ләрдә эшем буенча артистларны күрергә дип театрга бардым, барысы да репетициядә булганлыктан, Әнвәр абый янына кердем.

– Йомышың миндәме? – дип сорады ул, ничектер төксе генә.

Мин:

– Йомышым юк, артистлар бушаганчы сөйләшеп утырырга дип кенә кердем, – дип җавап бирдем.

– Сорауларың бармы?

– Сүз иярә сүз чыккач, соравы да табылыр, тәкъдимнәрем дә булыр.

– Артистлар бушагач, минем кирәгем калмас, сорауларыңны тезә башла.

– Тезәрлек сорауларым юк, исемеңнең ни аңлатуын беләсеңме икән, дип кенә сорамакчы идем.

– Әнвәр сүзе татарча «бик нурлы», «бик якты» дигәнне аңлата.

– Атаң-анаң бик гыйлем кешеләр булганнардыр...

– Исемне дә, ата-ананы да сайлап алып булмый. Мин илдә котырган ачлык елында, 1922 елның көзендә туганмын. Бик зәгыйфь булганлыктан, мине яшәмәс дип фаразлаганнар. Һәркөнне диярлек кемдер ачлыктан шешенеп үлә, бер кабергә икешәр мәетне күмәләр икән. Миңа 6 ай тулганчы исем дә куштырмыйлар. Үләр, дип.

Исем кушу мәҗлесенә килгәннәргә һәм хәзрәткә чәй эчертергә икмәк сыныгы да булмый өйдә. Шуны ишеткән хәзрәт хаергә кергән үз ипиеннән өлеш чыгарып, исем кушарга килә, баланың йөзен ачып карый. Бала хәзрәтне елмаю белән каршылый. Могҗиза кебек була бу.

– Нинди исем кушарга балага? – ди хәзрәт.

– Заманча бер исем табарсың инде, хәзрәт, – ди әти.

– Заманча түгел, балага үзенә хас исем кушарга кирәк. Күрәсезме, ул мине елавыннан туктап, якты елмаеп, күзләреннән нур сибеп каршылады. Димәк, исеме дә Әнвәр булыр!

Шулай итеп, бала Әнвәр исемен ала. Хәзрәт алып кергән икмәк кисәген, киндер чүпрәккә төреп, баланың авызына каптыралар да исем кушу догасын укып, чәй эчәләр. Шул көннән Әнвәр кешеләргә нурлы, якты караш бүләк итә. 2022 елда театр аның туууына 100 ел тулуны билгеләп үтәр дип өметләнәм.

...Театрда эшләгән кайбер җәйләрдә директорыбыз Рәшидә апа Җиһаншина, ярдәм итү йөзеннән, миңа гастрольләргә чыгучы бригадаларга кассир яисә администратор вазыйфаларын йөкли иде. Кайсыдыр бер елның җәендә, керемнең 5 процент өлешен

үземә калдыру шарты белән, бригададан алда шартнамәләр төзеп, төркемне озатып йөрүче администратор вазыйфаларын башкардым. (Хатыным Җәмиләнең кеше ышанмаслык суммада акча алуыма гаҗәпләнүе хәтердә.)

Башкортстан районнарында «Татар хатыны ниләр күрми» спектакле белән йөрибез. Татарстан белән чиктәш Илеш районы авылларына күчкәч, бушрак көн туры китереп, шартнамәләрне тикшереп барларга Мөслим һәм Актаныш районнары авылларына юл тоттым. Кайсыдыр бер авыл ашханәсендә ашап утырганда, «Шаулыйлар дулкыннар» спектакле белән йөрүче бригаданың җитәкчесе Дэллюс Ильясовны очратам. Бу очрашу безнең өчен Эльбада совет сугышчыларының американнар белән очрашуыннан да тәэсирлерәк булды. Нәтиҗәдә, без ике бригаданы Сөн елгасы буенда очраштырып, Сабан туе сыманрак бәйрәм оештыру турында килештек. Көнен һәм урынын билгеләдек. Минем кул астындагы бригада Илеш районының Октябрь колхозында уйнарга тиеш көннән бер көн алда бу колхозның рәисе, Социалистик хезмәт Герое Яхин абзыйны күреп, хәлне аңлаттым. Артистлар Сабан туе батырына тапшыру өчен колхозның сарык көтүеннән тәкә бирүен сорап, акча тәкъдим иттем. Яхин абый мине аңлады гына түгел, тәкәне бушлай бирергә булып, аны кая илтергә кирәклекне дә аңлаттырды.

Икенче көнне Сабан туебыз буласы урынга килгәндә, тәкә бәйдә безне көтә, китерүчесе сугым пычагын үткенләп маташа иде.

Ит яраткан Вәкил абый: «Үзем суям», – дигәч, авыл агаен рәхмәт әйтеп озаттык та үз эшебезгә тотындык.

Бәйрәмебез соклангыч булуы турында язмасам да аңлашыладыр.

Пешереп бетермәгән итне Әнвәр абый Гобәйдуллин Сабан туенда катнашкан һәркемгә гаделлек белән бүлеп, авыл гадәтенчә: «Монысы кемгә?» – дип өләшкәч, бу бәйрәм турында газетада мәкалә бастыру кирәклеге турында килешеп, аерылыштык.

Ит янына, табын түгәрәклеге өчен, 5 литрлы шешәдәге шәраб алган идем. (Әлбәттә, үз акчама, автобуста «Октябрь» колхозына кайтканда шул шәрабны авыз итеп баручы дәрәҗәле артистларны эчкечелектә гаепләү юк иде.)

Һәркем булып узган бәйрәмнән канәгать, ит өчен Әнвәр абыйга рәхмәт әйтә, аның гаделлеген, юмартлыгын ассызыклап: «Исемең җисемеңә муафыйк!» – дияргә тырыша. Бер Фоат абый Халитов кына мырлап утыра: «Безнең исәпкә муафыйк булу җиңел шул», – ди.

Тын гына утырган Әнвәр абый, шоферга машинаны туктатырга кушып, Фоат абыйдан: «Кемгә нәрсә муафыйк түгел иде?» – дип сорый.

Фоат абый:

– Тәкәне колхоз рәисе безнең бригадага бүләк итеп биргән. Ә син аны бу бүләккә бер катнашы да булмаган «Шаулыйлар дулкыннар» әрсезләренә таратып үзеңә абруй казанмакчы булдың, – ди.

Шуннан башлана гауга. Әнвәр абый гомергә күрсәтмәгән горурлыгын күрсәтә. Әрәм булмасын дип, автобуска салган тәкә тиресен урындык астыннан эзләп алып, Фоат абыйның аркасына чәпи. Сугышудан Вәкил абый гына туктатып кала.

«Юаштан юан чыга» дигәнгә бер мисал булса да, бу «ЧП» гына Әнвәр абыйга мөгамәләне үзгәртә алмады, әлбәттә.

Холкы өчен приказ белән эштән чыгарылгач та, Әнвәр абыйның Фоат абый янына хәл белергә барып йөрүе аның исеме җисеменә муафыйклыгын раслый.

Фоат Халитовның кабат театрга алынып, СССРның халык артисты исеменә лаек булуы, Әнвәр абыйның аны беренчеләрдән тәбрикләве бик гыйбрәтле факт.

Әйтер сүзләр күп булса да, мохтасар кылу кирәк. ■

ТАТАР ҖЫРЧЫЛАРЫ. КАДЕРЛЕ МИЗГЕЛЛӘР

Татарстанның халык артисты Миңгол абый Галиев белән якыннан танышлыгым 1988 елда башланды. Нәкъ шул елны мин, институт тәмамлап, Мамадышка эшкә кайттым һәм баштанаяк мәдәниятка кереп чумдым.

Миңгол абый – Мамадыш төбәгенең горурлыгы. Районда нинди генә зур бәйрәм булмасын – шундук кайтып җитә, җырлый, якташларын куандыра, без хезмәт иткән мәдәниятне башка дәрәҗәгә күтәрә иде.

Ул әле танылган җырчы булып киткәнче, Казандагы мәдәният үзәкләренең берсендә эшләп йөргән чорында, тулай торакларның «Кызыл почмак»ларына килеп куйган концертларын тыңлаганнар аны Моңгол дип йөрткәннәр. Студент чагымда заводта эшләүче ике авыл кызының бәхәсләшкәнен тыңлап торганым булды. Берсе: «Миңгол ул!» – ди, икенчесе: «Юк, Моңгол! Моң сүзеннән ясалган исем. Тавышы моңлы булганга шундый исем куйганнар», – дип, аңа каршы төшә. Тавышы моңлы инде Миңгол абыйның, үзе дә тулы бер моңнан гына тора кебек ул.

Җәмәгате Фәния апа белән бер мәктәптә укыган алар. Менә ничек була бит ул «гомер буе бергә» дигәннәре! Икесе ике өлкәдә хезмәт итсәләр дә, Фәния апаның да «сәхнә биографиясе» юк түгел. Үзешчән театрда герой белән героиняларны уйнаган Миңгол белән Фәния алар. Ун еллар элек алар кызлары Розаны югалттылар. Гаҗәеп тыйнак, кыяфәтеннән сабырлык сирпелеп торган, озын буйлы, зифа кыз иде ул. Таш калада андый нечкә күңелле, миһербанлы баланы ничек тәрбияләп булгандыр – иренең әтисе авырып кулга калгач, Казан үзәгендәге фатирларын сатып, ике балалары белән Аксубайның кечкенә авылына кайтып яши башлады алар. Каенатасын карап озаткач, үзенә афәт килде... Миңгол абый кызын, туган авылы Иске Комазанга алып кайтып, әнисе кабере янына җирләде. Уллары Марат, Миңгол абый кебек үк, табигать баласы. Аның холкында да таш каланың әсәре дә юк. Бүген ул да гаиләсе белән Иске Комазанда яши. Миңгол абый белән Фәния апа дүрт онукка әби белән бабай хәзер.

Миңгол абыйның Айдар Галимовны иң беренче күргән көне егетнең армиядән кайткан көне булган. Башкортстанның Миякә районына кунакка килгән күренекле шәхесләрне каршылаганда үзе язган җырны җырлаган ул. Тавышының гаҗәеп тембрына, йомшак аһәңенә сокланып, Миңгол абый аңа җырчылыкка укырга тәкъдим иткән. «Мин юристлыкны сайладым шул инде», – дигән Айдар... Һәм, еллар узгач, Миңгол абыйның шәкертенә һәм күренекле җырчыга да әйләнгән. Ул әле хәзер дә, никадәр генә үрләр яуламасын, Миңгол абыйның шәкерте. Айдар Галимовның Казан концертлары узган көннәрдә Миңгол абыйны әлеге концерт залларыннан табып була. Фанат! Киңәшен бирә, рухи көч өсти. Башка шәкертләре дә нәкъ шулай кадерле аңа. Ул да шәкертләре өчен бик кадерле!

Миңгол абый Галиев белән сөйләшүдә, узган көннәр истәлекләренә караганда, аның киләчәккә планнары күбрәк яңгырады. «80 яшегез тулуга җиңне тагын да ныграк сызганырга уйлыйсыз, ахры, Миңгол абый», – дим мин. «Башкача булмый. Мин бит җыр аркасында гына яшим. Хәрәкәт, омтылыш булмаса, кеше яши алмый, сеңлем», – ди Миңгол абый. Инкяр итә торган сүз түгел...

Миңгол абыйның Илһам ага турындагы хатирәләреннән: «Илһам абый, консерваториядә укытса, гениаль педагог булыр иде. Ул концертлар вакытында биргән киңәшләр һәрчак төгәл һәм гаҗәеп урынлы булды. Аның авазын, ул җырлаган җырларның аһәңен тулаем саклыйсы иде. Күңелемдә бер истәлек саклана. Авылдан белемсез килеш әзерлек курсына укырга килгәч, консерваториянең бер классында утыра идем. Класска бер егет керде дә мине җырлатып карады. Җырладым. «Син дә моңлы икәнсең», – диде дә чыгып китте. Ул егет консерваториянең өлкән курс студенты Илһам Шакиров булып чыкты».

Артистларның архивларында сакланучы мондый фотоларны бик яратам мин. Илһам тулы, нур балкып торган йөзләр, зәвыклы караш, энәдән-җептән уйланган килеш-килбәт. Бер генә очраклы мимика, килешсез мизансцена юк ул фотосурәтләрдә. Бу фотода да күпме таныш, кадерле кешеләр...

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Җуелмас хәзинә

«Су буйлап» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Су буйлап (Идел)

(Татар халык җыры)

Идел бит ул, бик киң бит ул,
Тирән бит ул, көчле бит ул,
Аяз кичне тын бит ул.
Болытлы көн, караңгы төн –
Без аерылган төн бит ул.

Идел буенда күп йөрдем,
Салкын суында күп йөздем,
Тугайларын буйладым.
Аерылганда кул бирмәдем,
Күрешербез дип уйладым.

«Су буйлап» – Бөек Ватан сугышы вакытында бик киң таралган җырларның берсе. Җырның беренче башкаручысы – **Зифа Басыйрова.** Ул җырлаганда баянда **Мөхтәр Әхмәдиев** уйный торган була.

«Су буйлап»ның көен Казанга баянчы **Оркыя Ибраһимова** алып кайта. Ул бу җыр турында мондый истәлек калдырган: «Безнең Академия театры 1942 елның җәендә Татарстан районнарына гастрольгә чыкты. Идел буйлап Камага таба барабыз. Артистка Галимә Ибраһимова белән палубада утырабыз. Каяндыр алдан, пароход борыны ягыннан, бик моңлы җыр ишетелә. Барып карасак, аскы катта кисмәкләр арасына посып утырган бер яшь кыз ниндидер без ишетмәгән яңа моңлы көйгә җырлый:

«Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул шул,
Тирән бит ул, киң бит ул.
Болытлы көн, караңгы төн –
Без аерылган көн бит ул...»

Күрәсең, бу чибәр кызны да сугыш давылы сөйгәненнән аергандыр. Мин, баянымны шунда ук алып, көйне кызга ияреп уйный башладым һәм тиз арада отып та алдым. Хәтта Галимә дә отып алды. Кызның исемен, кайсы яклардан булуын белә алмадык. Ул беренче пристаньда ук төшеп калды. Соңрак бу көйне мин башка сүзләр белән Чаллы районында ишеттем. Аны Зифа Басыйровага өйрәттем. Ул аңа тагын яңа сүзләр өстәде. Шуннан соң без аны шул елның көзендә радио аша яңгыраттык. Көйнең үз исеме юк иде. Беренче мәртәбә Идел өстендә ишеткәнгә, без аны «Су буйлап» дип исемләргә карар иттек».

Бу җыр Георгий Ибушев, Зөһрә Сәхәбиева, Мәгәфур Хисмәтуллин, Мирсәет Сөнгатуллин, Халидә Бигичева, Сәйдә Мөхәммәтҗанова, Ратмир Вәлиев репертуарында бар.



Җырчы, Татарстанның атказанган артисткасы Зифа Басыйрова (1910-1979)



«Су буйлап» җырының нотасы

(Сәхифә «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан күзгә» тапшыруы материаллары нигезендә әзерләнде. Тапшыруның авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева.) ■

Безнең мирас №8 август 2021

Көлке куа килә...

Нажар Нәҗми (1918-1999)

Мөгез

Өч ир-егет, өч ир-узаман,
Утырышып алып берзаман,
Мөгез белән шәраб эчәләр,
Чыңлый-чыңлый бушый шешәләр.

Кавказдан бит килгән бәрәкәт
(Җанга – рәхәт, башка – хәрәкәт),
Мөгез – бүләк, шәраб – күчтәнәч,
Ир ирмени шуны эчмәгәч!

«Мөгезкәе икән путалы,
Бер тот әле, ике тот әле...» –
Мөгез күчә кулдан кулларга,
Мөгез күчә җырдан җырларга...
Дуслар шулай шәраб эчәләр,
Җырлый-җырлый бушый шешәләр.

Өч узаман, өч ир-арыслан:
Аю белән берсе алышкан,
Икенчесе еккан үгезне...
Өченчесе тоткан мөгезне –
«Их, – ди, – хәзер бер фил булганда,
Филләр юк шул безнең урманда...»

Дуслар шулай шәраб эчәләр,
Бушап килә соңгы шешәләр.
Бәй, ни күрәм: өч ир-узаман,
Утыра торгач шулай берзаман,
Берсе китте уңга тәгәрәп,
Икенчесе сулга тәгәрәп,
Өченчесе...
«Их, – ди, – урманда
Филләр юк шул...Филләр булганда...»

Һушсыз ята өч ир-арыслан:
Аю белән берсе алышкан,
Икенчесе еккан үгезне,
Өченчесе тоткан мөгезне...

Яталар өч ир-пәһлеван,
Адәм күрсә күрә икән –
Үгез түгел, бер мөгез дә
Сөзсә, каты сөзә икән!..

Илдар Юзеев (1933-2004)

Хикмәтле шигырь

Берәү – байый.
Миллион – бөлә.
Миллион – елый,
Берәү – көлә.

Мөхәммәт Мәһдиев (1929-1995)

Үзәгенә үткән

Әтисе малайны каеш белән ярам дип үстерә, яргалый да. Малай бервакыт әтисенә әйтә, урманга барыйк, ди. Әтисе:

– Агач яфрак яргач барырбыз.

– Агачларны да каеш белән яралармы?

Туфан Миңнуллин.
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Театраль мәзәкләр

Картаю

Камал театрының сәхнә артында – артистлар ял итеп утыра торган җирдә Туфан Миңнуллин бер артистканың бит очыннан пәп итеп алган икән. Моны күреп торучы өлкән артист Һидаят Солтанов:

– Да-а, Туфан да картая, хатын-кызларны кеше алдында үбә башлады, – дип әйтеп куйган.

Җансөймәс

Бер артист Фирдәвес Әхтәмовага тозлы-борычлы анекдот сөйләгән. Фирдәвеснең андый мәзәкләрне тиз генә аңламый торган гадәте бар. Икенче көнне ул теге артистны очраткан да:

– Карале, җансөймәс, кичә син оятсыз анекдот сөйләгәнсең ич, – дигән.

Зар

Академия театрында мишәр сөйләмендә язылган «Йөрәк маем» спектакленә репетицияләр бара икән. Төп рольне башкаручы халык артисты, Чүпрәле районында туып-үскән Ринат Таҗетдинов:

– Башта, Казан телендә сөйлә, дип, мишәр телемнән биздерделәр, хәзер, мишәрчә сөйлә, дип интектерәләр, – дип зарланып утыра.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Без барыбыз да – балачактан

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Әхмәт Исхак (1905-1991)

Беренче рәхмәт

Алсу хәзер зур кыз инде –
Аңа өч тулган.
Абыйсының кульяулыгын
Ул бүген юган.

Сабынлаган да ул аны
Чиләккә тыгып,
Чайкаган һәм элеп куйган
Тормыйча сыгып.

Шатлыктан нәни Алсуның
Күзләре яна.
Рәхмәт әйткән моның өчен
Абыйсы аңа.

Мөмкин түгел шатланмаска:
Бит шундый рәхәт –
Чын күңелдән эшләп алган
Беренче рәхмәт!

Мич башында биш мәче
(Тел көрмәкләндергеч)

Мич башында биш мәче,
Биш мәченең биш башы.
Биш мәченең биш башына
Ишелмәсен мич ташы.

Нәрсә бирәсең?
(Мәзәк)

– Бабай, әйт әле, син кайчан бабай булдың? – дип сорый нәни Фәрит.

– Син тугач, улым, – дип җавап бирә бабасы.

– Алайса моның өчен син нәрсә бирәсең?

Нәкый Исәнбәт (1899-1992)

Өч матур сүз

– Әйт миңа син өч матур сүз,
Уйлап әйт син, бәбкәем!
– Мин яраткан иң матур сүз,
Иң якын сүз – Әнкәем!

– Калмый аннан бер матур сүз,
Һәрвакыт син әйткәнең.
– Бергә әйткән ул матур сүз –
Әткәем дә Әнкәем!

– Бар өченче бер матур сүз...
– Ул матур сүз – Илкәем!
Анда бу йорт, төп бабамнар,
Илкәем – үз җиркәем!

Дәрдемәнд (1859-1921)

Кояшның нурлары

Матур кояш иртә белән, кызарып, күк йөзенә күтәрелде. Җир йөзен татлы йокысыннан уятыр өчен, алтын кебек сары нурларын таратып, төрле якларга җибәрде.

Башта бер нур очты. Барып-барып сабан тургаеның өстенә төшкән иде, сабан тургае йокысыннан уянып тирбәнде, чыгып, күк йөзенә күтәрелде.

Икенче нуры очты. Монысы татлы йокыда яткан бер куян өстенә барып төште. Куян, урыныннан торып, озын колакларын селкетте. Шуннан сикерә-сикерә яшел тугай эченә төшеп, йомшак үләннәрне керт-керт ашамага кереште.

Янә бер нур, очып, тавык кетәгенең эченә кергән иде, өлкән әтәч, күзләрен ачып, канатларын язып, гайрәт белән тилпенде: «Кикри-и-и-и-кү-ү-ү-үк!» – дип кычкырып җибәрде. Тавыклар куначаларыннан очышып төштеләр. Кытаклашып, төрлесе төрле якка таралды җим эзләргә.

Дүртенче нур, килеп, умарта өстенә төшкән иде, бал корты, балавыз сараеннан чыгып, канаткайларын төзәтте. Ә шуннан: «Без-з-з-з!» – дип китте очып – хуш исле чәчәкләрдән татлы бал җыйнарга.

Бишенче нур, балаларның йокы бүлмәсенә кереп, бер кечкенә ялкауның түшәгенә, туп-туры күзкәенә төште. Йа Рабби, кыздыра! Әмма кечкенә ялкау әйләнеп икенче ягына ятты да тирән йокыга талды.

Муса Җәлил (1906-1944)

Бишек җыры

Шаян кызым син минем,
Таң йолдызым син минем,
Йөрәгемдә кабынган
Шатлык җырым син минем.

Синең гомерең җыр булып
Яңрар бәхет илендә,
Йолдыз булып янарсың
Син туган ил күгендә.

Таңнан торып, бакчада
Син уйнадың көнозын.
Аргансыңдыр, кил, кызым,
Йокла инде, йолдызым!

Әлли-бәлли-бәлли-бәү!
Әлли-бәлли-бәлли-бәү!

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

ИЮЛЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында



● Июльдә язучы-галим, Татарстан-Төркия дуслык җәмгыятенең идарә рәисе Фирдүс Дәүбашның (Фирдүс Нурислам улы Фәтхелисламовның) чәчмә һәм публицистик әсәрләре тупланган китабы дөнья күрде.

● 1 июльдә татар зыялылары Урмайда (Чуашстан) Татарстан һәм Чуашстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, милләтпәрвәр Фәрит Гибатдиновны (1961-2020) искә алды.

● 1 июльдә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында Татарстанның халык шагыйре Мәдәррис Әгъләм (1946-2006) иҗатына багышланган спектакльнең (режиссер, әдәби мөхәррир һәм музыкаль бизәлеш – Туфан Имаметдинов, хореограф – Марсель Нуриев, рәссам – Лилия Имаметдинова) премьерасы күрсәтелде.

● 1 июльдә башкалабызның «Kazan» гранд-кунакханәсендә Мәскәү татарлары

штабы һәм «Аксу» продюсерлык үзәге әзерләп чыгарган «Үз җиремдә – үз телем» китабын тәкъдим итү булды.

● 3 июльдә Мөслимдә XI Бөтенроссия авыл Сабан туе узды. «Мөслим районы республикабыз читендә булса да, бәйрәмне лаеклы әзерләде. Оештыручыларга, кунакларга зур рәхмәт! Бүген монда илнең 45 төбәгеннән 550 делегат килде. Барыгызны да чын күңелдән сәламлибез. Сабан туйларыбыз матур, уңышлы үтәр дип ышанабыз», – диде Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов үзенең котлау-чыгышында.

● 5 июльдә Татарстанның халык артисты, язучыларның Абдулла Алиш исемендәге әдәби премиясе лауреаты, язучы Хәлим Бәдри улы Җәләлев вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде 6 июльдә Самосыроводагы Мөселман зиратында җирләнде.

● 8-9 июльдә «Безнең мирас» журналының җаваплы мөхәррире Ленар Гобәйдуллин Троицк шәһәренә сәфәр кылды. Ул «Рәсүлев укулары»нда катнашты, шәһәрдәге татар зы-

ялылары белән очрашты һәм дин әһелләре, эшкуарлар тарихы турында бай мәгълүмат туплады.

● 10 июльдә Чүпрәле районының Мунчәли авылында XIII «Мунчәли укулары» фәнни-гамәли-дини конференциясе үтте.

● 15 июльдә татар халкының күренекле шагыйре, Башкортстанда яшәп иҗат итүче каләмдәшебез Салават Рәхмәтулла (Салават Ибраһим улы Рәхмәтуллин) вафат булды.

● 16 июльдә «Татарстан» радиосы хезмәткәрләре узган ел кинәт вафат булган шагыйрь, журналист Рөстәм Акъегетне (Рөстәм Габдрахман улы Фәйзуллинны) искә алды.

● 17 июльдә Биектау районының Кече Битаман авылында Т.Миңнуллин исемендәге III Бөтенроссия драматурглар семинары узды.

● 18 июльдә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, профессиональ музыкант, тәҗрибәле педагог Харис Шәрип улы Нигъмәтҗанов вафат булды.

● 18 июльдә Кече Битаман (Биектау) авылында – драматург Данил Салихов йортында – татар зыялылары мәшһүребез Т.Миңнуллинны (1935-2012) искә алды.

● 20 июльдә күренекле язучы, тәрҗемәче, журналист Саимә Ибраһим кызы Ибраһимова вафат булды. Мәрхүмәнең җәсәде 21 июльдә Тынычлык бистәсендәге Мөселман зиратында җирләнде.

● 23 июльдә Казан шәһәренең «Тантана» кафесында «Безнең мирас» журналы редакциясе Корбан ашы уздырды. Анда вафат булган күренекле шәхесләр рухына багышлап Коръән укылды һәм дога кылынды. ■

МИРАСВОРД

Тылсымлы сүз, тылсым

... Басыйрова

100 квадрат метр

Борынгы кабер өстенә куелган таш сын

Күрәзәлек, юрау

... Миңнуллин

Тарантаста утыру өчен чыбыктан үреп ясалган арҗә

... Гыйматдинова

XIX гасыр француз рәссамы

Фатих Кәрим поэмасы

Крокодил (иск.)

Эре сөякле, зур (диал.)

Әдәби кечерәйтү ярдәмендә ясалган сурәтләү чарасы

Язучы Зиннур ...

Билгеле бер вакытта укылырга тиешле дога, аять

Горурлык, эрелек (иск.)

Сиртмә

Төрле төстәге

Язучы ... Камалов

Томас ... (инглиз язучысы, фәлсәфәче)

Җитмеш төрле чирдән дәва

Әйләнә (диал.)

Язучы ... Насыйри

Җәнлек оясы

Ташлы ташкын

Аллаһы Тәгалә пәйгамбәр күңеленә салган фикер, хәбәр

Үгет, яхшы киңәш

Калын, тупас сукнодан тегелгән элекке өс киеме

Белән (иск.)

Агарган, көмеш төсле чәч

Аз санлы төрки халык

Чокып ясалган зур агач табак (диал.)

1920-1929 нчы елларда Әфганстанда сугылган алтын акча

1906-1918 нче елларда Оренбургта чыккан татар газетасы

Бәхет кошы (иск.)

Әти-әнисез

... янына куш

Язучы Кәрим ...

Какшамас

Әмирхан Еники повесте

Ат, ишәк, дөя аркасына салынган йөкнең бер ягы (иск.)

Тавык (диал.)

Рәис Габдулла төзеде.

7 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: мәшкә, сада, гөрзи, Уту, ярен, «Зингер», Авиан, бәк, Сәйф, әнәчә, ушат, «Яшен», хәер, хәя, Әйди, Иркә, тояк, Зыятдинова, паяз, егу, читек, ыра.
Өстән аска: Мәгаз, Хәй, Игәнәй, Ширин, де, Гафури, язучы, Әминев, ут, Гир, ригая, дзета, «Тәрбия», энә, нанка, Ян, Поти, Амур, Бәширов, Теләче, аяк, ахун, кәнтәк.

«Безнең мирас»

елъязмасы / август

Казанда сәүдәгәр Апанаевлар карамагында булган мәчет

675 ел элек (1346)

Алтын Урда дәүләтенә зур афәт килә – чума эпидемиясе башлана. Дәшти Кыпчак, Идел буе вә Кырымда бик күп кеше үлә. Елъязмаларда бу хакта: «Үзбәк хан җирләрендә шәһәрләр һәм авыллар бушап калды», – диелә. Бер Кырымда гына да шушы эпидемиядән 85 мең кеше вафат була.

470 ел элек (1551)

14 августта Мәскәү-Казан солых килешүе төзелә.

175 ел элек (1846)

17 августта данлыклы татар сәүдәгәре Мөммәтзакир Габделкәрим улы Апанаев (1846-1912) дөньяга килә.

115 ел элек (1906)

Баку шәһәрендә мәктәп балаларына хаслап (багышлап) рәсемле педагогик журнал чыга башлый. Ул ике атнага бер тапкыр нәшер ителә. Мөхәррире – Мирзазадә Гафурша Габдерахманзадә.

100 ел элек (1921)

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариатының Әдәбият бүлеге татар әдәбияты буенча чыгышлар шәлкеме оештыра. Лекцияләр укуга Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Гали Рәхим, Газиз Гобәйдуллин һәм Хуҗа Бәдигыйны чакыралар.

85 ел элек (1936)

Август башларында үзбәк язучылары – Әмин Гомәри,Гафур Голәм һәм Шакир Сәләйман, Татарстандагы мәдәни вазгыять белән танышу һәм Татарстан турында әдәби әсәрләр язу өчен материал туплау җәһәтеннән, башкалабыз Казанга киләләр.

*Журналга **Марат Закир** әзерләде.* ■

Содержание. Август 2021

И останется в мире слово моё...: Адип Маликов.

Историческое наследие: «Айтикины». Р.Нафиков, Ф.Валиев; «Потерянная Казань Сибири». Н.Галиева; «Моя последняя археологическая находка...». М.Усманов; «Татарское издательство в Омске». Р.Шарафиева, Л.Губайдуллин; «Габдулвали Яушев – представитель Троицких богачей». Г.Баттал; «История нашей родословной». А.Маликов.

Литературное наследие: «Один из сборников Тукая, изданный в Суоми». Х.Миннегулов.

Татарский мир: «Наши надежды оправдываются». М.Шаймиев; «Слово Сибири». Ф.Байрамова; «Тукай вернулся в Троицк». Л.Губайдуллин; «На малой родине Нурихан ага».

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Уроки религии». С.Бикбулат.

В глубинах памяти: «Ученый, исследовавший Сибирь». А.Валиева; «Из Сибирских простор в душу народа». Л.Мухамметзянова; «В памяти, до сих пор в памяти!».

Художественное наследие: «Татарские певцы. Дорогие мгновения». З.Гильмутдинова.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Нарва җәмәгате исламиянең 10 еллык бәйрәме мәрәсиме
(«Эстониянең Нарва шәһәрендәге ислам җәмгыяте тарихы». *И.Мифтахов*)

● **Эстониянең Нарва шәһәрендәге ислам җәмгыяте тарихы.**
Ильяс Мифтахов

● **«Кыйссаи Сәкам».**
Лилия Мөхәммәтҗанова

● **Багъбостан ханым.**
Ленар Гобәйдуллин

● **Троицк байларыннан сәүдәгәр Бакировлар.**
Марат Әхәтов

Омск татарлары — фотоларда

Омск татар драма театры коллективы. 1935-1936 нчы еллар

Тара сәүдәгәре Хәмзә Гыйноятов хатыны Сәхидә белән

Тара районындагы Кыргап авылының мәчет бинасы. Совет чорында аның манарасы киселеп, мәктәп эшләгән.

Тара районындагы Себеләк авылының мәчет бинасы. 1972 ел

Тара районындагы Гаедкол (икенче исеме – Кызылкаш, урысча – Айткулово) авылында укучы мәктәп балалары. 1940-1950 нче еллар. Бу авыл хәзерге вакытта юк инде.

Рәҗәп (Шәехләр) авылында сәүдәгәр Гыйноятовлар йорты

Сәхифәне ***Азат Сәйфетдинов*** *әзерләде.* ■

ОМСК МӘЧЕТЕ. XX ГАСЫР БАШЫ ФОТОЛАРЫ

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.